дә килеп кушылабыз...‖ [1, 5]. Бирелгән сүзләр укучылар тарафыннан аңлатыла. Мәсәлән, *тугай* сүзе болын, су буе дигән мәгънәне аңлата, ә *тикмәгә* сүзе бушка түгел мәгънәсендә кулланылуы укучылар тарафыннан әйтелә. Эшнең бу төре укучыларның сүзлек байлыгын арттырып кына калмый, аларда ата-анага, туган якка, туган телгә карата хөрмәт хисе уята.

Өй эшенә дә мөстәкыйль өйрәнү өчен төрле биремнәр бирелә. Эш төрләре түбәндәгечә була: укытучы тарафыннан укучылар 4 төркемгә бүленәләр һәм һәрбер төркемгә аерым бирмнәр бирелә. Әлеге биремнәр үз эченә аш-су өлкәсенә караган; көнкүрешә кулланыла торган диалекталь сүзләрне язып алып килергә һәм аларның мәгънәләрен аңлатырга; яисә диалектлар кулланылган табышмак, шигырьләр, хикәяләр алып килергә, аларда кулланылган диалектларның мәгънәләрен аңлатырга һ.б. Әлеге эш вакытында укучылар ―Татар теленең зур диалектологик сүзлеге‖ (2009) файдалана алалар.

Азнакай районы мәктәпләрендә татар телен укыту методикасы республикакүләм укыту методикасына туры килә. Шул ук вакытта, татар теле лексикасын укытуда җирле сөйләш үзенчәлекләре дә исәпкә алынырга тиеш. Укучыларның сүзлек байлыгын үстерү, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү – башлангыч һәм урта звено сыйныфларында укытуның төп максатларыннан берсе. Телне өйрәнү, аны үзләштерү, билгеле булганча, бик катлаулы, иҗади эш. Аның нигезендә өйрәтүчегә механик рәвештә ияру түгел, бәлки актив танып-белү эшчәнлеге ята.

Ана теле дәресләрендә укучылар матур итеп уку белән бергә, текстның төп мәгънәсен аңларга, сораулар куя белергә, сүзлекләр белән эшләргә, шул ук вакытта үзләре дә тулы, дөрес җавап бирергә өйрәнә. Дәресләрне җанлы, мавыктыргыч итеп үткәргән очракта гына – бала дәрестә катнашып, татар телендә дөрес итеп сөйләшергә өйрәнә ала. Шулай эшләгәндә генә уңай нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин.

Әдәбият

1. Әхмәдиев Н. Г. Атларым, колыннарым: повестьлар һәм хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 190 б.

2. Галиуллина Г. Р. Хәзерге татар теле лексикологиясе. – Казан: Казан ун-ты, 2009. – 126 б.

3. Сафиуллина Ф. С., Зәкиев М. З. Хәзерге татар әдәби теле: лексикология, фразеология, фонетика, графика һәм орфография, орфоэпия, сүз ясалышы, морфология, синтаксик: Педагогия училищелары, гимназияләр өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 1994. – 144 б.

4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

CAUCASUS AREA OF TOPONYMS OF TURKISH ORIGIN

Karimova Irada Mazahim gizi
ADPU
irade.kerimova.81@mail.ru

Toponyms are one of the most valuable resources that reflect the history, language, and geographical location of the area where it belongs. There are still enough onomastic units that show that the Turks settled in the Caucasus in ancient times, and that they needed research from linguistic point of view.

It is known that the Caucasus is one of the oldest part in the East. Since these areas are ancient settlements, the history of the land names here is also ancient. Historical sources have preserved the onomastic units of the distant past, as well as toponyms to our day.The sources provide valuable evidence for the scientific explanation of toponymic units. Sometimes, to avoid erroneous assumptions about toponyms, it is necessary to rely on historical sources and variants mentioned in sources

We can also find information about the toponyms of Azerbaijan in various sources and sources of different periods. Very valuable information and facts concerning the toponymy of Azerbaijan have been preserved in ancient Greek, Roman, and later Georgian, Arabian, Persian, and Syrian sources.

Russian and European travelers also take a special place among the sources of rich and interesting information about the toponyms of Turkish origin, spread throughout the Turkic world. Experts attribute Europeans' first travel to the Caucasus, including Azerbaijan in the 13th century.

Ethnic processes and events that have taken place in the distant past have preserved their traces in the toponymy of Turkic-speaking nations. Most of the toponyms of Turkic origin in the area are the names of separate tribes or union of tribes which give valid facts abot the people who had settled in those areas.

It is more important and expedient to investigate the toponyms in the refinement and determination of the ethnic composition of the territories where the Turkic peoples have historically lived.

A number of geographical names of Turkic origin that have historically existed on the territory of other countries have, over time, been forgotten, changed, distorted and translated into another language.From this point of view, it is of interest to study the names of settlements of Turkish origin, common to Turkic-peoples, as well as lexical-semantic, grammatical and syntactic structures ofhydronims, oykonims, oronyms.From this point of view, there is still a need to investigate the historical-linguistic aspect of the toponyms of Turkic origin in the Turkic world and provide lexical and semantic interpretation of these geographical names.Because of the richness of the lexic-semantic features of the toponyms of the Turkic origin in the territories of the Turkic-speaking peoples, they have always attracted attention. One of the theoretical features of the toponyms of Turkish origin is the large semantic circle.

Abdal. Abdals were one of the ancient Turkic tribes settled in Azerbaijan as well as in the Caucasus, Iran, Turkey, Bashkortostan, Central Asia. This tribe represents the name of the White Hun tribe.

According to folk etymology, the name Abdall was derived from the name of Abdal, who built this area. According to village elders, the name was taken from the camel's baby. However, the fact that toponyms exist within the territory of Azerbaijan and beyond the borders of our country creates the idea that it is based on ethnicity.

Abdall is an oykonim formed on topoformant with Abdal +*li*. The word Abdal embodies the name of the ancient Turkic-speaking Abdal tribe.

Historical sources indicate that the Abdalahs were the great Turkic people who played the role in the history of Central Asia, East, Turkestan and India. In the historical sources named after the tribe of Abdal are eftalit, abdel, heptal, etc. names (4. p. 74).

. The Syrian historian Zohori Kitor (6th century) also named the Turkic-speaking tribe abdal among the various tribes living in Hun province in the North Caucasus. Akad VV Barthold noted that the adabel // abdal tribe is one of the ancient tribes in Kazakhs, Karakalpaks, Turkmen and Turkey.Various phonetic forms of the name ethnonim abdal, mentioned in the sources as heftal, heptal, eftal.The Albanian historian Movses Kalankatli, referring to the Abdalis tribe living in Albania, noted that heptols (abdals) migrated here during the Macedonian Alexander period (4th century CE).The tribe has a special place in the formation and development of the Azerbaijani people.

Abdal village, river and river (Tovuz), Choban Abdally village (Goygol), Abdal Gulabli str. (Aghdam), Abdal str. (Agdash, Oguz), Abdalanli str. are abdal based etnonyms in Azerbaijan. It is possible to find oykonims and hydronims like Nic-Abdali (Gabala), Abdallar village (Khojavend), Abdal mountain, valley and hill (Lachin), Abdal river (Dashkesen) and Abdal spring (Jabrayil)(15.s.125). N. Mammadov, who researched the ethnonym of Abdall as a place, writes that one of the origins of the ethnonym is Abdal Mountain. The author mentions the name of abdal tribes in the oronyms of Abdal valley (Abdal village, Tovuz region), Abdallar village (Bahramli village, Khojavand district), Abdal Mountain, Abdal hill, Abdal valley (Lachin district) in the archeology of our republic (15..1.1). The name of Abdal Mountain was also recorded in Ordubad district of Nakhchivan AR.

B.Budakov and G.Geybullayev have showed etnonyms as Abdallar in Karpibasar district of Iravan khanate, Abdallar tomb in 1590, source in 1727 in Abdal village in Varanda district of Nagorno-Karabakh, Uzunabdally and others in the area. (6.98, 383, 393).

Qeybullayev informed that the topology of Abdal and Abdallar also exists in Iran (21. p.436).

A. Pashayev writes about the ethnonym of Abdal: ―Although in the anthroponymy of Azerbaijan there is little mention of the name of Abdal // Avdal, in North and South Azerbaijan there are many toponyms of Abdal hill, Abdal mountain .In Turkey, Afghanistan, Iraq, Karachay and Balkar have many monuments and village names related to this anthroponym. The name of one of the oldest Turkic

tribes, and in the mythical thinking of the Turkic peoples, Abdal lives as a god who protects hunting animals. Before the hunt they would pray to Abdal (18 p.211).

I. Jafarsoylu explored the "abdal" ethnonym as a tribal name derived from the teonims. The author writes that Abdal is a god of hunting in the ancient beliefs of a number of Dagestan peoples - Avars and Kumuk. According to the author, these nations believed that Abdal is sitting on the clouds and graze his animals,plays his mysterious pipe, and protects them.Those who break the rules of hunting, go hunting before the hunting season, punish them, and bend their arrows in the sky. That is why these peoples share the corpus of the animal they hunt with abdal (2 p. 36).

Abdal and Abdallar in Iran, Abdal, Kishlok village in Uzbekistan and Abdalbulak hydronim are found in the range of toponyms of Abdal ethnonym. In the territory of present-day in Armenia, Abdallar, Avdallar villages and Boz Abdal have been known as mountain ranges (1.98).

Speaking of Abdal ethnonym, Chobanov noted that the word "hunting god" as in the mythology of Turkic peoples means "protector of hunting" and " hunting supporter" (3. p.28).

Referring to the work of the "Detailed Book of the Province of Tiflis", N. Askerov cites that there is Abdal oykonim in Borchali , Abdal and Patak villages in Agjagala district and Bozabdal village in Bolnis in the region of Georgia where Azerbaijanians live .The author considers that there is a village called Goyash near the village of Abdalli, and that the villages of Abdall and Goyash are of the same tribe (11. p. 8).

Abdal ethnonym in the system of onomastic units of Uzbekistan is Abdal, Obdal, Abdalbek, Abdalkhan, Abdulbulak, Abdalbay, Mulla Abdal, Abdalaras, Abdal-bova, Kara-Abdal, Hodja Abdal as anthroponym, ethnonym, toponym and hydronyme. The author considers that the village of Goyash is located near the village of Abdalli and that the villages of Abdall and Goyash are of the same tribe (11. p. 8).

As it can be seen, abdal based ethnotoponyms have become quite widespread in the system of common toponyms with Turkic peoples.

Baydar. The toponym is formed on the basis of the "Baydar" which is more widespread in the Caucasus. There is a toponym of Baydarli in the Gakh region of Azerbaijan.

When investigating the distribution range of the Baydarli toponym, E.Nuriyev finds that it is an ethnonym. This ethnonym was also known among the Mongols and Crimean Tatars in the 17th century. The author makes two points about the creation of the Baydarli oykonim. One is related to the person's name and the other to the tribe's name. Baydar is described as a person in 1273 as the leader of the group (Amir Baydar) among the Mongols (17. p. 42).

Commenting on the etymology of the Baydarli toponym, R.Aliyeva writes: ―Baydar is a Mongol warrior. The Dominican priest, who visited the palace of the Mongol khanates in the 13th century, translated this word as "voevada" (8. p.134).

The boundaries of the Baydar ethnotopony are also found in the Republic of Georgia, Armenia, Crimea, and Bashkortostan.

A.Bayramov writes about the Baytaroğlu // Bayda-roglu valley in the Amasya district of Armenia, saying that Armenian sources mention the name of the ruined village in the Ili (Elli) valley in the Amasya district. This area is 4 km south of the Baytar village (5. p.157).

In the Borchali accident of the province of Tbilisi there are Baydar oykonyms. In the North Caucasus, one of the mountains in the Ter province is called Baydara. The release of the Caucasus calendar for 1878 states: ―Baydara is 7,782 feet above sea level and is the highest human settlement in the Caucasus after the height of Kodor (23 p.68).

There is currently a Baydar oykonym in the Marneuli district of the Borchali district of the Republic of Georgia.

Baydar oykonym was registered in the Cherden Soviet, called Redikor, near the Republic of Bashkortostan. In the historical documents of 1579 it can be seen that it was the same as Baydarov's surname (24. p.110).

The range of the Baydar toponyms can also be found in the Crimea region. M. Nuriyeva writes that this toponym is used in the Crimean Tatar language as Baydar-Ova (25 p. 159).

Çol//Çul//Çullu. The Chulu tribe played a great role in shaping the language and origin of the Azerbaijani people. The Chulular are also called Chol and Chul. The geographical names associated with this ethnonym are found not only in Azerbaijan, but also in the Caucasus and other areas inhabited by Turkic peoples.

Researchers have different opinions on the toponym of Chul.

Qeybullayev notes that Chul // Chol // Ethnoponim was created on the basis of the "chulu" ethnonym. The author writes: ―In the first centuries of Iran, a city in the north-east of Albania south of Derbent is known as Chol // Chul. This toponym is considered Caucasian. However, we have stated that this name reflects the name of the Chul tribe of Turkic origin living in Albania and that the ethnonym still holds the names of the villages of Chullu ‖ (p. 132).

G.Qeybullayev notes that Chul // Chol // Chullu Ethnoponim was created on the basis of the "chulu" ethnonym. The author writes: ―In the first centuries of era, a city in the north-east of Albania south of Derbent is known as Chol // Chul. This toponym is considered Caucasian. However, we have stated that this name reflects the name of the Chul tribe of Turkic origin living in Albania and that the ethnonym still holds the names of the villages of Chullu ‖(p. 132).

N. Baskakov notes that the Cul/Col is the name of the of Caspian kagan (19 p. 20).

V. Gukasyan also stated that Chol and Chul are the names of the Caspian kagan and that the word is used in the Chuvash language as "valley" and "rock" (p. 20, 57).

Ch.Kazimov who has researched Chul/Chol toponyms, writes that Chul // Chol was recorded in the monuments of the fifth century AD. Armenian historians of the 5th century Egiès Fovstos Buzand and Aqofongel often mention the Turkic tribes coming to Azerbaijan from the north and often mention the name of the Caul // Chul cave.

The author writes, referring to K.M. Traver, that the mascots settled on the north-west coast of the Caspian Sea, south of the Samur river, in the area called Chor, Chul in the V century. The author then cites V.V. Bertold as saying that it is appropriate to read Sul oykonim as Chul, which is found in some Arabic sources. Ch. Kazimov writes that the Arabic letter "sad" is like the replacement of the sound "ç". Based on G. Mashadiev, V.K. Yegorova, Chol-Chul is a Turkic word that is used in the Chuvash language to mean "stone", "rock", "valley", which corresponds to the geographical landscape of the Oykonim. In our opinion, it is associated with the word chul// chol, which means "desert" (12. p. 29-30).

H. Mirzayev, who investigates Chol // Chul onim as an ethnonym, writes that Chul is a village name in Daralayaz. Historical sources indicate that the name of the Turk tribe Cul, was an ancient Azerbaijani village (16, p. 90).

R.Eyvazova writes about the Chul // Chol toponymy range in the territory of Afghanistan: ―Chol-village-Parvan; Shor // Shur village - in Gandhar. We consider the geographical names of Chol, Tsar, Sul, Sur and Sur in the Afghan territory and the names of the Turkic origin with the same semantic meaning and different phonetic variants ‖(7.7).

N. Mammadov writes in his researches about the Chulu mountain, Chullu valley and Chullu hill oronyms in the territory of our republic that the aforementioned oronyms bear the name of the Chullu Ethnonym. From the first years of our era in the territory of our republic there were also tribal tribes (kəngər, tərtər, qarqar, çiraq, gəncə) among the Azerbaijani tribes. In the last century, five toponyms in the Caucasus have existed (15 p.164).

N.Askerov said that Chol-Chul-Sul onimi's explanation as "water" and "river" is more scientific (11. p.311).

Chol // Chul // Chullu toponyms and hydronims are in Georgia - Çullu k. Alının yeri, Çolman, Çolyan k., Sul valley; In Armenia - Çulabad k., Çul k., Çullu k., Cul k.; In Tatarstan - Çulım ideli, Çulman çayı, Çullu k.; In Turkey - Çullu k.,, South Azerbaijan - Çölabad k.;; In Uzbekistan - Çulobod k., Çulvotir Mountain; It is found in the mountainous Altai - Chulush river and Tuva - Chulcha river.

Qazan. It is possible to find the range of Qazan ethnopoponym both in Azerbaijan and outside of Azerbaijan. Before the revolution in the Caucasus, 24 toponyms with the Qazan command were registered. There were only 10 villages in Azerbaijan called "qazançı" (22. p.130).

The Kazan Turkish tribe was a Bulgarian tribe. The Bulgarians lived in the Bulgarian territory of the Volga-Kama river basin. According to sources, the Bulgarians at the beginning of the Middle Ages consisted of a number of tribes - *küdvar, çakar, kuriqir, kul, kazan, iskil* and others. The Caucasus, as well as one of the Bulgarian tribes, which has made its mark on the toponymy of Azerbaijan, is considered to be the kazan (22. p.87).

Sources claiming that approximately in the VI-VII centuries AD the name Kazan originates from the name of the ancient Turkic tribe Kaz, who lived in the Kazan, the Meshi Basin and the lower Kama River, archeological excavations in the territory of the Republic of Tatarstan in recent years have led to the conclusion that

before the arrival of the Bulgarians to the Volga-Kama beaches, the ancient Turkic tribes lived here in the III and IV centuries AD (first stream) and VI-VII centuries AD (second stream).

N. Askarov writes: "It is possible that the" kaz "tribes, to which the names of a number of geographical objects of our country are connected, were one of these ancient Turkic tribes. Apparently, after the Bulgarians arrived in the Middle Volga, the Kaz tribes mixed with them. It seems to us that the Kazakh ethnonym is closely related to the totem beliefs and that they were probably derived from the personal name or nickname of Kaz (Gaz), the founder of the Turkic tribe, which later grew into a tribe. ‖ (11. p.155-156). In the end, N. Askerov concluded that animal totems and ethnonyms related to ancient person names were widespread among ancient Turkic tribes.

The fact that Kazan-based ethnoponims, as well as the Caucasus, Turkey, Bashkortostan, Iran, Mountainous Altai, Uzbekistan, Kazakhstan, Afghanistan, and the various parts of Azerbaijan, proves that it is a common etnotoponim and has manifested itself in many regions of the Turkic tribes. In the end, N. Askerov concluded that animal totems and ethnonyms related to ancient person names were widespread among ancient Turkic tribes.

Six villages and two mountains called "Kazanchi" are among the ethnoponims of Turkic origin in the territory of Western Azerbaijan (present-day Armenia). In the territory of Qazanlıqdərə of West Azerbaijan, Gazanchi (village in Mazra and Shurekal district of Iravan province), Gazanchi, Gazangol (village and lake in Zangezur district of Yelizavetpol province), Gazanchi (Irenvan village) Toponyms have been registered (6. p.174).

In the Circassian toponymy, J.N.Kokov states that Kazankai-Kazankovo toponyms can be found in the Kazan component mountain, crossing and river names near Baksan, Çerek, Nalchik (28,209). J.N.Kokov and S.O.Shakhmurzayev also noted that the toponymy of Kabarda-Balkar is the toponym of Kazan (26. p. 81).

Toponyms called Kazan were also registered in Turkey. Doğubeyazit-Agri and Yenimahalle-Ankara have Kazan, and Konya in Kazanchi (27. p. 90).

According to G.Geybullayev, Kazanchi and Kazan toponyms were registered in the North Caucasus, Ukraine, Bashkortostan, Western Siberia, Iran and Turkey. The author notes that there are 24 toponyms in the Caucasus (13. p.135).

Writing numerous studies on the ethnogenesis of the Bashkorts, R. Kuzeyev investigated the active participation of the Kazanchi (Kazançı) tribe in the genocide of this Turkish nation. The author writes that the history of the Kaipan Tamp tribes settled in northern Bashkortostan was also related to the active Kipchak migrant period (14. P. 365).

There are different opinions in the scientific literature concerning the semantics of the ―Kazan‖ based toponyms.

Speaking about the semantics of the word ―Kazan‖, E. Miraliyev explains it as ―a subduction zone far above the edges‖.

R.Eyvazova writes with reference to V.V. Radlov: "Kaz // gas" and its "Kas // Qas" phonetic version have the words "altitude" and "height" in Kyrgyz, Sakai,

Koybal. The word "gaz //gas" is also used in the names of earth, rivers, and even breed horses. In the name of Gazan, "gaz" is a form of the verb adjective. Created from both contents, Gazan is understood to be "rising, emerging, glorified" (7. p.83)

J. Amirova's ideas about the Gazan ethnonym are also very interesting. The author writes: ―Some of the ethnographic toponyms in Azerbaijan have been formed by the connection of the suffix ―çı‖, profession, art and occupation suffixes to the names of the ancient Turkic tribes and division who lived in our territory. For example, the settlements of the Bulgarian tribes, the Kazan tribes, were called Gazan (10p.110-111).

Currently, toponyms like Gazan can be found in the names as Gazanbulag in Goranboy region, Gazangul settlement in Zagatala, Gazanbul in Jabrail, Gazanbatan in Agdam, Zangilan, Julfa and Goranboy in Gazanchi village, Gazadagul lake, Gazadagal plain, Gazabad (15. p.112-113).

N. Mammadov considered the names of Gazan-based mountains and rivers as metaphorical oronims because of their outward appearance. The author writes about metaphorical hierarchies of the Gazan hill in Agjabadi, Qazandağ in Shamkir, Qazangәldağ in Ordubad, Qazan valley in Ismayilli, and Qazança hill in Masalli. But the word ―qazan‖ in the mountain range of the Qazangöl is not related to the likeness of a mountain to a pot.

The mountain is called Gazangol Mountain due to the presence of boiler-shaped, circular lakes on the mountain. At the same time, in the oronim of Qazanqoşa it is stated that the two peaks of the mountain resemble the pot (15. p. 47-48).

The research carried out further proves that the toponyms of Qazan (Kazan) originated with the name "qaz / kaz" Turkic tribes. When it comes to the semantics of the word "gas", it is interpreted as "high, great" in linguistics.

It is clear from the researches that along with the ancient Turkic words and elements, which were considered archaic, the names of the tribes of Turkic origin were also included in the formation of geographical names.

References

1. Budagov B.A., Geybullayev GA Explanatory dictionary of toponyms of Azerbaijani origin in Armenia. Baku: Nafta Press, Oguz, 1998, 452 p.
2. Jafarsoylu I., Ethnolinguistic Compliance of Turkic, Urartu, Albanian. Baku, 2008, 327 p.
3. Chobanli M., Toponyms of Borchali. Baku, 1996, 64 p.
4. Askerov N., Historical-linguistic analysis of river names in Azerbaijan. Baku: Science-Education, 2013, 576 p.
5. Bayramov A., Local names (toponyms) of the ancient Oguz countries - Aghbaba, Shoreyel and Pambak. Baku, Adiloglu, 1996, 240 p.
6. Budagov B.A., Qeybullayev Q.A., Explanatory dictionary of toponyms of Azerbaijani origin in Armenia. Baku, Oguz, 1998, 453 p.
7. Eyvazova R., Toponyms of Turkic origin in Afghanistan. Baku, Science, 1995, 243 p.

8. Aliyeva R., Mongolian elements in toponymy of Azerbaijan // Researches. Institute of Linguistics named after Nasimi of ANAS Baku, Science, 1999, No. 5, p. 129-135.
9. Explanatory dictionary of the Azerbaijani language. II c., Baku, Science, 1980, 576 p
10. Amirova J., On ethnographic toponyms of Azerbaijan // Problems of Azerbaijani onomastics III, Baku, API, 1990, pp.110-111.
11. Askerov N., Areal linguistic features of Turkish onomastic units. Baku: Science, 2005, 485 p.
12. Mashadiyev G., Toponyms made from ethnonimals. AOP, II, 1998, pp.112-113
13. Geybullayev G., From the history of the formation of Azerbaijani Turks. Baku, Azerbaijan State Publishing House, 1994, 248 p.
14. Kuzeev R.G., The origin of the Bashkir people. M., Science, 1974, 571 p.
15. Mamedov N., The place names of Azerbaijan (oronimy). Azerbaijan State Publishing House, Baku, 1993, 184 p.
16. Mirzayev H., Daralayaz district of Western Azerbaijan. I, Baku, Science, 2004, 854 p.
17. Nuriyev E., Toponymy of Sheki-Zagatala zone of the Azerbaijan SSR. Baku, Science, 1989, 110 p.
18. Pashayev A., On international onomastic units with ―fire‖, ―hearth‖ and ―pir‖ components // Researches. Institute of Linguistics named after Nasimi of ANAS Baku, Science, 2006, No. 2, p. 205–215.
19. Baskakov N.A., The proper names of the ancient Turks of Eastern Europe. Onomastics, Typology, Stratigraphy. Moscow, Science, 1988, p. 120-127.
20. Voroshil G., Aslanov V. Studies on the history of the Azerbaijani language of the preliterate period. Baku, Elm, 1986, 228 p.
21. Geybullayev G., From the history of the formation of the Azerbaijani Turks. Baku, Azerbaijan State Publishing House, 1994, 248 p. Institute of Linguistics named after Nasimi of ANAS Baku, Science, 1999, No. 5, p. 129-135.
22. Toponyms of Azerbaijan. Encyclopedic Dictionary. Baku, Azerbaijan Encyclopedia, 1999, 588 p.
23. Caucasian calendar for 1848. Tiflis, In the printing house of the offices of the governor of the Caucasus. 1847, 266 p.
24. Krivoshchekova-Gantman A.S., Turkic component in the onyme of the Upper Prikamye Research in Vashkir dialectology and onomastics. Ufa, 1986, p. 110-111.
25. Nuriyeva M., From the renaming of the great Turkic land from the West to the East. Baku, 1999, 244 p.
26. Kokov J., Shakhmurzaev S.O. Balkar toponymic dictionary. Nalchik, Elbrus, 1970, 170 p.
27. Erk Yurtsever., Compilation of Turkish geographical names in Asiyada. A full-time. Turkish World Research Foundation. Istanbul, 1993, 156.
28. Kokov J. N., Adyghe (Circassian) toponymy. Nalchik: Elbrus, 1974, 316 p

СОВРЕМЕННЫЕ ЦИФРОВЫЕ СРЕДСТВА ОБУЧЕНИЯ ЯЗЫКАМ

Каюмова И.Ф. , Мударисова Р.Р.
МБОУ «Средняя школа №63» г. Ульяновск
Kaif070@mail.ru

Аннотация. В данной статье рассказывается о современных средствах, которые облегчают работу учителям и преподавателям при организации учебного процесса, способствуют эффективному взаимодействию с учащимися в ходе совместной работы.
Ключевые слова: дистанционное обучение, информационные технологии, он-лайн обучение, инновационные методы.

Пандемия коронавируса привела к серьезным изменениям в образовании - теперь традиционное очное обучение будет соседствовать с дистанционным - единственно возможным способом передачи знаний от педагога к ученику посредством онлайн-платформ, видеоконференций, мессенджеров и других современных технологий. На конференции «Первые итоги пандемии: вызовы и новые возможности для мировой системы образования» глава Министерства просвещения России Сергей Кравцов сказал: «В целом, речь может идти о создании новой дидактики, которая позволяет совмещать традиционное обучение и обучение с использованием информационных технологий. И это должно работать вместе. И, наверное, мы на пороге этой новой дидактики все вместе находимся» [2].

Дистанционное технологии позволяют учащимся посещать любые курсы, уроки, занятия, вебинары в режиме он-лайн, экономя драгоценное время.

«То, что мы видим во время пандемии, - это не новая модель образования. Это просто запасной вариант, пока нельзя восстановить существовавшую ранее модель образования», - считает оксфордский профессор Джеймс Брук, по мнению которого очное обучение - это золотой стандарт [4]. Но и этот профессор признает отдельные плюсы нынешней ситуации. Виртуальное обучение помогает ученикам и студентам с ограниченными возможностями. И чем больше программ становятся доступным он-лайн, тем это лучше для них.

За период дистанционного обучения нами были использованы всевозможные инновационные технологии:

-Classroomscreen.

- Flippity.

-Triventy.

Онлайн-сервис ClassroomScreen помогает в организации мероприятий, в том числе дистанционных. Для использования дистанционных мероприятий необходимо запустить демонстрацию экрана в приложении для организации онлайн-мероприятий.

Этот сервис позволяет:

1. Разделить участников на команды.
2. Выбрать слово или имя участника из списка случайным образом.
3. Демонстрировать qr-код с возможностью разделения разных кодов для разных команд.
4. Выбрать фон (заполнение цветом или картинкой).
5. Использовать рабочие символы (иконки): «без звука», «шепот», «спроси соседа», «работать вместе».
6. Случайный выбор числа.
7. Вывод таймера со звуковым сопровождением окончания времени.
8. Вывод секундомера с возможностью разделения на группы.
9. Светофор с переключением цвета.
10. Вывод календаря и часов.
11. Вывод окна для ввода текста (текстовый блок) с разделением на команды.
12. Вывод окна для рисования.

Онлайн-сервис интерактивных заданий Flippity работает без предварительной регистрации пользователя, но при этом у пользователя должна быть заранее создана учетная запись Google. Этот цифровой инструмент позволяет на основе информации электронных Таблиц Google быстро создавать онлайн-карточки с заданиями. Пользователь входит в свой аккаунт Google. Далее нужно зайти, открыв соседнюю вкладку браузера, на сайт Flippity по электронному адресу http://flippity.net/. Пользователь может добавлять изображения и видеоролики, вставив в ячейки электронной таблицы Google ссылку на изображение или видеофрагмент. Пользователь может встроить собственную аудиозапись, для этого нужно воспользоваться сторонним сервисом http://vocaroo.com/, записав или загрузив аудио на сервис.

Triventy — это бесплатный конструктор игр и викторин. Учитель может создать тест или викторину на своѐм компьютере, а ученики могут отвечать на вопросы со своих мобильных устройств или ноутбуков. Очки начисляются за правильные ответы. Дополнительные баллы начисляются за скорость ответа.

Ученики могут присоединиться к викторине, перейдя в Triv.in и после ввода PIN-кода, присвоенного вашей игре.

Создать викторину довольно легко. Вы формулируете вопрос и указываете несколько вариантов ответа, один из которых правильный. В отличие от других конструкторов, вы можете в отдельном окошке при желании ввести некоторые подсказки и объяснения к вопросам. К каждому из вопросов имеется функция загрузки изображений.

В завершении каждой викторины вы можете подвести итоги по каждому ученику.

Classtime — очень любопытный цифровой инструмент формирующего оценивания. Программа очень доступна и проста в использовании, экономит время, усилия и обеспечивает отслеживание работы учеников в течение всего занятия. Класс работает в режиме реального времени. Причѐм сервис обеспечивает индивидуальный режим работы каждого ученика.

Classtime располагает русскоязычной версией. Для работы с сервисом учителю необходимо завести свой аккаунт. Вы можете воспользоваться библиотекой или завести свои папки с заданиями. Даже в бесплатной версии сервис располагает большим количеством инструментов тестирования учащихся. Конструктор позволяет вводить в задания изображения как с компьютера, так и по ссылке из интернета, а также видео с канала YouTube.

Некоторые карантинные нововведения предлагается сохранить. Записанные видео-уроки, которые можно пересматривать несколько раз, и они будут полезны отстающим ученикам. Можно сохранить использование всевозможных он-лайн платформ, которые использовались во время карантина.

Но в любом случае, ничто из предложенных современных инновационных технологий не сможет заменить традиционный урок и учителя.

Литература

1. Котлярова А.Е. ст. преподаватель УМЦ ИКТ ГБУ ДПО ЧИППКРО http://ikt.ipk74.ru/upload/iblock/2ed/2ed96c347550edcd76b9ad93575dd51a.pdf
2. Кравцов Сергей http:// www.interfax.ru
3. Палагутина, М. А. Инновационные технологии обучения иностранным языкам / М. А. Палагутина, И. С. Серповская. — Текст : непосредственный // Проблемы и перспективы развития образования : материалы I Междунар. науч. конф. (г. Пермь, апрель 2011 г.). — Т. 1. — Пермь : Меркурий, 2011. — С. 156-159. — URL: https://moluch.ru/conf/ped/archive/17/578/ (дата обращения: 07.02.2021).
4. Смирнова Ольга «Ненастоящее образование». Как пандемия вскрыла проблемы онлайн-обучения. https://www.bbc.com/russian/vert-cap-54027632

ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ЗАМАНЧА ҺӘМ ИННАВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

Кәлимуллина Л.Ю.
ОШИ «IT-лицей КФУ»
Lilunchik1986@mail.ru

Аннотация. В статье рассматривается приложения, сайты, программы, которые могут использоваться при изучения татарского языка
Ключевые слова: технология, татарский язык, приложение, настольные игры, сайты

Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр чоры укыту-тәрбия эшенең дә барлык өлкәләренә яңача якын килү, аны яңача аңлауны таләп итә. Бу үзгәрешләр мәгариф өлкәсендә эшләүчеләр алдына яңа мәсьәләләр куя. Укытучылар бу яңарышларны тормышка ашыруда төп рольне башкаралар. Мәктәпләрнең бүгенге бурычы – хәзерге көн таләпләренә, тормыш, җәмгыять ихтыяҗларына җавап бирүче белемле, тирән фикер йөртә торган, социаль актив, карарларны мөстәкыйль кабул итә торган иҗади шәхес тәрбияләү. [3, 3]

Заман таләпләре бүгенге көндә татар телен укыту процессында да зур үзгәреш сорый. Беренчедән, телебезне саклап калу, икенчедән, балаларда телне өйрәнүгә кызыксынуны бетермәү, киресенчә, бу кызыксынуны үстерү бурычы. Бу укытучыдан зур һөнәри осталык, түземлелек һәм заман таләп иткәнчә, югары технологияләрдән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдәр булуын һәм иҗади эшли белүне таләп итә.

Педагогик эшчәнлектә иҗадилык – бу, беренче чиратта, яңалыкка, үзгәрүчәнлеккә омтылу. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне уңай кабул итү өчен, укытучының заман белән бергә атлап баруы мөһим. Бүген укытучы, иҗади шәхес буларак, күп укырга, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге яңалыклар белән таныш булырга гына түгел, ә яңа педагогик технологияләрнең иң нәтиҗәлесен сайлап алып, үзләштереп эшли белергә дә тиеш.

Соңгы елларда күп кенә яңа технологияләр тәкъдим ителде һәм гамәлгә кертелде. Аларның күбесе дәресләрдә уңышлы кулланыла. Психология фәненең соңгы тикшеренүләре шәхеснең яңа мәгълүматның 65 процентын күрү ярдәмендә үзләштерелүен ачыклады. Ул процесста укучының тыңлап утыруы гына түгел ә төрле эшчәнлектә катнашуы бик мөһим. Шуңа күрә яңа педагогик технологияләр күрү эшчәнлеге төрләренә юнәлтеләләр дә инде.

Татар теле һәм әдәбиятын яңа технологияләр аша өйрәтү – ул уку процессын яңача оештыру, ахыргы нәтиҗәләрне күзалларга омтылу, укучыларның актив эшчәнлегенә этәргеч бирү.

Бүгенге көндә халык мәгарифе икътисадын, укыту техникасын һәм технологиясен, укытуны компьютерлаштыру мәсьәләләрен өйрәнү-тикшеренү эшенә бәйле рәвештә педагогик технология, педагогик техника төшенчәләре дә актив кулланылышка керде.

Технология – фәннең яисә җитештерү өлкәсенең билгеле бер тармагында кулланылучы методлар, алымнар, ысуллар җыелмасы ул. Нәрсә соң ул педагогик технология? Педагогик технология укытуны, белемнәрне үзләштерүне, идея-фикерләрне, төрле чараларны, ысулларны планлаштыруны һәм гамәлгә ашыруны үз эченә ала. Аларның бурычы - укыту процессын, яңалыклар кертеп, даими камилләштереп тору, яңа дәреслекләр, укыту өчен кинофильмнар, компьютерларга программалар һ.б. ярдәмлекләр төзү. [1, 95]

Педагогик технология төшенчәсенә күренекле педагог-галимнәрнең аңлатмалары төрлечә. Б.Г.Лихачев фикеренчә, педагогик технология – укыту процессындагы махсус ысуллар, алымнар, психологик-педагогик юнәлешләр җыелмасы; ул – педагогик процессны оештыруның төп коралы. В.П.Беспалько педагогик технологине ―укыту процессын тормышка ашыруда эчтәлекле техника‖ дип саный. И.П.Волков бу терминны укытуның көтелгән нәтиҗәләрен тасвирлау процессы буларак карый.

Соңгы елларда белем бирү системасында заманча технологияләрдән уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр (терәк схемалар кулланып, алга китеп укыту технологиясе, белем бирүнең компьютер технологияләре, үстерелешле укыту технологиясе, проектлар методы, концентрик белем бирү технологиясе) һәм укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга юнәлтелгән педагогик технологияләр (уен технологиясе, проблемалы укыту технологиясе, аралашуга өйрәтү технологиясе) уңышлы кулланыла.

Моннан берничә еллар элек уку-укыту процессында укытучының төп эш коралы булып такта белән акбур торса, хәзер инде хәл бөтенләй башкача. Компьютер технологияләре кеше эшчәнлегенең барлык өлкәләренә дә үтеп керде. Өлеге заманча технологияләрнең мәктәпләргә, укыту процессына үтеп керү этапларын карап үтик.

1) Такта, акбур, магнитофон, плакатлар.
2) Беренче компьютерларны укучылар информатика дәресләрендә генә күреп, ул дәресләрдә аны ничек кабызырга, сүндерергә, ниндидер гамәлләр эшләргә (wordта язарга, paintта рәсем ясарга) өйрәнделәр.
3) Тормышка телефоннар, интернет актив үтеп керә башлый. Елдан-ел алар үзгәрә, яңадан-яңа кушымталар барлыкка килә, куллану мөмкинлекләре арта.
4) Мәктәпләрдә проекторлар, акыллы такталар (Smartboard) урнаштырылды. Power Point программасы белән презентацияләр эшләнә. Укучыларга аудио-видео материаллар күрсәтелә.
5) Заманча мәктәпләрдә төрле студияләр ачыла. Тавыш яздыру, видео төшерү һ.б.

Тормыш һәм уку шуның белән генә туктамый. Телефоннарда яңа кушымталар, интернетта күп төрле сайтлар, укыту ресурслары, компьютерларда программалар барлыкка килә. Өлбәттә, укытучылар җилкәсенә зур йөк ята. Беренчедән, укытучы алардан хәбәрдар булып, аларны үзе өйрәнеп чыгарга тиеш булса, икенчедән, аны дәрескә ничек итеп кертергә, ничек

кулланырга икәнен дә белергә тиеш. Шулар арасыннан иң файдалы, иң кирәкле, уңышлы материалны, ресурны сайлап алу иң авыры.

Татар теле дәресләрендә нинди программалар, кушымталар, сайтлар кулланып була соң? Аларга кыскача күзәтү ясап китик.

1) Укучылар гына түгел, олылар да тормышны телефонсыз күз алдына китерә алмыйбыз. Шул ук телефонда нинди генә кушымталар, мөмкинлекләр юк хәзер. Уеннар, онлайн китаплар уку, видеолар карау, телләр өйрәнү. Телефонда шул кушымталарга анализ ясаганда, татар теленә бәйле кушымталарның аз булуына инандым. Алар түбәндәгеләр:
   - Алга. Изучаем татарский язык
   - Ябалак – изучение татарского
   - Тренажер татарского языка
   - Русско-татарский разговорник
   - Татарский каждый день
   - Татар электрон китапханәсе
   - Әкиятләр.

   Күбесенең исемнәре рус телендә, кайбер кушымталарга керү мөмкин түгел, берничәсе башланган һәм дәвамы юк. Татар телендә уеннар аерым кушымта буларак, гомумән юк. Димәк, укучылар белән берлектә аларны булдырырга кирәк.
2) Башлангыч сыйныфларда укучы балалар өчен өстәл уеннары чыкты. Мәсәлән, ―Тәти уеннар‖, ―Туган як‖, ―Күңелле домино‖, ―Күңелле лото‖, ―Магнитлы курчак театры‖, ―Өстәл курчак театры‖, ―Хәрәкәт. Балалар‖ һәм ―Сабантуй‖. Урта сыйныфлар өчен андый өстәл уеннары юк диярлек.
3) Kahoot, Quizlet, Quizizz кушымталары, тавыш бирү өчен пультлар. Сүзләр өйрәнү һәм кабатлау, тестлар үткәрү өчен бик җайлы кушымталар.
4) Әйдә! Online – изучаем татарский проекты. Грамматика, лексика буенча кызыклы аудио-видео материаллар. Читаем на татарском бүлегендә татар язучыларының әсәрләре генә түгел, чит ил язучыларының әсәрләре белән дә танышып була. Текстлар кыскартылган, җайлаштырылган. Шулай ук аудиокитап бар, сүз һәм гыйбарәнең тәрҗемәләре һәм тест бирелгән.
5) Анателе-онлайн мәктәбе. Татар телен өйрәнүчеләргә яисә камил сөйләшергә теләүчеләргә киңәш итәргә мөмкин.

Бүгенге көндә күпчелек мәктәпләрдә күп мөмкинлекләргә ия булган интерактив такталар, барлык мәктәпләрдә дә җиһазландырылган компьютер сыйныфлары бар. Без бу өлкәдә булган яңалыклар белән танышып, аларны үз эшебездә кулланырга тырышабыз. Әмма һәрбер дәресне дә информацион технологияләр кулланып үткәреп булмый, мондый дәрескә әзерлек укытучыдан күп вакыт та таләп итә.

―Укытучының тере сүзен бернинди компьютер да алыштыра алмый‖ дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә. Бу сүзләр белән килешәм. Туган тел дәресләрен укучыларны мониторга каратып кына үткәреп булмый. Чөнки дәреснең төрле этапларында урынлы, уйланылып кулланылган компьютер

белән эш укучының укытучы һәм сыйныфташлары белән аралашуы һәм башка күп төрле эшләр белән үрелеп барырга тиеш.

Компьютер технологияләреннән уңышлы файдалану, тел һәм әдәбият фәненә иҗади якын килеп эшләү зур нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Укучыларда ана телебезгә карата мәхәббәт тәрбияли, аның байлыгын, матурлыгын, фикри тирәнлеген ачып бирә, аны мәдәниятле итә, һәрьяклап үстерә, шәхес итеп тәрбияли. Укытучы укучыга тормышта үз урынын табарга ярдәм итүче төп ышанычы булып кала.

―Шәкертләрне гыйлем белән тәрбияләү, изге шәригатьтә аңлатылган күркәм холыклар белән таныштыру һәм гадәтләндерү – укытучының беренче эше булыр,‖ – диген Р.Фәхреддин. Бүгенге укучыларның гыйлем, яхшы тәрбия алырга тулы мөмкинлекләре бар. Безгә бары тик гыйлем алуга тырышлык, теләк һәм омтылыш тәрбияләргә кирәк. Безнең кулларда балалар язмышы. Безнең укучыларыбыз, Р.Фәхреддин теләгәнчә, бөтен яктан да үрнәк балалар булып үсеннәр һәм милләтебез горурланырлык шәхесләр булсыннар иде.

Әдәбият

1. Габдуллин Г.Г. Педагогик сүзлек / Г.Г.Габдуллин, Ә.Н.Хуҗиәхмхтов. – Казан:КДПУ, 1997. – 190 б.
2. Гайфуллин В. Педагогик технологиләр / В.Гайфуллин // Мәгариф, 2000. - № 4. – Б. 7-10
3. Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик алымнар. – Тулыландырылган 2 нче басма. – К(И)ФУ АФ нәшрияты, 2012. – 137 б.
4. Колеченко А.К. Энциклопедия педагогических технологий: пособие для преподавателей. СПб.: КАРО, 2001
5. Харисов Ф. Татар телен өйрәтүдә заманча технологияләр / Ф.Харисов, Ч.Харисова // Мәгариф. – Казан, 2002. - № 8. – Б.33-36

ГЕРМАНИЯ ҺӘМ ВЕНГРИЯДӘ ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУ

Кириллова З.Н.
Казан федераль университеты
zkirillova@yandex.ru

Аннотация. В данной работе исследуется преподавание татарского языка в Германии и Венгрии. По нашим сведениям, в Германии татарский язык преподается в Свободном университете Берлина и Гиссенском университете в качестве второго тюркского языка после турецкого, а в Венгрии татарский язык изучается студентами кафедры Алтаистики Сегедского университета.
Ключевые слова: татарский язык, преподавание татарского языка, Германия, Венгрия.

Туган телебез Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясенең татар диаспоралары яши торган тәбәкләрендә генә түгел, кайбер чит илләрдә дә укытыла. Мәкаләдә Германия һәм Венгрия дәүләтләрендә татар телен укытуга кыскача күзәтү ясарбыз.

Германиядә татар теле ике югары уку йортында: Берлиндагы Азат университетының Тюркология институтында һәм Гиссен университетында укытыла. Тюрколог квалификациясе алырга теләгән студентларга татар теле төрки телләрнең берсе буларак укытыла. Студентлар дәрес вакытында татар теленнән сөйләм күнекмәләре алалар, татар халкының мәдәнияте һәм милли үзенчәлекләре белән танышалар, үзләре өчен төрки дөньяны ачалар [4, 270].

Азат университетында озак еллар дәвамында татар телен Маргарете Эрсен-Раш укыта. Ул 1990 елларда берничә тапкыр Казанга килә һәм күренекле галимә, «Чит аудиториядә татар теле» кафедрасы мөдире Ф.С. Сафиуллинадан дәресләр ала. Берлинга кайткач, үзлегеннән дә актив шөгыльләнеп, татарча бик яхшы сөйләшә башлый. Күп еллык эш тәҗрибәсенә таянып, 2009 елда ул алман телендә татар теле дәреслеген бастырып чыгара [2]. Укучыларны кызыксындырырлык итеп төзелгән, күп санлы диалоглар, оригиналь текстлар, үзенчәлекле биремнәргә бай дәреслек алманнарга татар телен өйрәтүдә гаять зур ярдәм күрсәтә.

Гомумән, Германиядә тюркология белгечлеген алучы студентлар XXI гасыр башына кадәр татар телен аерым текстларга нигезләнеп һәм грамматик үзенчәлекләрне истә калдырып кына өйрәнсәләр, яңа гасыр башыннан инде татарча сөйләшә алуның мөһимлеге беренче урынга чыга. Бу максат белән, Маргарете Эрсен-Рашның алдарак күрсәтелгән дәреслегеннән тыш, 2002 елда Михаил Коротков тарафыннан «Tatarisch Wort für Wort» («Татар теле – сүз артыннан сүз») китабы да чыга [3]. Дәреслекнең төп максаты – татар телен көндәлек аралашуда актив куллану, ә телнең барлык грамматик үзенчәлекләрен ятлау түгел. Моның белән бәйле рәвештә, төрле аралашу ситуацияләре өчен күп санлы сөйләм әйләнмәләре тәкъдим ителә. Дәреслек белән бергә, тел материалы

яздырылган диск яки кассета алу мөмкинлеге дә булу [4, 270] китапның гамәли әһәмиятен тагын да арттыра.

Азат университетында татар телен укыту эшенә шулай ук Казан дәүләт университетының «Чит аудиториядә татар теле» кафедрасы мөгаллимәләре дә шактый зур өлеш кертә. 1993 елда Ф.С. Сафиуллина университетның Тюркология институтында дәресләр уздыра. 1997 елгы җәйге курсларда аның эшен бу мәкалә авторына дәвам итәргә туры килде. 1990 еллар ахырында кафедрадан ДААД программасы буенча Германиягә киткән И. Мифтахова укуы белән бер үк вакытта Азат университетында студентларга татар телен өйрәтү белән дә шөгыльләнә башлый һәм хәзерге вакытка кадәр бу эшен дәвам итә.

Германиядә татар теле укытыла торган икенче югары уку йорты – Ю. Либиг исемендәге Гиссен университеты. Казан университеты белән 20 елдан артык хезмәттәшлек иткән әлеге уку йортында татар теле икенче төрки тел буларак өйрәтелә. Беренче төрки тел итеп төрек теле укытыла. Татар теле белән кызыксынучы студентлар өчен һәр атна саен түгәрәк үткәрелә, анда йөрүчеләр татар теле грамматикасы буенча белемнәрен тирәнәйтәләр, сүзлек байлыгын арттыру һәм сүзләрнең әйтелешен яхшырту мөмкинлеге алалар [4, 270].

Венгриядә татар теле Сегед университетында укытыла. Сегед шәһәре Венгриянең иң көньягында, Сербиядән ун гына чакрым ераклыкта урнашкан. Сегед сүзе татар телендәге «сәгать» сүзе кебек әйтелә, кайбер галимнәр фикеренчә, «көрәнчек» мәгънәсен аңлата. Сегед – венгрлар сүзе белән әйткәндә, Венгриянең өченче шәһәре. Яшәүчеләр саны чагыштырмача күп түгел: 160 меңнән артык, ләкин аларның күбесе – яшьләр, студентлар, чөнки Сегед – университет һәм институтлар шәһәре.

Сегед университетында татар теле укытылуын ишеткәч, «венгрларга татар теле ни өчен кирәк булды икән?» дигән сорау туарга мөмкин. Без бит алар турында бик аз беләбез, телләре дә фин-угыр төркеменә керә. Татарлар һәм венгрлар арасында нинди уртаклык бар? Тарихка мөрәҗәгать иткәч, шул беленде: күп гасырлар буе галимнәр арасында «венгр теле төрки телләргә керәме, әллә угыр телләренәме?» дигән бәхәс барган [7, 11]. Бары тик XIX гасыр азагында гына венгр тюркологы Й. Буденц туган телен фин-угыр телләренә кардәш дигән фикерне раслап чыга [1]. Шул вакыттан алып венгр теле Урал телләренең фин-угыр тармагына һәм аның, ханты, манси телләре белән бергә, угыр төркеменә кертеп карала [8, 549].

Ләкин венгр теленең төрки телләргә керү идеясе дә буш урында барлыкка килми. Безнең эра башында венгрларның борынгы бабалары Идел һәм Чулман елгаларының урта агымында төрки кабиләләр белән тыгыз бәйләнештә яшәгән. Хәзерге венгр телендәге төрки алынмалар нәкъ шул чордан килә икән. Гомумән, венгр милли теленең формалашуында борынгы төрки тел зур роль уйнаган. Венгр телендә урын алган күп санлы төрки алынмалар да (галимнәр фикеренчә, аларның саны 200ләп), кайбер фонетик, морфологик һәм сүз ясалышы ягыннан охшашлыклар да моңа дәлил булып тора [6, 17].

Безнең эраның IV гасырында венгр кабиләләренең бер өлеше Көнчыгыш Европаның көньягына юнәлә, көнбатыштарак урнашкан кабиләләр исә шул җирләрдә кала һәм әкренләп төркиләр арасында таралып бетә. Күчеп киткән угро-венгрлар IX гасыр ахырында хәзерге ватаннары урнашкан территориягә килеп керәләр. Сугышчан венгрлар бу җирләрдә яшәгән славяннарны һәм авар кабиләләрен үзләренә буйсындыралар, күпчелеген юкка чыгаралар [7, 9]. 2016 елда венгрлар «Ватанга ия булу»ларының 1120 еллыгын билгеләп үттеләр. Карпат бассейнында яши башлагач, венгрлар христиан динен кабул итәләр, агачка чокып язудан латин алфавитына күчәләр. Әкренләп венгр теле төрки телләрдән ераклаша бара...

Шулай да венгрлар үзләренең үткәненә битараф кала алмыйлар, алтай телләрен, шул исәптән татар телен дә игътибардан читтә калдырмыйлар. Бу эшкә бигрәк тә Сегед университеты зур өлеш кертә. Аның тарихына күз салсак, университетка Сегедтә нигез салынмый, ул 1921 елда Коложвар шәһәреннән күчерелә, чөнки бу җирләр I Бөтендөнья сугышыннан соң Румыниягә бирелгән була. Коложвар шәһәрендә үк университетның Алтай телләре кафедрасы була. Аның белән Габор Балинт җитәкчелек итә, ул – татар теле буенча да күп хезмәтләр язган галим. Ләкин Сегедкә күчкәннән соң, Алтай телләре кафедрасы яңадан оештырылмый. Бу хәл озак еллар дәвам итә. Кафедраның кабат эшли башлавы төрки телләр тарихы, тибет, монгол телләре белгече академик Рона Таш исеме белән бәйле. Аның тырышлыгы белән 1974 елда фин-угыр кафедрасында Алтай телләре бүлеге ачыла. Ун елдан соң, 1984 елда, бу бүлек кафедра дәрәҗәсенә ирешә. 1992 елдан кафедра белән профессор Арпад Берта җитәкчелек итә (2008 елда вафат – З.К.). Ул Идел буе төрки телләре, аларның тарихы, моннан тыш, борынгы венгр кабиләләренең атамалары белән шөгыльләнә. Татар диалектлары буенча алман телендә зур күләмле ике китабы басылып чыккан. Барлык кыпчак телләрен диярлек белгән Арпад Берта кафедрада эшләү дәверендә студентларга ел саен яңа тел укыта.

Кафедрада эшләүче күренекле галимнәрдән профессор Мария Иваничны аерып күрсәтергә мөмкин. Ул Госманлы империясе, Кырым ханлыгы тарихлары, кырым татарлары һәм венгр бәйләнешләре, төрек дипломатикасы белән шөгыльләнә. Моннан тыш, кафедрада яшь галимнәр – венгр милләтеннән Ева Кинчес-Надь һәм Ласло Карой, Казахстаннан килгән Раушан, Бурятиядән Баярма, Төркиядән Фигән һ.б. студентларга дәрес бирә.

Студентларга килсәк, һәр ел саен кафедрага 8-10 студент кабул ителә. Ләкин аларның иң акыллылары, сәләтлеләре һәм тырышлары гына укуын дәвам итә ала, калганнарын җитәкчеләр рәхимсез рәвештә кафедрадан чыгаралар. Уку дәверендә студентлар борынгы төрки, чагатай, төрек, казах, үзбәк, якут, бурят, уйгыр язма истәлекләре телен, һәр ел саен берәр яңа тел: чуваш, кумык, караим, сары уйгырлар, татар, кырым татарлары һәм монгол телләрен өйрәнәләр.

Кафедрадагы укытучы һәм студентларны бик борчыган бер проблема бар: тирән белем алып чыккан студентларга ахырдан эш табуы җиңел булмаячак. Шуңа күрә студентларның кайберләре бер үк вакытта башка кафедрада да укый. Шулай да студентлар төшенкелеккә бирелмиләр, телләрен өйрәнгән

халыклар янына барып эшләү теләкләре дә бар. Казан һәм татарлар да шул исемлеккә керә.

Казан һәм Сегед университетлары арасындагы турыдан-туры бәйләнешләр 1970 еллар уртасыннан башлана. Шул вакыттан алып Арпад Берта, Клара Адьягаш, Эве Чаки, Адам Мулнер һ.б. венгр галимнәре һәм укытучылары, шулай ук студентлар Казан университетына килеп, берничә ай дәвамында дәресләр ала. 1980 елда исә Казан университеты профессоры Фәһимә Хисамова Сегед университетында бер ай фәнни стажировка үтә, күренекле галим Рона Таштан тарихи фонетика, төрки телләрне классификацияләү буенча дәресләр ала.

1988 елда Казан һәм Сегед университетлары арасында дуслык һәм хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелып, 1994 елда ул яңартылгач, ике ил арасында турыдан-туры белгечләр алмашу мөмкинлеге тагын да артты. 1995-1996 елларда Казан университеты доценты Мөслимә Шәкүрова Сегед университеты студентлары белән татар теленнән дәресләр алып барды. 1996-1997 елларда аның эшен бу мәкалә авторы дәвам итте. Кызганычка каршы, икътисади авырлыклар сәбәпле, хәзерге вакытта Сегед белән Казан университетлары арасындагы бәйләнешләр өзелде [5, 83-85]. Ләкин киләчәктә ике як өчен дә файдалы булган бу багланышлар кабат яңартылыр дигән теләктә калабыз.

Күренгәнчә, татар теле чит илләрдә төрле дәрәҗәдә һәм билгеле бер максатларны күздә тотып укытыла. Тикшерелгән илләрдә аның югары уку йортларында тюркология яки алтаистика кафедраларында өйрәтелүен билгеләп үтәргә кирәк.

Әдәбият

1. Budenz J. Az ugor nyelvek ősszehasonlitó alaktana. – Budapeşt, 1884. – 94 l.
2. Ersen-Rasch M.I. Tatarisch. Lehrbuch für Anfängerund Fortgeschrittene. – Wiesbaden: Harrassowitz, 2009. – 238 s.
3. Korotkow Michael. Tatarisch Wort für Wort. – Bielefeld: Reise-Know-How-Verlag, 2002. – 192 s.
4. Бартоломэ Р. Изучение современного татарского литературного языка как иностранного в вузах Германии // Филология и культура. Philology and Culture. – 2013. – № 3 (33). – С. 268-271.
5. Кириллова З.Н. Маҗарстанда татар теле // Язык и литература в поликультурном пространстве: Материалы региональной научно-практической конференции (16-17 декабря 2005 года). Вып. 2. – Бирск: Бирск. гос. соц.-пед. акад., 2005. – С. 83-85.
6. Кириллова З.Н. Төрки-татар һәм маҗар телләре: охшаш һәм аермалы яклар // Фән һәм тел. – 2006. – № 4. – Б. 14-17.
7. Майтинская К.Е. Венгерский язык. Ч. I. Введение. Фонетика. Морфология. – М.: Изд-во АН СССР, 1955. – 304 с.
8. Языкознание. Большой энциклопедический словарь / Гл. ред. В.Н.Ярцева. – М.: Большая Российская энциклопедия, 1998. – 685 с.

ПРИМЕНЕНИЕ ИННОВАЦИОННЫХ ТЕХНОЛОГИЙ НА УРОКАХ РУССКОГО ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ В СОВРЕМЕННОЙ ШКОЛЕ

Лукаш Л.В.
Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение города Ульяновска «Средняя школа №29»
ljudmila-luk@lenta.ru

Аннотация. Сейчас многое изменилось в образовании. Но и современный учитель задумывается о том, как сделать урок интересным, как увлечь ребят своим предметом, как создать на уроке ситуацию успеха для каждого ученика. Объективной необходимостью в условиях современного образования становится освоение учителем и применение им на своих уроках инновационных технологий при обучении детей. В статье рассматриваются эффективность, задачи, особенности, технологии, приѐмы инновационного обучения.
Ключевые слова: Инновация, педагогическая технология, инновационное обучение, ИНСЕРТ.

В последние годы всѐ чаще поднимается вопрос о применении инновационных технологий в образовательном процессе. Сегодня основная цель обучения — это не только накопление учеником определѐнной суммы знаний, умений, навыков, но и подготовка школьника как самостоятельного субъекта образовательной деятельности. ИННОВА´ЦИЯ [от лат. innovātio обновление, перемена] - нововведение, новшество. Инновацио´нный - относящийся к инновации, инновациям. Понятие «инновационная педагогическая технология» включило в себя всѐ, что касается совершенствования учебного процесса. Педагогическая технология – это исследование с целью выявить принципы и разработать приѐмы оптимизации образовательного процесса путѐм анализа факторов, повышающих образовательную эффективность путѐм конструирования и применения приѐмов и материалов, а также посредством оценки применяемых методов. Эффективность инновационного обучения заключается в следующем:

- соответствие концепции гуманизации образования;
- преодоление формализма, авторитарного стиля в системе преподавания;
- использование личностно-ориентированного обучения;
- поиск условий для раскрытия творческого потенциала ученика;
- соответствие социокультурной потребности современного общества самостоятельной творческой деятельности.

Инновационные технологии позволяют реализовать одну из основных целей обучения русскому языку и литературе - дать возможность перейти от изучения предмета как системно-структурного образования к изучению его как средства общения и мышления, а учебно-познавательную деятельность

перевести на продуктивно-творческий уровень. Задачи инновационного обучения[2]:
- оптимизация учебно-воспитательного процесса;
- создание обстановки сотрудничества ученика и учителя;
- выработка долговременной положительной мотивации к обучению;
- тщательный отбор материала и способов его подачи. Инновационные технологии позволяют регулировать обучение, направлять его в нужное русло.

Особенностями инновационного обучения являются [1]:
- работа на опережение, предвосхищение развития;
- открытость к будущему;
- направленность на личность, её развитие;
- обязательное присутствие элементов творчества;
- партнёрский тип отношений: сотрудничество, сотворчество и пр.

В основе инновационного обучения русскому языку и литературе в современной школе лежат следующие технологии [3, с. 15]:
- развивающее обучение;
- проблемное обучение;
- развитие критического мышления;
- дифференцированный подход к обучению;
- создание ситуации успеха на уроке.

При использовании инновационных технологий в обучении русскому языку и литературе успешно применяются следующие приёмы [3, с.16]:
- ассоциативный ряд;
- опорный конспект;
- ИНСЕРТ (интерактивная система записи для эффективного чтения и размышления);
- мозговая атака;
- групповая дискуссия;
- чтение с остановками и вопросы Блума;
- кластеры;
- синквейн;
- «Продвинутая лекция»;
- эссе;
- ключевые термины;
- перепутанные логические цепочки;
- дидактическая игра;
- лингвистические карты;
- лингвистическая аллюзия (намёк);
- исследование текста;
- работа с тестами;
- нетрадиционные формы домашнего задания.

Таким образом, использование современных инновационных образовательных технологий, методов, приёмов – это объективная

необходимость и условие достижения высокого качества современного образования.

Литература

1.Инновационные методы преподавания русского языка. - [Электронный ресурс]. – Режим доступа: https://articlekz.com/article/12306

2.Курочко Е.А. Применение инновационных технологий на уроках русского языка и литературы в условиях современной общеобразовательной школы. - [Электронный ресурс]. – Режим доступа: https://urok.1sept.ru/articles/640880

3.Масляк С.И. Инновационные технологии на уроках русского языка и литературы. – [Электронный ресурс]. - Режим доступа: http://www.e-osnova.ru/PDF/osnova_14_48_13458.pdf

ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘТНДӘ СЫЙНЫФТАН ТЫШ УКУ ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ РОЛЕ

Мансурова З.Җ.
Башкортстан Республикасы Бүздәк районы Каран мәктәбе
man.zul2014@yandex.ru

Аннотация: в данной статье рассказывается о роли внеклассных учебных занятий на татарском языке, о развитии речи. В качестве примера приводится внеурочная деятельность по татарскому языку ―Сокровища народа - богатство души‖, и кукольный театр, который организован в рамках данных занятий.
Ключевые слова: внеурочная деятельность, творческая деятельность, родной язык, личность, кукольный театр.

Һәр бала өчен мәктәп - аның тормышында иң мөһим урыннарның берсе, чөнки нәкъ менә биредә ул төрле фәннәр буенча төп белемнәрне үзләштерә, алга таба өлкәннәр тормышы өчен кирәкле тәжрибә ала, төрле социаль рольләрне үзләштерә, үзен мөстәкыйльлеккә әзерли. Баланың киләчәктә уңышы аның мәктәп тормышы вакытында яраклашуына, индивидуальләшүенә һәм интеграцияләнүенә бәйле. Әмма, кызганычка каршы, барлык балалар да үз сәләтләрен мөстәкыйль рәвештә ача һәм тормышка ашыра алмый, шуңа күрә күп нәрсә аның якын даирәсенә, ә нәкъ менә мәктәпкә һәм гаиләгә бәйле. Әлеге социаль төркемнәр әгъзаларының балага социальләшергә ярдәм итүе һәм аны барлык интеллектуаль һәм иҗади башлангычларда хуплавы бик мөһим. Мәктәпнең төп бурычларыннан берсе – балага ярдәм итү, аның сәләтен үстерү, үз-үзенә ышаныч бирү, шул рәвешле аны төрле яхшы гамәлләргә этәрү. Шулай итеп, мәктәп баланың сәләтләрен һәм максатларын гамәлгә ашыру өчен җирлек әзерли. Бу җәһәттән, икенче буын ФБДБС таләпләре буенча, дәрестән тыш эшчәнлек уку программасында үз урынын алды.

Мәктәбебездә телебезгә мәхәббәт тәрбияләү, халкыбызның гореф – гадәтләре, йола-бәйрәмнәре белән таныштыру, сәнгатьле уку күнекмәләре үстерү һәм, иң әһәмиятлесе, аралаша белергә өйрәтү максатыннан оештырылган ―Халкым хәзинәләре – күңел байлыгы‖ сыйныфтан тыш уку дәресләренең оештырылуы зур әһәмияткә ия. Бу дәресләрдә укучылар туган телне тирәнтен өйрәнү белән берррәттән, башка бик күп мәгълүматлар алалар, нәфис сүз белән эш итергә өйрәнәләр, төрле конкурсларда катнашып, үзләренең көчләрен сынап карыйлар. Болардан тыш алар иҗат эшчәнлеге белән дә шөгыльләнәләр.

Сыйныфтан тыш уку дәресе – программа тарафыннан билгеләнеп куелган, расписаниедә күрсәтелгән әдәбият дәресләренең эченә керә торган, укучыларның мөстәкыйль укуы белән идәрә итү дәресе [2, 344]. Мондый эшчәнлекне алып баручы укытучы өчен, иң беренче чиратта, дәресне дөрес оештырырга кирәк. Чөнки нәкъ менә эшчәнлекнең төрле формалары аша бала үзендә моңарчы билгеле булмаган яңа талантлар һәм сәләтләр ача ала. Ә

аларны ачкач, ул үз көченә ышанырга, курыкмаска, элек беркайчан да эшләмәгән эшне башкарырга, яшьтәшләре белән контактка җиңел кирәргә шартлар тудырачак.Сыйныфтан тыш эшчәнлек һәр балага үз шәхесенең уникальлеген аңларга, үз шәхси сәләтләрен билгеләргә, үзе өчен тормыш принципларын, мәнфәгатьләрен һәм кыйммәтләрен билгеләргә мөмкинлек бирә [4, 41]. Шулай ук бала үз гамәлләренә бәя бирергә өйрәнә, димәк, анда үз гамәлләре өчен җаваплылык тою, кешелеклек сыйфатларын формалаштыру, җәмгыятьтә яхшылык, матурлык кайгырту, үзара ярдәм, яхшылык кебек әхлакый категорияләрнең әһәмиятен аңлау процессы бара.

Мәктәбебездә ―Халкым хәзинәләре – күңел байлыгы‖ класстан тыш уку дәресенең 2020-2021нче уку елында бер юнәлеше булып, театр эшчәнлеге белән дә таныштыру тора. Театр – сәнгатьнең бер төре. Ул үз эченә әдәбият, музыка, бию, сынлы сәнгатьне берләштерә. Бүгенге укучылар сүз дөньясыннан ерактарак. Чөнки балалар күбрәк компьютер артында утырырга,сериаллар карарга, эстрада музыкасы тыңларга яраталар.

Башлангыч сыйныф укучылары әле яңа гына ачылып килүче чәчәкләр төсле. Аларны берләштерүдә, зурлар белән аралашырга өйрәтүдә, бәйләнешле сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үз-үзен тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур. Баланың бөтен тормышы – уен. Уенда бала тирә-юнь турында, җәмгыятьнең законнары, кешеләрнең үзара аралашу матурлыгы турында мәгълүмат алып кына калмый, ә бу дөньяда яшәргә, аралашырга, тормышта үз урынын табарга өйрәнә. Ә бу баланың игътибарлы, яхшы хәтерле, дөрес, матур сөйләшә белүен таләп итә. Персонажлар сөйләме өстендә даими эшләгәндә, сөйләм күнекмәләре үсә, баланың сүз байлыгы арта, аваз культурасы, интонацион сөйләм формалаша. Башкарылачак роль баланың чиста, аңлаешлы итеп сөйләвен таләп итә. Сәхнәләштерелгән уеннар, әкиятләр барышында бала персонажлар өчен кайгыра, үзен алар урынына куя, булышу ысулларын таба, яхшылык һәм явызлыкка үзенең карашын белдерә. Моңардан тыш, укучылар татар әдипләренең әсәрләре белән таныша, укый, эчтәлеген исендә калдыра һәм үзенең күңеле аша уздыра.

Шула итеп, укучыларның белем һәм күнекмәләре, өйрәнгән һөнәрләренең ни дәрәҗәдә үзләштерелгән булуы, шөгыльләрдә һәр баланы күзәтү, проект эшләре, өйрәнгән әсәрләрне сәхнәләштерү аша өйрәнелә. Өйрәнгән спектакльләрне башка сыйныф укучылары, балаларның ата-аналары каршында күрсәткәч, тамашачының алкышлап, үз фикерләрен әйтеп бәя бирүе, спектакльнең ни дәрәҗәдә сыйфатлы һәм тамашачы өчен үтемле булуын раслый (спектакльдән соң тамашачыларга үз фикерләрен белдерергә сүз бирелә) һәм түгәрәкнең эшенә дә бәя булып тора. Соңгы шөгыльдә балалар үзләре, һәр уйналган роль турында фикер алышалар, уңай һәм кимчелекле якларын билгелиләр. Курчак театры аеруча әдәбият һәм татар теле, әйләнә-тирә дөнья, технология, музыка дәресләре белән тыгыз үрелеп бара. Бу предметларның һәм сыйныфтан тыш уку дәресенең нәтиҗәсе балаларның белем һәм күнекмәләренә комплекслы бәя бирә.

Әдәбият

1. Григорьев Д. В. Внеурочная деятельность школьников. // Методический конструктор: пособие для учителя–М.: Просвещение, 2010.
2. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – 367 б.
3. Таишева С. Ана теленнән читләшү.// Мәгариф. – 2017. – № 4. – 31-35 б.
4. Шәмсетдинов Г., Вәлиуллин М. Хәерле көн укытучы!// Мөгалимнәргә, методистларга, тәрбиячеләргә методик кулланма. – Казан: ―Идел –Пресс‖ полиграфия –нәшрият комплексы, 2004. – 224 б.

ПОДГОТОВКА БИ- И ПОЛИЛИНГВАЛТЬНЫХ ПЕДАГОГИЧЕСКИХ КАДРОВ В КАЗАНСКОМ ФЕДЕРАЛЬНОМ УНИВЕРСИТЕТЕ

Мирзагитов Р.Х.
Казанский федеральный университет
mirza_ramil@mail.ru

Аннотация. В статье рассматриваются вопросы подготовки би- и полилингвальных педагогических кадров для общеобразовательных учебных заведений.

Ключевые слова: Казанский федеральный университет, би-и полилингвальные кадры, педагоги, родно (татарский) язык.

На базе высшей школы национальной культуры и образования им. Габдуллы Тукая Казанского Федерального университета готовятся специалисты в области татарского языка и литературы, иностранных (английского, китайского, турецкого) языков, дизайнеры, преподаватели музыки и с 2018-2019 учебного года осуществляется подготовка би- и полилингвальных педагогических кадров для национальных образовательных учреждений Республики Татарстан. (Т.е. с 2018 года учителей билингвалов и с 2020 года учителей полилингвалов)

Казанский Федеральный университет является уникальным примером реализации полилингвального образования в Республике Татарстан и в Российской Федерации, в котором осуществляется обучение будущих учителей на трех языках – русском, татарском и английском. Идея полилингвального обучения состоит в том, что наряду с родным языком другие языки используются как средство учебно-познавательной деятельности в процессе профессиональной подготовки. В университете идет подготовка учителей для школ с русским языком обучения, с татарским языком обучения, а также для инновационных образовательных учреждений, в которых английский язык используется как инструмент образования и самообразования учащихся.

Практическую значимость реализации полилингвальных образовательных программ трудно переоценить:

- они обеспечивают преемственность национальной культуры, ее дальнейшее развитие, опираясь на культурологические и фольклорно-исторические аспекты воспитания и обучения, способствуют функциональному использованию татарского языка, как языка науки;

- служат надежным педагогическим средством интернационализации высшего и постдипломного образования, способствуют импорту и экспорту передовых образовательных программ и технологий, содействуют формированию в стенах университета национальной научно-педагогической элиты.

Открытие по направлению 44.03.05 Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки) программ, ориентированных на подготовку

квалифицированных педагогических кадров, готовых к ведению образовательной деятельности в условиях билингвальной и полилингвальной образовательной среды сыграет важную и, безусловно, положительную роль в укреплении языковой культуры в РТ.

Опыт Казанского федерального университета по реализации подобных программ может представлять существенный интерес для других национальных республик, где разработка аналогичных образовательных программ будет способствовать повышению качества языковой подготовки, развитию национальной культуры, укреплению тенденций интернационализации научно-педагогической сферы

Для того чтобы подать документы на эти направления абитуриенты заключают договора о целевом обучении с общеобразовательными организациями Республики Татарстан, в которых в дальнейшем, по окончании обучения, они обязуются отработать не менее 5-и лет. Одновременно между Казанским федеральным университетом и данными общеобразовательными организациями Республики Татарстан заключается договор о целевом приеме этих студентов на обучение.

Уникальность нашей работы заключается в том, что для работы с обучающимися привлекается профессорско-преподавательский состав со всего вуза, используются ресурсы собственных лицеев и татарской гимназии №2 имени Шигабутдина Марджани при КФУ. В настоящее время рассматривается вопрос о прохождении педагогических практик также и в полилингвальном комплексе «Адымнар – путь к знаниям и согласию» города Казани.

Обучение осуществляется за счет средств бюджета Республики Татарстан, т.е за обучение платят не сами студенты, а республика.

Все студенты очной формы обучения получают стипендии по республиканской программе стипендиальной поддержки педагогических кадров в размере 15 тыс. руб. в месяц. В первом семестре эту стипендию получают все студенты независимо от результатов ЕГЭ. Со второго семестра для того чтобы получать стипендию необходимо сдать зимнюю сессию на оценки хорошо и отлично, при этом отличных оценок должно быть не менее 50%.

Следует также отметить и то, что в кратчайшие сроки при поддержке попечителей и средств университета созданы современные модельные классы и инновационный Центр цифровых образовательных технологий EduTex.

В основу подготовки полилингвального учителя нами положена методика предметно-языкового интегрированного обучения (CLIL), успешно применяемая в различных странах Европы и Азии (Нидерланды, Испания, Германия, Китай, Малайзия, Япония и т.д.). Она позволяет осуществлять преподавание и изучение учебных предметов через неродной язык, а также параллельно развивать знания и навыки в предметной области, языковые компетенции и когнитивные способности.

Совместно с профильными институтами КФУ были разработаны специальные образовательные программы, имеющие двойной профиль. Данные

программы позволяют в наибольшей степени удовлетворить потребности Республики Татарстан в педагогических кадрах на би- и полилингвальной основе различной предметной специализации и повышения конкурентоспособности выпускников, способных осуществлять педагогическую деятельность сразу по двум предметам. Очная форма предполагает срок обучения 5 лет, заочная – 6 лет.

Все программы ориентированы на подготовку специалиста, ведущего профессиональную деятельность в би- и полилингвальной образовательной среде. Для достижения этого, кроме углубленного изучения иностранного (английского) языка, в учебные планы были включены такие дисциплины как «Основы билингвального обучения и двуязычия», «Основы преподавания предметов на иностранном языке», «Альтернативные методы преподавания на иностранном языке», «Татарский язык в профессиональной коммуникации», «Практика по созданию математических текстов на татарском языке (LaTeX, MathType)», «Технологии би- и полилингвального развития детей дошкольного возраста» и др. Помимо этого, студенты изучают историю, литературу и культуру Татарстана.

В 2020-2021 учебном году на 1 – 3 курсах всего по проекту подготовки би- и полилингвальных кадров обучаются 386 студентов.

Из них на дневном отделении обучаются 156 студентов-билингвалов (2-3 курсы) по профилям подготовки: «Математика и информатика», «Математика и физика» «История и обществознание», «Начальное образование и преподавание предметов в начальной школе на английском языке», «Музыка и дополнительное образование», «Иностранный (английский) язык и второй иностранный язык»; 82 студента полилингвала по профилям «Математика и иностранный (английский) язык», «История и иностранный (английский) язык», «Начальное образование и иностранный (английский) язык». и 148 человек на заочной форме обучения из числа выпускников педагогических колледжей, профиль подготовки «Дошкольное и начальное образование».

Что касается географии студентов-билингвалов: 81 студент имеют договора со школами и гимназиями города Казани, много студентов обучаются из близлежащих городу Казани районов (Арский, Сабинский, Кукморский, Тюлячинские районы). Всего представлено 39 муниципальных районов Республики Татарстан.

Если говорить о тех профилях по которым планируется набор в 2021 году, то по проекту подготовки би- и полилингвальных кадров планируем набрать пять групп по 25 человек на дневное отделение по направлению «Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)». Профили следующие: «Математика и Иностранный (английский) язык», «Информатика и Иностранный (английский) язык», «История и Иностранный (английский) язык», «Начальное образование и Иностранный (английский) язык», «Иностранный (английский) и второй иностранный язык». И на отделение заочного обучения планируем набрать одну группу из выпускников педагогических колледжей в количестве 25 человек на направление

«Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)» «Начальное образование и дошкольное образование (в билингвальной образовательной среде)»

В настоящее время совместно с Министерством образования и науки Республики Татарстан разработан и проект Государственной Программы Республики Татарстан по подготовке педагогических кадров для работы в билингвальных и полилингвальных образовательных организациях РТ на 2020-2025 годы.

ИЗУЧЕНИЕ ФРАЗЕОЛОГИЧЕСКИХ ЕДИНИЦ НА УРОКАХ РОДНОГО ЯЗЫКА (РУССКОГО)

Мигранова Л.Ш.
Стерлитамакский филиал БашГУ
lilimigranova@gmail.ru

Аннотация. В статье рассматриваются особенности содержания учебных предметов «Родной язык (русский)» и «Родная литература (русская)», представлены материалы, описаны приемы работы над фразеологическими единицами на уроках родного языка (русского). Лингвокультурологический комментарий способствует пониманию семантики фразеологизма, знакомит с культурой, историей народа, раскрывает его менталитет, расширяет фоновые знания учащихся.
Ключевые слова: родной язык (русский), родная литература (русская), культуроведческая компетенци, фразеологические единицы.

Во всех школах Российской Федерации ведется преподавание новых учебных предметов «Родной язык (русский)» и «Родная литература (русская)», которые входят в образовательную область «Родной язык и родная литература» (согласно ФГОС).

На этом уроке осуществляется изучение русского языка как родного из числа языков народов РФ. В 2018 году появилась примерная программа по учебному предмету «Русский родной язык». Урок родного (русского) языка имеет свою специфику, он не должен быть продолжением или уроком углублѐнного изучения основного курса «Русский язык». «Важнейшими задачами курса являются приобщение обучающихся к фактам русской языковой истории в связи с историей русского народа, формирование представлений школьников о сходстве и различиях русского и других языков в контексте богатства и своеобразия языков, национальных традиций и культур народов России и мира; расширение представлений о русской языковой картине мира, о национальном языке как базе общезначимых нравственно-интеллектуальных ценностей, поведенческих стереотипов и т.п., что способствует воспитанию патриотического чувства, гражданственности, национального самосознания и уважения к языкам и культурам других народов нашей страны и мира» [4: 6].

В 2019 году вышли учебные пособия для 5 – 9 классов (авторский коллектив: О.М. Александрова, О.В. Загоровская, С.И. Богданов, Л.А. Вербицкая, Ю.Н. Гостева, И.Н. Добротина, А.Г. Нарушевич, Е.И. Казакова, И.П. Васильевых), направленные на расширение представлений учащихся об отражении в русском языке истории, материальной и духовной культуры русского народа. Следовательно, содержание предмета ориентировано на соизучение языка, культуры и истории народа, т.е. должно быть организовано культуроориентированное изучение русского языка, направленное на усиление

лингвокультурологической составляющей. Исходя из сказанного, следует, что базовой является культуроведческая (лингвокультурологическая) компетенция, «в состав которой входит осознание родного языка как формы выражения национальной культуры, понимание взаимосвязи языка и истории народа, национально-культурной специфики русского языка, освоение норм русского речевого этикета, культуры межнационального общения; формирование способности объяснять значение слов с национально-культурным компонентом» [2: 100].

В 2020 году разработана примерная программа по учебному предмету «Родная литература (русская)». Эта дисциплина, как «родной (русский) язык», имеет свою специфику: отведѐнное учебное время на изучение данного предмета не может рассматриваться как время для углублѐнного изучения основного курса литературы, содержание программы не включает произведения, изучаемые в основном курсе литературы.

«Специфика курса родной русской литературы обусловлена, во-первых, отбором произведений русской литературы, в которых наиболее ярко выражено их национально-культурное своеобразие (например, русский национальный характер, обычаи и традиции русского народа), духовные основы русской культуры; во-вторых, более подробным освещением историко-культурного фона эпохи создания изучаемых литературных произведений, расширенным историко-культурным комментарием к ним [3: 9 – 10].

Культуроведческий подход к изучению языка связан с понятиями «языковая картина мира», «языковая личность», «диалог культур».

Картина мира есть целостный глобальный образ мира, который является результатом всей духовной активности человека и возникает в ходе всех его контактов с миром. Языковая картина мира является отражением окружающей действительности и воспроизводит, передает национально-культурную специфику мировидения народа.

Языковая личность обладает знаниями об окружающей действительности, закрепленными в языке, т.е. является носителем определенной картины мира. Личность развивается в истории, культуре и языке нации, которая выступает как один из компонентов общественной среды. И, конечно, личность охватывает всю систему общественно значимых отношений и ценностей. При этом отметим, что единого подхода к определению ценностной системы нации не существует. Миропонимание и речевая деятельность человека определяется той национальной культурой и средой, в которой он родился, был воспитан, живет. Языковая личность формируется на протяжении всего периода обучения в школе, и прежде всего в процессе изучения родного языка как источника развития духовных способностей школьников.

Обучение родному (русскому) языку должно осуществляться в процессе диалога культур, предполагающего знание русской культуры, культур наиболее многочисленных народов России, а также традиционных европейских культур.

Уроки родного (русского) языка, таким образом, должны рассматриваться как уроки воспитания нравственности, приобщения к национальной культуре,

формирования национального самосознания. «Язык есть исповедь народа, в нём слышится его природа, его душа и быт родной…», – писал П.А. Вяземский.

Как известно, национальная самобытность, специфика языка наиболее ярко отражена во фразеологии, именно фразеологические единицы в большей степени способны передать особенности миропонимания, мировосприятия народа.

В учебном пособии «Русский родной язык» за 6 класс [5: 45 – 51] в § 6 «Отражение во фразеологии истории и культуры народа» учащиеся расширяют свои представления о фразеологизмах, об источниках их происхождения.

Формированию культуроведческой (лингвокультурологической) компетенции учащихся способствует художественный текст. Текст помогает учащимся постигать эстетическую ценность языковых явлений, знакомит с индивидуальным стилем писателя.

Отметим также, что учащиеся должны уметь видеть фразеологизмы в тексте, уметь понимать и объяснять их значение, а также определять функцию употребления фразеологических единиц в тексте. К тому же, чтобы правильно, уместно употреблять фразеологизмы, необходимо хорошо понимать ситуацию и внеречевые условия, созвучные с фразеологизмом, знать речевой узус. Следует подчеркнуть, что поскольку фразеологический оборот реализует свое значение только в связи с другими словами контекста, то именно в тексте он и представит весь свой потенциал, раскроет оценочные смыслы.

Предлагаем обратиться к повести Э.Е. Фоняковой «Хлеб той зимы». Ученики «откроют новое имя» – познакомятся с писателем Фоняковой Эллой Ефремовной (1934 – 2012). «Хлеб той зимы» (1970) – воспоминания автора (маленькой героини) о «блокадном» голоде, холоде, о человеческой стойкости, силе духа – о блокадном быте ленинградцев.

Язык книги «Хлеб той зимы» Э.Е. Фоняковой яркий, живой, насыщен фразеологическими и паремиологичекими единицами. На страницах повести встречаются такие устойчивые сочетания: *зуб на зуб не попадает, (не) приходить в голову, хоть убейте, из уст в уста, взбредет в голову, ругать на чем свет, как в воду глядеть, показать, не повести бровью, где раки зимуют, вставать в тупик, оторвать с руками, бес (не) попутал, комок в горле, ломать голову, строить куры, болтать языком, ни в какие ворота не лезет, взять языка, глазом не моргнуть, разбить врага (немца), не знать куда глаза деть, держать марку, вывести на чистую воду, ставить на карту, душа не лежит, быть на побегушках, собраться с духом, взять в толк, ловить себя на мысли, нет худа без добра, суд да дело, страх берет, чему быть – того не миновать* и др.

Рассмотрим наиболее интересные фразеологические единицы, представленные в повести Э.Е. Фоняковой. Функциональный анализ фразеологизмов помогает увидеть ситуацию употребления, раскрывает такие свойства, как экспрессивность, эмоциональность.

I. «– Мам, мне не сложить эти циферки!

– Сложишь.

– Не могу.

– Тебе достаточно ясно все объяснили. Теперь изволь думать сама.

– Ну, мам!..

– *Поломай, поломай себе голову*. Потрудись. Не сдавайся.

Легко ей говорить! А мне совсем не хочется *«ломать» себе голову*» [6].

Полагаем, что работу с фразеологизмом можно построить таким образом: 1. Определить значение устойчивого сочетания. *Ломать [поломать, изломать] [себе, всю] голову.* Напряженно думать, стараясь найти решение какой-либо задачи, проблемы [1: 364].

2. Объяснить, как образован фразеологизм, на чем основан.

В основе образа лежит метонимия: голова – источник ума, рассудка, в ней хранятся все наши знания, вся информация, голова осознается как инструмент мыслительной деятельности человека. Образ основан на сходстве оболочки головы – черепа – с коробкой. Фразеологизм передает стереотипное представление о напряженном обдумывании какой-либо сложной ситуации, об усиленном поиске ее разрешения [1, 365].

3. Подобрать эквиваленты из других языков, например, из башкирского, татарского, чувашского (диалог с представителями других культур), а также из других европейских языков.

Сходные образные выражения (по структуре и по значению) встречаем и в других языках, в частности в башкирском и татарском языках («баш вату»), в немецком и французском языках (букв. пер. «ломать голову»), в английском языке (букв. пер. «бить свои мозги палкой»), в испанском языке (букв. пер. «греть себе голову»).

Увидеть национальное своеобразие фразеологических единиц в русском и других языках позволяет образ, положенный в основу номинации, что мы наблюдаем на примере представленных фразеологических оборотов. Подобное обусловлено особенностями мировидения, миропонимания, мироощущения каждого народа, своей историей, культурой, обычаями, традициями, жизненным укладом, жизненной философией, своими ценностями и образными представлениями, т.е. своим особым взглядом на мир.

В следующих речевых ситуациях учащиеся должны самостоятельно рассмотреть и проанализировать фразеологические единицы по такому же образцу (если затрудняются в определении значения оборота, следует обратиться к фразеологическому словарю). Рассмотреть источники происхождения, подобрать эквиваленты можно предложить в качестве домашнего задания.

III. «Узнав, что я за один раз съела «всю гомеопатию», мама *лишилась дара речи*, а папа побежал было вызывать скорую помощь.

– Так я же ее еще неделю назад съела, – невинно сообщила я.

– Ну все, – трагическим голосом сказал папа. – Все. Там же яд.

Взрослые люди такие горошинки принимают по одной в день, а десять штук *могут убить слона*!

– Значит, я сильней слона» [6].

IV. «– Что же это творится?! *Грабеж среди бела дня*!.. «Где же бела, когда сейчас темная ночь», – сонно размышляю я» [6].

Необходимо рассказать школьникам и о стилеобразующем средстве, используемом авторами в своих произведениях, – каламбуре (языковой игре), построенном на обыгрывании фразеологических оборотов. Языковая игра заключается в том, что слово, входящее во фразеологизм, понято буквально, в его основном значении. Маленькая героиня воспринимает устойчивое сравнение в прямом смысле («я сильней слона», «где же бела, когда сейчас темная ночь»). Разъяснение образа фразеологизма, ситуации возникновения способствует пониманию связи между прямым значением оборота (прототипом фразеологизма) и переносным, метафорическим значением самого фразеологизма.

Итак, обучение родному языку (русскому) должно быть основано на приобщении к национальной культуре, должно строиться на воспитании интереса к мировой культуре, на формировании национального самосознания учащихся и на становлении системы общечеловеческих ценностей.

Литература

1. Большой фразеологический словарь русского языка / Отв. ред. В. Н. Телия. – 4-е изд. – М.: АСТ-ПРЕСС КНИГА, 2009. – 784 с.

2. ВоителеваТ.М. Культуроведческий подход к обучению русскому языку как способ формирования ценностных ориентаций школьников // Вестник МГГУ им. М.А. Шолохова. – 2014. – № 3. – С. 98-103.

3. Примерная программа по учебному предмету «Родная литература (русская)» для образовательных организаций, реализующих программы основного общего образования. – URL: https://fgosreestr.ru/.

4. Примерная программа по учебному предмету «Русский родной язык» для образовательных организаций, реализующих программы основного общего образования. – URL: https://fgosreestr.ru/.

5. Русский родной язык. 6 класс: учеб. пособие для общеобразоват. организаций / [О.М. Александрова и др.] – М.: Просвещение, 2019. – 144 с.: ил.

6. Фонякова Э.Е. Хлеб той зимы. – Новосибирск, 1970. 224 с. – URL: http://lib.ru/PROZA/FONQKOWA_E/hleb.txt

«КАРА» КОМПОНЕНТЛЫ ТАТАР МӘКАЛЬЛӘРЕНӘ ЛИНГВОМӘДӘНИ АНАЛИЗ

Мөгътәсимова З.А.
Казан федераль университеты
Ziliyu@mail.ru

Аннотация. В статье рассматриваются особенности семантики колоронима «кара» в татарской паремиологии. Проведенный анализ прилагательного цветообозначения обосновывает универсальность категории цветовосприятия татарского фольклора и достаточно четко выявляет национально специфические особенности.
Ключевые слова: татарский язык, паремия, колоративная лексика, цветообозначения, лингвокультурологический анализ, паремиологическое пространство.

Һәр халыкның төсләргә үз мөнәсәбәте. Ул аның үткәне, дини карашлары, җәмгыятьнең нинди үсеш баскычында торуы, ырым һәм ышанулары белән бәйле. Әйтик, чегәннәрнең чуар төсләр яратуын кайбер галимнәр аларның Һиндстанда яшәгәндәге кастасы (алар югары катламнарның күңелен күрүче җырчылар, биючеләр булган), ыруглык җәмгыятеннән ары китә алмаулары нәтиҗәсе дип саныйлар.

Татар теленең лексик-семантик системасында да төс атамаларының шактый компактлы төркеме аерылып тора. Алар иң борынгы атрибутив сүзләрне тәшкил итәләр. Әлеге берәмлекләр әйләнә-тирә чынбарлыкны чагылдыруда актив катнашалар. Шул ук вакытта төсләр татар халкының дөньяга карашы һәм яңа сүзләр ясау өлкәсендәге фикер үзенчәлекләрен дә характерлыйлар.

Мәкаләдә татар теленең «кара» компонентлы мәкальләренә игътибр итәрбез. Эштә мәкаль контекстында кара сыйфатын куллану үзенчәлеге һәм закончалыгы ачыклана, әлеге сыйфатының семантик үзенчәлекләре анализлана.

Мәкальләр – халык мәдәнияте һәм менталитеты турындагы иң кыйммәтле мәгълүматлар чыганагы. Аларның күпчелеге халык аңы стереотипларын чагылдыра. Үз формасы буенча кыска мәкальләр мораль-этик нормалар системасын гына түгел, бәлки кешенең тышкы һәм эчке дөньясы турында белемнәр тупланмасын да тәшкил итәләр.

Мәкаль текстларындагы берәмлекләрне лексик коннотация үзенчәлекләренә бәйле анализлаулар уңышлы. Атап әйткәндә, халык иҗатыннан тыш та сүзгә хас билгеләрне, шулай ук фольклор дөньясының һәм аның теленең бөтен системасы белән бәйле «ассоциатив тезаурус»ны да исәпкә алырга кирәк.

Кара төсне белдерә торган «кара» сыйфатына татар телендә полисемантик билгеләр хас. Төп семантик билгеләре тискәре: явыз, куркыныч, авыр, караңгы,

рәхимсез һ.б. санала, һәм кайчак аларның кайсы өстен булуын билгеләү дә авыр. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә мондый мәгълүматлар китерелгән:

«Кара – 1. Корым, күмер төсендәге; киресе: ак. 2. Гадәттәге яки төп төскә караганда куерак төстәге, карңгырак төстәге. 3. Караңгы, яктылык төшми торган, куе. 4. Кояш яндырудан аклыгын югалткан яки гомумән ак булмаган (кешедә бит, тән төсе турында). 5. Керле, пычрак, юылмаган. 6. Квалификациясез, аерым осталык сорамый торган (авыр, пычрак, гадәттә физик эшкә карата кулланыла). 7. Революциягә кадәр гади халык арасыннан чыккан, укымаган, надан кеше. 8. Фаҗигале, шатлыксыз, авыр (тормыш, көннәр һ.б.). 9. күч. Бик көчле. 10. күч. Явыз, мәкерле, җинаятьчел» [4, 232].

Борынгы төрки сүзлектә «кара» сүзе бары төсне генә аңлата. Сүзлектә борынгы төрки форманың kara икенлеге билгеләнә һәм мисал китерелә: sariğ taş nağıd tözlük ol qara taş kivan tözlüg ol (сары таш табигатьтән Венера белән бәйле, кара таш Сатурн белән бәйле ул).

«Кара» сыйфаты татар мәкальләрендә «усал, явыз» мәгънәсенә ия. Мәсәлән, *Йөзе ак дип алданма, эче кара булмасын.*

Кешенең шәхси үзлекләрен характерлаучы мәкальләрдә кара тискәре коннотация тапшыру өчен кулланыла: *Кара сакалың кая барсаң да калмас; Су һәр нәрсәне агарта, йөз карасын агарта алмый; Казан карасы китәр, намус карасы китмәс.*

Татар мәкальләрендә хатын-кыз матурлыгын тасвирлаганда, «кара» сыйфаты уңай коннотациядә кулланыла: *Кара кызның дәрте бар; Кашы кара, күзе кара, карасам күзем кала; Ак матур – чак матур, Кара матур – бик матур.*

Халык авыз иҗатының башка жанрларындагы кебек үк, «кара» сыйфаты да «җир» сүзенә даими эпитет булып тора: *Кара җирне яманлама, кермә торган җиреңдер; Җир кара да, үлән үстерә, кар ак та, эт чылата; Кара җиргә кар яуса, карны күрү бер зәвык; Кара җирдән кар китсә, җирне күрү бер зәвык.* Шулай итеп, без «кара» сүзенең «җир»нең төсен түгел, сыйфатын билгеләвен күрәбез.

Татар телендә «кара» сыйфаты халыкны символлаштыра һәм, «гади, танылмаган» дигән мәгънәгә ия булып, еш кына дөньяда билгеле булмаган кешегә карата кулланыла. Тикшерелгән материалны анализлау күрсәткәнчә, «гади, танылмаган» дигән мәгънәләргә тагын «укымаган, белемсез» мәгънәләре дә өстәлә: *Кара халык – кара сарык.*

Татар мәкальләрендә «кара» сыйфаты зоологик һәм ботаник атамалар составында килә: *Итче ак сарыкны да, кара сарыкны да суя; Кара җир астында кара елан да туйган.*

Мәкальләр арасында «кара» сыйфатына уңай бәя бирә торганнары да күзәтелә. Мәсәлән, *Һәрбер кара нәрсә шакшы булмас, һәрбер ялтыраган яхшы булмас.*

Л.Г.Бедоидзе фикеренчә «кара» күп кенә телләрдә бәхетсезлек, явызлык символы булып тора [1, 70].

Р.Р.Закиров исә үзенең хезмәтләрендә, А.Веселовскийга нигезләнеп, «кара» барлык халыкларда да матәм, шом, гайгы, тормышның караңгы яклары белән ассоцияцияләнүен [2, 30]. Татар мәкальләрендә дә бу фикерне раслый торган мисаллар табарга була: *Дус кара көндә беленер; Кара көндә дус булган арага кылыч чапса да аерылмас; Ил белән кара көн бәйрәм; Көннән якты нәрсә юк, кара болыт басмаса.*

Тикшеренү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, күп кенә төсләр атамаларының күчерелмә мәгънәләре барлыкка килү аларның билгеле бер символикага ия булуы белән аңлатыла. Татар мәкальләрендә «кара»ның символик мәгънәсе бертөрле түгел. Биредә «кара» сыйфаты, мәсәлән, Европа мәдәниятләрендәге кебек абсолют тискәре мәгънәдә генә чагылыш тапмый, ә катлаулырак мәгънәләрне дә үз эченә ала.

Әдәбият

1. Бедоидзе Л.Г. Фразеологические еденицы с компонентом цвета в немецком, русском и осетинском языках: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Ростов-на-Дону, 1997. – 241 с.

2. Закиров Р.Р. Феномен цвета во фразеологии (на примере английского, русского и татарского языков). – Казань:ТГГПУ, 2009. – 246 с.

3. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Өч томда. Казан: Татар. кит. нәшр., Т.1. —1959. — 913 б.; Т.2. 1963. — 959 б.; Т.З. 1967. — 1013 б.

4. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: ―Матбугат йорты‖, 2005. – 842 б.

КЫТАЙ ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЕ ФОНЕТИКАСЫ: ЧАГЫШТЫРМА АСПЕКТТА

Мөхәммәтшина А.Ф.
ИФМК, КФУ
alisafaizovna99@mail.ru

Генеалогик классификациядә татар теле төрки телләрнең кыпчак төркеменә керә, ә кытай теле кытай-тибет телләре гаиләсенә карый, иң зур һәм күпсанлы халык сөйләшә торган төркем булып тора. Димәк, бу ике тел – ике төрле төзелешле система, шунлыктан алар арасында уртаклыкларга караганда аермалар күбрәк булуы табигый.

Икенче телне өйрәнгәндә, укытуның фонетик этабы әһәмиятле, ул өйрәнеләчәк телнең нигезендә ята. Фонетика чит телне өйрәнгәндә туган тел йогынтысына бик нык дучар ителә һәм һәрвакыт күп хаталар белән характерлана.

Икенче чит телдә фонетиканы камил өйрәнергә, туган тел йогынтысын ничек җиңәргә, кешеләр белән аралашырга? Бу сораулар икенче телне үзләштерергә теләүчеләр өчен гаять мөһим. Татар һәм кытай телләренең фонетикалары шактый аерылса да, аларның уртак яклары да бар. Бу бүлектә без татар һәм кытай телләренең төп фонетик үзенчәлекләрен, аның охшаш һәм аермалы якларын карап үтәрбез. Әмма кытай теле авазлардан түгел, ә иҗекләрдән торганга күрә, без башта ике телнең иҗекләр төзелешенә бәйле үзенчәлекләрне карап үтик.

Иҗек структурасы. Иҗек – сөйләмнең иң кечкенә әйтелеш берәмлеге. Ул бер сузык аваздан яки сузык аваз белән янәшә килгән тартык аваздан тора ала. Татар телендә иҗекнең ачык һәм ябык төрләре бар. Ачык иҗек дигәндә без күз алдында сузык авазга тәмамланган иҗекләрне күздә тотабыз, ә ябык иҗек тартык авазга бетә. Һәр телнең үзенә генә хас иҗек калыплары бар. Хәзерге татар телендә 6 төрле иҗек калыбы саклана: С, ТС, СТ, ТСТ, СТТ, ТСТТ (С – сузык аваз, Т – тартык аваз).

Кытай иҗеген татар теленнән аера торган мөһим үзенчәлекләрне аерып күрсәтергә мөмкин:

1. Татар телендә иҗектә авазларның төрле тәртиптә килүе рөхсәт ителә. Татар теленең теләсә нинди авазы да диярлек иҗекнең башында, уртасында яки ахырында килергә мөмкин. Кытай телендә иҗек хасил итүче авазлар төгәл тәртиптә урнаштырыла. Тулы кытай иҗеге түбәндәгечә төзелә: тартык аваз, иҗек ясамый торган сузык, иҗек ясый торган сузык, соңгы ярымсузык яки борын сонанты; һәм шуның нигезендә башка дәрәҗәдәге структур элементларга бүлгәләнергә мөмкин: *duan* иҗеге үз эченә *d* инициален, *uan* финален ала.
2. Кытай телендә бер иҗектә ике тартык берничек тә бер-бер артлы килә алмый, ә сузыкларның бергә килүе – гадәти күренеш. Татар телендә исә тартык һәм сузык аваз чиратлашып килә, шулай ук ике тартык авазның сүз уртасында һәм ахырында бер-бер артлы килүе дә мөмкин.

3. Кытай телендә барлык авазлар да алда әйтелгән тәртиптә була алмый (мәсәлән, [фи], [ты] бергә килә алмый). Бу кытай телендә иҗекләр саны чикләнү белән билгеләнә (алар барлыгы 400 тирәсе).

4. Кытай телендәге иҗек дүрт төрле ысул, дүрт төрле көй яки интонация белән әйтелергә мөмкин. Бу *тон* дип атала. Тон дигәндә без аның озынлыгын, югарылыгын күз алдында тотабыз. Ул тулаем иҗеккә яки аерым авазга түгел, ә финальга, ягъни башында тартыгы булмаган авазлар төркемчәсенә хас. Дүрт тоннан тыш сирәк булса да, нуль тоны да очрый ала. Бу инде финальне кыска, басым ясамыйча әйтелү дигәнне аңлата.

5. Кытай телендә тон мәгънә аеру, мәгънә белдерү функцияләрен үти. Әгәр иҗекне дөрес икенче тон белән әйтсәң, гомумән икенче сүз чыга, икенче мәгънә бирелә (әни - 妈 - mā, җитен -麻 – má, ат -马 - mǎ, ачуланырга - 骂-mà, сорау кисәкчәсе - 吗 -ma). Шулай итеп, тон – ул иҗек өстендә белдерелә торган уникаль фонологик берәмлек.

6. Кытай теленең иҗекле характеры һәм иҗек структурасының аермалы үзенчәлекләре минималь әһәмиятле берәмлекләрне аерып чыгару принципларын билгели. Монда татар телендәге кебек аерым аваз (фонема) түгел, ә гадәттә силлабем яки слогофонема дип атала торган тоны билгеләнгән иҗек килә.

Иҗек ягыннан шактый аерымлыклар булса да, бер охшаш якны да билгеләп үтәргә кирәк. Кытай телендә иҗек күп дигәндә дүрт аваздан тора (*suan*), татар телендә дә шундый ук сыйфатны күрәбез (*карт*).

Фонетик һәм фонологик системалар. Кытай һәм татар телләре авазлар системасында охшашлыклар зур. Аларны аерым карыйбыз.

Төп монофтонг сузыкларны алганда, алар ике телдә дә бер үк дисәк, ялгышмабыз. Ләкин кытай телендә аларның саны алты, ә татар телендә – унике (өчесе рус теленнән). Кытай телендәге алты сузык аваз татар телендә дә бар (таб.1.1):

Таблица 1.1. Кытай теленең сузык авазлары һәм аларның татар эквивалентлары

Кытай теле	Татар теле
[a]	[а] яки [ә]
[o]	[о] (рус теленнән)
[i]	[и] яки [ы]
[u]	[у] яки [ү]
[ü]	[ү] яки [ө]
[e]	[ы] яки [ә]

Татар телендә калган тагын [ө], [о], [э] һәм рус теленнән кергән [ы], [э] авазларына охшаш сузыклар кытай телендә очрамый.

Таблицада туры килгән авазларның әйтелеше дә бик охшаш:

[a] – [а] (дан – bāng (帮));

[ә] – [a] (тән – kàn (看));

[о] – [o] (сон – dòng (动));

[и] – [i] (дин – qíng (晴));
[ы] – [i] (тын – chī(吃));
[ү] – [u] (күз – qù (去));
[у] – [u] (кунак – zhù (祝));
[ү] – [ü] (күңел – nǚ'ér (女儿));
[ө] – [ü] (көл – lǜ (绿));
[ы] – [e] (кыр – chē (车));
[ә] – [e] (фән – rén (人)) һ.б.

Шулай ук татар һәм кытай телләрендә охшаш яңгырашлы дифтонглар да бар. Аларның шулай ук күтәрелмә һәм төшерелмә төрләре була. Мәсәлән:

[йа] – [ya] (куя – yālì (压力);
[йу] – [yu] (баю –yùndòng (运动);
[wa] – [ua] (куа – suān (酸);
[ай] – [ai] (сай – bǎi (百);
[әй] – [ei] (җәй – fēi (飞);
[әw] – [ao] (дәү – táopǎo (逃跑) һ.б.

Тартык авазларны карасак, татар телендә тартык авазлар ясалу урыны, ясалу ысулы һәм тавыш катнашу яки катнашмау буенча бүленәләр. Татар теленең 28 тартык авазы 24 хәреф белән белдерелә. Ясалу урыны буенча: ирен, ирен – ирен, ирен – теш; тел, тел – теш, тел – аңкау, тел уртасы, тел арты, кече тел (увуляр), йоткылык (фарингаль), бугаз (ларингаль). Ясалу ысулы ягыннан йомык, саф, аффрикат, өрелмәле, ярым – йомык, борын, ян – як, калтыраулыга бүленәләр. Акустик аспектта шаулы, сонор, яңгырау, саңгырау булалар.

Татар телендә 28 тартык, алынма һәм диалект сүзләр составында кулланыла торган 5 тартык ([ц], [тч], [щ], [в], [х]), 25 тартык фонема һәм рус алынмаларыннан күчкән 3 фонема ([в], [ц], [щ]) бар. Татар теленең үзенә генә хас булган тартыклары: [къ], [гъ], [ң], [ж], [h], [‘].

Галимнәр кытай телендәге башлангыч тартыкларның санын егерме бер дип күрсәтә: [p], [b], [t], [d], [k], [g], [c], [dz], [ch], [dzh], [q], [j], [f], [s], [sh], [ɕ], [h], [r], [m], [n], [l] (таб. 1.4). Кытай теленең консонантизм системасын 3 билге характерлый: ясалу урыны, ясалу ысулы һәм сулап чыгару (придыхательность). Ясалу урыны буенча кытай телендә ирен-ирен, ирен-теш, теш-теш, альвеоляр, тел алды, тел алды-какуминаль, палаталь һәм тел арты тартыкларын аералар. Ясалу ысулы буенча шартлаулы, борын, фрикатив, аффрикатив һәм ян-як тартыклар була.

Глайдлар дип күрсәтелгән [y], [w] һәм тел арты [ng] авазлары кытай телендә инициальлар итеп каралмый.

Татар һәм кытай теленең тартык авазларының үзара аермаларын караганда берничә пунктка тукталырга кирәк.

Беренчедән, кытай телендә калтыраулы [р] авазы юк, шуңа күрә кытай кешеләре [р] авазы урЫнына еш кына [л] авазын кулланалар. Шулай ук тел-теш [з] авазы урнына аффрикат [dz] яки [dzh] авазлары әйтелә. Рус теленнән кергән

[в] авазы татар теленә охшаш, ә кытай телендә глайд булып каралган [w] кебек яңгырый.

1. Абдрасимова А.Е., Жиембай Б.С. Казахские и русские заимствования в языке турецкой диаспоры Республики Казахстан // Вестник Евразийского национального университета имени Л.Н. Гумилева. Серия. Политические науки. Регионоведение. Востоковедение. Тюркология. – №1 (126)/2019. – С.157-163.

2. Жолдасбеков М., Шаймердинова Н.Г., Калдыбаев М.С., Каликов Р.К., Жиембай Б.С., Диханбаева А.Е. История, язык и этнокультура тюркских народов Казахстана. Монография. – Нурсултан: «Free Flight», 2020. – 237 с.

3. Ӡазаӡ тілінің сөздігі. Анықтамалық басылым. Жалпы редакциясын басҙарған Телғожа Жанұзаков. – Алматы: Дайк-пресс, 1999. – 775 б.

4. Ӡайдаров Ә., Оразов М. Түркітануға кіріспе. – Алматы: Арыс, 2004. – 360 б.

5. Меметов А. Источники формирования лексики крымскотатарского языка. – Ташкент: Фан, 1988. – 196 с.

6. Сайын Ж. Лингвокультурные заимствования в разговорной речи турецкой диаспоры Казахстана// Сборник материалов Международной научно-практической конференции. «Современные проблемы тюркологии: язык - литература - культура» – М., РУДН, 2016. – С.496 -500.

7. Шаймердинова Н.Г. Тюркские народы Казахстана: гагаузы, их история, язык, традиции // Вестник КарГУ им. Букетова. – № 2 –2017. – С. 74-81.

8. Шаймердинова Н.Г. Жиембай Б., Абдрасимова А. Ӡазаӡстандағы Ӡырым татарлары тілінің ерекшеліктері // Туған жер идеясы және ӡоғамдыӡ сананың жаңғыруы ғылыми конференциясының материалдарының жинағы. – Алматы, Arna-B баспасы, 2019. – 225-232 б.

9. Шаймердинова Н.Г. Татарская диаспора Казахстана: социокультурные аспекты//Материалы международной научно-практической конференции «Литература и худ.культура тюркских народов в контексте Восток-Запад». – Казань, КФУ, 2015. – С.590-601.

СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ТЕХНОЛОГИЯСЕ НИГЕЗЕНДӘ ЯЗУЧЫ ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮ

Хөснетдинов Д.Х., Сагдиева Р.К.
Казан федераль университет
Domer1982@mail.ru

Аннатоция. В статье рассмотрены основные здоровьесберегающие технологии применяемые в школе. Раскрыты возможности их применения. Проведена классификация здоровьесберегающих технологий.
Ключевые слова: язык, метод, технология

Сәламәтлек – иң зур байлык. Укучыларның яшьтән үк сәламәт булып үсүе бик мөһим. Сәламәтлек әле ул авырмау гына түгел, үзеңне тыныч, гармонияле итеп хис итү; башка кешеләргә карата мәрхәмәтле, яхшы мөнәсәбәттә булу.

Сәламәтлек технологиясе – укучының сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга юнәлтелгән чаралар, алымнар, ысуллар системасы.

Күптөрле галимнәрнең хезмәтләрендә укыту ысулларының төрлечә төркемләнүе китерелә. Шулар арасында И.Я.Лернер һәм М.Н.Скаткин тарафыннан тәкъдим ителгәне күпчелек тарафыннан яклана: аңлату-күрсәтү методы, репродуктив метод; проблемалы укыту методы; өлешчә эзләнү яки эвристик метод; тикшерү методы.

Укучыларның яшь үзенчәлекләренә, белем дәрәҗәләренә һ.б. факторларга бәйле рәвештә, укытучы аларның тиешлесен сайлап ала. Язучы телен өйрәткәндә дә, бу методларның төрлесе кулланыла ала.

Аерым бер темаларны аңлатканда репродуктив метод, ягъни укытучы сөйләвенә нигезләнгән ысул уңышлы була. Аерым алганда, кушма җөмлә турында күзаллау булдыру дәресендә бу ысулга мөрәҗәгать итәргә була. Аңлату-күрсәтү методы кулланылганда, укытучы, күрсәтмә әсбаплардан (таблица, схема, рәсемнәр һ.б.) файдаланып, төрле мисаллар ярдәмендә өйрәнә торган материалны укучыларга аңлата, шул ук вакытта укучыларның танып-белү эшчәнлеген активлаштыруны да күздә тота. Бу метод күләме ягыннан зур булмаган, укучылар өчен кыен, авыр аңлашыла торган темаларны яки тел күренешләрен өйрәткәндә кулланыла ала. Язучы телен өйрәтүдә бу ысул – иң мөһиме. Мәсәлән, лексика бүлеген үткәндә, Ә.Еники әсәрләреннән рухи һәм физик сәламәтлек турындагы фразеологизмнар, синтаксис бүлеген үткәндә, Бәдретдин һәм аның сабакталашларының мәдрәсәдәге көндәлек режимы турындагы җөмләләрне укып анализлауда, ягъни иң күләмле, төп темаларны өйрәнгәндә, аңлату-күрсәтү ысулы аеруча әһәмиятле. Моның өчен синтаксис буенча таблица һәм схемаларга (алар дидактик хезмәтләрдә дөнья күрде) мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Әлеге юнәлештәге эштә компьютер технологияләре дә ярдәмгә килә. Бу төр дәресләрдә компьютер технологияләре белән берррәттән, сәламәтлек саклау технологиясен бергә кулланырга мөмкин. Ә.Еникинең —Гөләндәм туташ хатирәсе‖ әсәре буенча спекталь карап, артистлар телендәге гади сөйләм

сүзләрен тыңлап анализларга мөмкин. Шулай ук фонетика бүлеген үткәндә дә спектакльне карап, авазлар әйтелешен, аваз үзгәрешләрен тикшерергә мөмкин. Билгеле, бу метод кулланылганда, укучылар пассив гына утырырга тиеш булмый, укытучы, төрле сораулар биреп, аларның игътибарын җәлеп итәргә, активлаштырырга тиеш була. Авазлар орфоэпиясе турында өйрәнгәндә дә, тел чисталыгы мәсьәләләренә тукталу мөһим. Димәк, сәламәтлек саклау технологиясе шулай ук гамәлгә ашырыла.

Өлешчә эзләнү ысулын кулланганда, укучыларның аң эшчәнлекләре төп урында тора, алар, укытучы җитәкчелеге астында, аерым бер күренеш буенча эзләнәләр, нәтиҗәләр ясыйлар, аннан соң белемнәрне гомумиләштерәләр. Сүз төркемнәренә караган мәгълүматны шул рәвешле бирергә мөмкин. Укытучының юнәлеш бирүче сораулары ярдәмендә, укучылар өйрәнелгән сүз төркемнәре, аларның грамматик категорияләрен турында искә төшерәләр, аларның үзенчәлекләрен билгелиләр, җөмләдәге синтаксик вазыйфаларын әйтәләр, шуннан соң укытучы тарафыннан яңа сүз төркеменә билгеләмә бирелә.

Болардан тыш, карточкалар белән эш, тестлар, әдәби әсәрдән я булмаса газета я журналлардан сәламәтлек саклау темасына караган җөмләләр язып алу, викторина һ.б. шундый эш алымнарын куллану кушма җөмлә синтаксисын өйрәтү дәресләрен нәтиҗәле итәргә булыша.

Фонетика турында гомуми төшенчә булдырганнан соң, балаларга авазлар, аерым алганда тартык һәм сузык авазлар турында мәгълүмат бирелә. Бу татар телен укытуда дәвамчанлык һәм эзлеклелек принцибына нигезләнеп башкарыла. Сузык авазларның классификациясе, алга таба тартыклар классификациясе турында мәгълүмат китерелә. Дәресләрнең шушы этабында татар һәм рус телләрендәге авазларны үзара чагыштырып өйрәтү әһәмиятле һәм максатка ярашлы. Моның өчен төрле биремнәр, күнегүләр тәкъдим итәргә мөмкин. Мәсәлән, яңа теманы аңлату дәресендә үк, аваз үзгәрешләре, аларның транскрипциядә бирелеше турында искә төшереп китү дә уңышлы. Шуннан соң, интерактив такта ярдәмендә әйтелеш белән язылыш арасындагы аермалыкларны табарга тәкъдим итеп була:

Сәламәтлек – җәүһәр, ләкин тиз югала.

Бурычын яшергән бөлгән, авыруын яшергән үлгән.

Башта җөмләләрнең мәгънәләре аңлатыла. Аннары грамматик сүзләр транскрипциядә күрсәтелә. Шул ук вакытта сүзләрнең орфоэпиясе аңлатыла. *Сәламәтлек* сүзенең язылышы нинди кагыйдәгә буйсынуы ассызыклана.

Төрле сүз төркемнәрен өйрәткәндә, татар һәм рус телләрендә морфологик категорияләрне үзара чагыштырып өйрәткәндә, төрле күнегүләр эшләү барышында аларны аера белү күнекмәләре формалаштырыла. Мондый төр күнегүләр, әлбәттә, белем һәм күнекмәләрне ныгыту һәм йомгаклау, тикшерү этапларында кулланыла ала.

Сәламәтлек кешенең туган табигатенә дә бәйле, шуңа күрә дә рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында укучы татар төркемнәрендә кушма җөмлә синтаксисын өйрәткәндә, аналитик һәм синтетик җөмләләрне үзара чагыштырып өйрәтү дә әһәмиятле. Дәреслектә дә аналитик һәм синтетик

җөмләләрне чагыштырып өйрәнү күздә тотыла. Бу очракта күрсәтмәлелеккә мөрәҗәгать итү уңышлы дип санала.

Әдәбият

1. Смирнов Н.К. Здоровьесберегающие образовательные технологии и психология здоровья в школе. /Н.К. Смирнов // М.:АРКТИ.-2005.- С 320.
2. Соловьева Н.И. Концепция здоровье сберегающей технологии в образовании и основы организационно-методические подходы ее реализации. / Н.И.Соловьева // ЭКО. – 2004. – № 17. – С. 23-28.
3. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Русчадан Н.К.Нотфуллина тәрҗ. – Казан: Мәгариф, 2002. – 367 б.

УНИВЕРСАЛЬ УКУ ГАМӘЛЛӘРЕН ФОРМАЛАШТЫРУ ПОЗИЦИЯСЕННӘН, ЗАМАНЧА ЧИТ ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕ ПРОЕКТЛАШТЫРУ

Шаймухаметова Р.Р.
МБОУ «Татарско-Ямалинская ООШ»
rushaniya81@yandex.ru

Аннотация. Иглиз философы Джон Дьюның шундый сүзләре бар «*Өгәр дә без бүген кичәге көндәге кебек укытсак, без балаларның киләчәген урлыйбыз*». Минемчә, бу сүзләр бүгенге яңа стандартларның максатын чагылдыра. Бүгенге көндә укытучыларның максаты, заман таләпләрен тотып, беренче чиратта, укучы шәхесен формалаштыруда. Укучы конкрет дисциплиналар буенча белем алып кына калмый, ә аларны көндәлек тормышта, алга таба укуында файдаланырга да өйрәнә. Башкача әйткәндә, мәгариф системасы баланы белемле итү хакында гына түгел, аңа күнекмәләр бирү, аны эшкә өйрәтү турында да кайгырта.

Төп сүзләр: укыту, проектлаштыру, заманча укыту

Билгеле булуынча, яңа стандартлар уку предметының реаль тормыш белән бәйле булуын да аерым игътибарга ала. Укучы бала алган белемнәрен тормышта иркен куллана белергә, килеп туган мәсьәләләрнең чишелешен эзли, таба белергә тиеш. Заманча дәресләрдә исә шушы максатны гамәлгә ашыру өчен, укучыларда универсаль уку гамәлләрен формалаштырырга кирәк. Укытучы һәр балага шәхси якын килеп эшләгәндә генә, бала белемне аңлап үзләштерә. Укучы каршына нинди дә булса мәсьәлә куелган икән, ул аны ни өчен чишәргә икәнен аңларга, бу мәсьәләне чишкәннән соң, эшнең соңгы нәтиҗәсен күрә белергә тиеш. Бүгенгесе көндә барлык фән укытучылары, шулай ук инглиз теле укытучылары алдына укучыларда махсус белем һәм күнекмәләр генә түгел, универсаль уку гамәлләре формалаштыру максаты да куела. Заманча инглиз теле дәресе укучыларны шәхси, регулятив, танып-белү, коммуникатив УУГ белән коралландыруны таләп итә.

Дәрескә әзерләнгән вакытта, мин дә, башка укытучылар кебек, үз алдыма ике сорау куям: нәрсәгә өйрәтергә һәм ничек укытырга? Белемем буенча татар теле һәм чит тел укытучысы буларак һәм дә 15 ел чит тел укытып, мин бу телләрнең күп кенә охшаш якларын таптым. Шулай ук күп кенә очракларда миңа рус теленә дә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Бу технологик алымны грамматик темалар белән танышканда куллану отышлы. Мин әлеге алымны үз дәресләремдә танып белү УУГ формалаштыруда бик актив кулланам. Гади генә мисал китерик, сыйфат дәрәҗәләре белән танышкан вакытта, мин укучыларның татар һәм рус телләрендә алынган белемнәренә таянып эш итәм. Белгәнебезчә, 3 телдә сыйфат дәрәҗәсе бар, сүзләрнең аффикслары үзгәрә һәм бу сүзләр ярдәмче сүзләр белән ясала. Бу бигрәк тә башлангыч сыйныф укучылары өчен бик уңышлы алым. Беренчедән, әлеге метод өйрәнелә торган телләрнең

үзенчәлеген, грамматик һәм лексик структураларындагы охшашлыкларны һәм аерымлыкларны тирәнтен үзләштергән очракта бигрәк тә файдалы. Икенчедән, татар теле мәһитендә тәрбияләнгән укучыларны исә татар, рус телендәге белемнәрен инглиз теле дәресләрендә кулланулары табигый ихтияҗ формасында алып барыла (таблица рәвешендә чагыштырып бирү яхшырак хәтердә кала, икенчедән, аларның татар һәм рус телләрендә алган белемнәре инглиз телен үзләштерергә ярдәм итә). Шулай ук бу алымны тәртип санын, фигыльнең заман формаларын, алмашлыкларны, исемнәрнең күплек санын өйрәнгәндә һәм башка бик күп кенә очракларда кулланып була.

Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләргә килгәндә, чит тел укытучыларына бүгенгесе көндә зур бурыч куела. Без төрле яклап камил, иҗади үзүсешкә сәләтле, милли гореф-гадәтләр, Россия һәм Бөтендөнья культурасы кыйммәтләре нигезендә тормышта үз урынын тапкан шәхес тәрбияләргә тиешбез. Бүгенге поликультуралы һәм полилингваль дөньяда алар турыдан-туры мөстәкыйль эшчәнлек алып барырлык, җаваплы, оештыруга сәләтле укучылар булырга тиешләр. Шуңа күрә дә бүгенгесе көндә дәүләт бу адымны балалар бакчасыннан ук башларга кирәклеген зарур дип тапты. Район башлыгының да фикерләрен, таләпләрен исәпкә тотып, киләчәктә авыл балалар бакчаларында да чит телләр укытыла башлаячагы безне бик сөендерде. Бу, әлбәттә, киләчәктә аларда шәхескә кагылышлы УУГ формалаштыруда җиңеллек тудырачак. Алар кечкенәдән —Минем өчен чит тел өйрәнүнең нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорауларга җавап табачаклар, үз халкы культурасы белән беррәттән, башка халыкларның культурасына, тарихына хөрмәт белән караячаклар.

Чит тел дәресләрендә дә, башка фәннәрдәге кебек, регулятив уку гамәлләре план буенча эшләргә юнәлеш бирә, эшчәнлекне оештыру мөмкинлеге бирә, танып-белү процессы белән идарә итәргә булыша. Үзбәя, дустыңа, дәрескә бәя кую кебек алымнар белән беррәттән мин дәресләремдә үзмаксат куюны отышлы саныйм.

Алда санап үтелгән УУГ ләре заманча дәрес проектлаштыруда зур роль уйныйлар. Әмма чит тел өчен иң кирәге ул укучыларда коммуникатив УУГ формалаштыру. Татар мәктәпләрендә укучы балаларга чит тел укытуда коммуникатив методны төп юнәлеш итеп алсак, уңышка ирешергә мөмкин.Үземнең тәҗрибәдән чыгып әйтәсем килә: балалар дәрестә грамматик күнегүләрне, язма эшләрне эшләүгә караганда, нинди дә булса да мәсьәлә буенча сөйләшү, проект эшләре, экскурсияләр, диалогларны рольләргә бүлеп сөйләү, картина, видеоязмалар буенча әңгәмәләрне күпкә яратып башкаралар. Рольле уеннар алар өчен күпкә кызыклырак һәм бу эшләрнең нәтиҗәсе зур.

Коммуникатив УУГен формалаштыру юлларын дөрес оештырганда, ул укучыларның тел өйрәнүгә карата мөнәсәбәтләрен уңай якка үзгәртә, белемнәрнең аңлылыгына этәрә, мөстәкыйльлеккә өйрәтә, иҗади фикерләүне үстерә.

Татар милләтеннән булган балаларга чит тел өйрәтүнең һәрбер чорында уеннарны дәрестә һәм дәрестән тыш куллану уңай нәтиҗәләргә ирешергә

мөмкинлек бирә. Бары тик оста оештырылган заманча дәрес кенә балаларга чит телгә карата кызыксыну уята ала.

Listing (аудирование), Speaking (говрение) вакытында танып белү һәм коммуникатив УУГ тормышка ашырыла. Бу бүгенге заманча чит тел дәресләренең үзәгендә торырга тиеш. Аудирование һәм говорение җлешләрен яхшы үзләштергән балаларның киләчәктә БДИ ын уңышлы бирүләренә шик калмый. Ә бу безнең, ягъни чит тел укытучыларының, киләчәктә алга куелган төп бурычларыбызның берсе.

Мондый мисалларны саный китсәң, алар шактый. Бу хәзергесе вакытта бер генә фән укытучысы өчен дә яңалык түгел. Әмма шушы безнең өчен таныш булган гамәлләрне без көннән-көн үзебез яңартабыз. Шулай яңалыкка омтылып эшләсәк кенә без заманча дәрес формалаштыра алабыз һәм укучыларда укуга кызыксыну уятачакбыз. Ә чит тел укытучылары өчен болар һәммәсе дә бермә-бер тырышлык сорый.

Язмамны бик матур хикәя юллары белән тәгәллисем килә:

Борын заманда яшәгән ди бер патша. Беркөнне ул үзенең вәзирләрен чакырып алган да, үзенең патшалыгындагы иң зур йозакны ачырга кушкан. «Вәзирләрем минем! Кемдә - кем шушы йозакны ача, аңа мин патшалыгымдагы иң югары вазифаны бирәм. Шушы сүзләрне ишетү белән кайбер вәзирләр, бездән булмас дип» китеп барганнар. Икенчеләре йозак каршысында озак карап, тикшереп торганнан соң, кайтып киткәннәр. Тик бер вәзир генә йозакны тегеләй караган, болай караган, ниһаять тартып карарга булган. Һәм могҗиза! Йозак ачылып киткән. Патша моны күреп, болай дигән: «Карагыз! Ул үзенең күзләренә һәм колакларына гына таянмый, иң мөһиме үз көченә ышанып, авырлык алдында туктамыйча, янәдән – янә омтылыш ясады».

ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫГЫН ФОРМАЛАШТЫРУ

Шәмсетдинова Р.Р., Фаттахова Р.Ф.
ГАОУ ДПО ―Институт развития образования РТ‖
tnd@rambler.ru

Аннотация. В статье рассматриваютя некоторые понятия грамотности и процесс формирования функциональной грамотности на уроках татарского языка и литературы – целесообразное использования языковых средств при работе с текстами.
Ключевые слова: грамотность, функциональная грамотность , базовый уровень, языковые средства, культура речевого общения, использование информации прочитанного

Халыкның грамоталылыгы мәсьәләсе халыкара дәрәҗәдә (ЮНЕСКО) 20 нче гасырның 50 нче елларында карала башлый. 1958 елда ЮНЕСКО барлык илләр өчен тәкъдимнәр эшләп чыгара, әлеге тәкъдимнәрдә грамоталы кеше –ул укый белүче, укыганын аңлый һәм көндәлек тормышка караган гади кыска текстлар төзи белүче шәхес (Юнеско Генераль конференциясенең 10 нчы сессиясе материаллары). Шул ук вакытта грамоталылык терминын шәхеснең социаль мөнәсәбәтләр системасында нормаль хис итешен тәэмин итә алырлык күнекмәләр күләме мәгънәсендә аңлау да кабул ителгән. Шуңа бәйле рәвештә әлеге күнекмәләрнең күләме конкрет шартлардан чыгып төрлечә билгеләнә, хәзерге белем бирү эшчәнлегендә функциональ грамоталылык термины кулланыла. Ул кешенең тышкы мохит белән мөнәсәбәткә керә алу һәм тиз арада шул шартларга җайлаша алу сәләтен мәгънәсендә кулланыла.

Педагогика фәнендә грамоталылык мәсьәләсе төрле елларда күтәрелеп чыгып килде. Нигездә, грамоталылык мәсьәләләре массакүләм белем бирү мәсьәләләре хәл ителгәндә аеруча кискен күтәрелгән. Шул ук вакытта грамоталылык төшенчәсенең төгәл генә билгеләмәсе юк. Грамотылы кешене характерлый торган укый, яза, рәсем ясый һ.б. төрле кешенең нормаль тормыш эшчәнлеге өчен кирәк булган һәм башлангыч сыйныфларда үзләштерелә торган минималь күнекмәләр җыелмасы гына хәзерге чор социаль мәсьәләләрен чишү өчен җитәрлек түгел. Грамоталылык, белем бирү мәсьәләләре, тулаем алганда, һәрвакытта конкрет социаль, икътисади һәм мәдәни ситуациягә бәйле булган. Мисал өчен, антик дөньяда 1 дән алып 10 га кадәр исәпләүне укучылар еллар дәвамында өйрәнә алганнар һәм компетентлыкның мондый дәрәҗәсе шул чордагы социомәдәни чынбарлыкка туры килгән булса, хәзер исә грамоталылыкның бу дәрәҗәсе укуның беренче атнасында ирешелә торган дәрәҗә санала. Хәзерге чор цивилизациясенең дәрәҗәсе грамоталылык һәм белемлелекне бөтенләй башка төрле эчтәлектә аңлауны таләп итә. Бүгенге көндә функциональ грамоталылык кешенең мәгълүматны (беренче чиратта – текстны) таба, аңлый, үзләштерә, эшкәртә, саклый, тапшыра, көндәлек

тормышта, уку, һөнәри өлкәдә, иҗтимагый тормышта нәтиҗәле файдалана белү сәләтенә ия булуны белдерә. Функциональ грамоталылык – метапредмет күренеш һәм ул төрле предметларны үзләштергәндә файдаланыла һәм төрле формаларда чагылыш таба. Функциональ грамоталылыкның берничә индикаторы билгеләнә: коммуникатив грамоталылык, мәгълүмати грамоталылык, эшчәнлекле грамоталылык.

Коммуникатив грамоталылык укучыларда сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен яхшы белүләрен, алардан урынлы куллана белүне формалаштыруны күзаллый.

Сөйләм эшчәнлегенең һәр төре сөйләмә һәм язма формада җиткерелгән мәгълүматны дөрес аңлауны формалаштыра, шуңа күрә татар теле дәресләрендә теоретик материалны тирәнрәк үзләштерү өчен татар теле күренешләре турында хикәяләүче текстларны, әкиятләрне кертү, рус телендәге, чит телдәге тәңгәл яки тәңгәл килми торган мисаллар җирлегендә бирү мөһим. Бу очракта укучылар өйрәнелә торган тел күренешен ниндидер формаль грамматик күренеш буларак түгел, ә телләр тормышыннан алынган кызыклы, мөһим, күпкырлы күренеш буларак кабул ителәчәк. Мисал өчен, татар телендә грамматик күренеш буларак чагылыш тапмаган род категориясен, кайбер телләрдә (рус, француз, немец һ.б. телләрдә) исемнәргә карата кулланылуының бик шартлы булуын я яңа өйрәнә башлаганда, я кабатлау дәресендә түбәндәгечә шәрехләргә мөмкин: кешеләрнең, хайваннарның, кош-кортларның җенесен чагылдыра торган сүзләр бар телләрдә, мәсәлән, әти-әни, папа-мама, әтәч-тавык, петух-курица, ата каз –ана каз, гусак – гусыня. Татар телендә род төшенчәсенең башкача чагылышы юк. Ә менә рус телендә башка сүзләрнең родын билгеләгәндә, бу логика өзелә, кушымчаларга таянып билгеләнә, кайбер очракта, мисал өчен, ―ночь» һәм «день‖ беренче карашка берни белән дә аерылып тормаган сүзләрнең беренчесе – женский род, ә икенчесе мужской. Род категориясенең шартлылыгын тәрҗемә эшчәнлегеннән мисаллар белән дә күрсәтергә мөмкин: рус телендә стол – мужской род, шул сүз кергән текстны француз теленә женский родтагы исем буларак тәрҗемә итәбез (une table), яисә немец телендә das Madchen (кыз –девочка) - средний родтагы исем. Чагыштырып бирү нәтиҗәсендә, укучы үзенең туган теленең грамматик структурасы турында нәтиҗәләрен чыгара ала, башка телләр турында күзаллау булдыра ала, телләрдәге башка аерым күренешләр турында үзенең тикшеренү эшен алып бара, күзәтүләр ясый ала, шулар аша анда эшчәнлекле грамоталылык формалаша. Татар теле дәресләрендә эшчәнлекле грамоталык формалаштыру өстендә эш ―татар теле‖ курсының барлык темаларын өйрәнгәндә алып барылырга тиеш һәм аңа ―фикер һәм белем‖ проблемалы метапредмет ситуацияләрне чишү өчен шартлар тудырылып дәрестә фикернең белемнән аермасын күрсәтү юнәлешендә эш алып барганда ирешергә мөмкин.

Функциональ грамоталылык формалаштыру, укучыларның сөйләм эшчәнлеген камилләштерү татар теле предметында алган белемнәрен аларны аралашуның төрле шартларында куланылу үзенчәлекләренә нигезләнә. Өйрәтү процессы тел материалын анализлау күнекмәләрен формалаштыруга, тел

фактларын классификациялəүгə генə юнəлдерелмичə, сөйлəм культурасы тəрбиялəүгə, укуның төрле формаларыннан файдалану, текстларны мəгълүмати яктан үзлəштерү, мəгълүматны төрле формаларда эзлəү һəм аны сөйлəм ситуациясенə һəм əдəби тел нормаларына, аралашуның этик нормаларына туры китереп тапшыруның төрле ысуллары кебек тормышта гаять кирəк булган осталык формалаштыруга юнəлдерелгəн.

Функциональ грамоталык формалаштыруда татар теле һəм əдəбияты дəреслəрендə текст өстендə эш оештыру мөһим роль уйный. Нигез текстның гомуми мəгънəсен аңлау, авторның позициясен билгели белү, автор позициясе белəн герой позициясе арасындагы аерманы билгели белү, текстның логик төзелешен аңлый белүгə ия булу тора. Текстларны уку процессына кертеп җибəргəндəге методик факторларга без, беренче чиратта, текст материалын сайлау критерийларын; текстны дəрескə кертеп җибəрүнең максатка туры килə торган эш төрлəре; дəресне текстка таянып алып барырлык итеп оештыруны кертəбез. Текстны өйрəнгəндə, текстның, лингвистик күзəтүлəр юлы белəн бəйлəнешле, структур компонентлары ачыклана. Җөмлəнең өлешлəре һəм аерым җөмлəлəрне бəйлəү өчен уртак булган, шулай ук үзенчəлекле саналган күрсəткечлəр бүлеп чыгарыла, бəйлəнешле сөйлəмгə чыгу күнекмəлəре булдырыла. Бəйлəнешле сөйлəмне тикшерү кеше фикеренең төзелешен, аның телдə чагылышын аңлауга ярдəм итə. Текстларны игътибар белəн уку барышында укучылар фразаларны бəйлəүдə катнаша торган иң типик чараларны бүлеп чыгаралар. Мисал өчен, 9 сыйныфта сөйлəм үстерүгə караган темаларны ныгытканда, укучылар текст төзелешендə текст барлыкка китерүдə катнашкан, авторга текстның экспрессив-стилистик бөтенлеген тудыруга нигез булган төп чараларны билгелилəр. Мондый төр биремнəр укучыларны текстка нигезлəнеп, иҗади эшчəнлек башкару өчен бик кирəкле, мөһим. 9 нчы сыйныфта туган (татар) телдəн дəүлəт йомгаклау аттестациясе эше сочинение элементлары белəн киңəйтелгəн иҗади биремле изложение формасында тəкъдим ителə. Изложение имтихан бирүчелəрнең текстка нигезлəнеп, мөстəкыйль рəвештə мəгънəви бөтен, сөйлəм бəйлəнешлелеге һəм язу эзлеклелеге белəн характерланган иҗади бирем башкаруына йөз тота. Киңəйтелгəн изложение укучыларның лингвистик компетенциясе (тел материалы белəн эшлəгəндə, лингвистик белемнəрне куллана алуы, тел һəм сөйлəмгə караган белеме, өйрəнгəн материалны урынлы куллана белү күнекмəлəре, шулай ук танып белү, төркемлəү, татар теле дəреслəрендə алган аналитик белем һəм күнекмəлəр), тел компетенциясе (лексик, грамматик, стилистик, орфографик һəм пунктуацион нормаларны саклау осталыгы һəм күнекмəлəре), коммуникатив (аралашу) компетенциясе (сөйлəм эшчəнлегендə продуктив һəм рецептив күнекмəлəрне үзлəштерү дəрəҗəсе) тикшерелə. Шуңа күрə 5 нче сыйныфтан укучыларның коммуникатив грамоталылыгын үстерү өстендə эш оештырылырга тиеш. Мəсəлəн, эчтəлек сөйлəгəн вакытта, җөмлəлəрне дөрес итеп төзүгə игътибар бирелə. Бер үк җөмлəдə яки янəшə җөмлəлəрдə кабатлаулардан арыну, сүзлəрнең синонимнарын куллану талəп ителə. Сүзлек диктантлары язган вакытта (һəр дəрестə диярлек языла),

синонимнар таптырыла. Дәрестә орфографик сүзлекләр белән эшләү уңай нәтиҗә бирә. 5 нче сыйныфтан ук сүзлек диктантларының дәреслеген сүзлектән карап тикшерү сүзләрнең язылышын хәтердә калдырырга ярдәм итә, шул ук вакытта сүзлек белән эшләү күнекмәләрен үстерә. Дәрес, башта бу эш шактый күп вакытны ала, соңга таба укучылар кирәкле сүзләрне бик тиз табарга өйрәнәләр. Дәрестә текстны аңларга ярдәм итә торган уңышлы эш формаларыннан актив файдалану (абзацларны сайлап абзацларның эзлеклелеген билгеләү; авторның фикер йөртешен, тасвирлауларның бирелешен анализлау; вакыйгалар хронологиясен билгеләү, тексты микротемаларга бүлү һ.б.) укучыларның коммуникатив һәм эшчәнлекле грамоталылыгын арттырырга ярдәм итә.

Альберт Эйнштейнның функциональ грамоталылыкның гамәли әһәмиятен тулысынча чагылдыра торган фикере бар: ―...мәктәптә өйрәткәннәрнең онытылганнан соң калган өлеше ул - белем...‖ . Татар теле һәм әдәбияты дәресләреннән дә белем калырлык итеп укыту мөһим бурычыбыз.

Әдәбият

1. Концепция федеральных государственных образовательных стандартов общего образования: проект / Рос.акад. образования; под ред. А.М. Кондакова, А.А. Кузнецова. — М.: Просвещение, 2008. http://www.ed.gov.ru/ob-edu/noc/rub/standart/
2. Валькова Г., Зайнуллина Ф., Штейнберг В. Логико-смысловые модели - дидактическая многомерная технология // Директор школы: науч.-метод. журн. для рук. учеб. заведений и органов образования. - 2009. - № 1. - С.49-54.
3. Гыйләҗева Л.Г., Хадиева Г.В. Татар теле. 9 нчы сыйныф. Дәүләт (йомгаклау аттестациясенә әзерләнү. Татар телендә гомуми белем бирү мәктәпләре өчен методик кулланма. – Казан: Ихлас. - 92 бит.
4. Ермоленко В.А. Проблемы функциональной грамотности в современных условиях. Через чтение в мировое образовательное пространство. Выпуск 11. – М., 2002 - С.45-49.
5. Шәмсетдинова Р.Р. Татар теле: Күнегүләр. Анализ үрнәкләре. Тестлар/ Р.Р. Шәмсетдинова; тулыл. икенче басма. – Казан: Татар. кит. Нәшр., 2007. – 191 б.

МИЛЛИ МӘГАРИФНЕ БЕЛЕМ СЫЙФАТЫН КНТӘРНДӘ ТӨП БУРЫЧЛАР

Шарифуллина Р.И
МБОУ ―Черемшанский лицей‖
shrazily@mail.ru

Аннотация. Эта статья не только о проблемах обучения языкам в качестве родного, но и о применении о новой и уникальной технологии в обучении родного языка.

Ключевые слова. Деятельностный подход. Приоритетные технологии. Обучение в сотрудничестве. Успешный выпустник.

Бүгенге көн мәгариф системасыны стенлекле юн леше булып- ү ө ә ң ө ә баланың ү ә ү ә ү ә злегенн н сешен т эмин ит г юн лдерелг н уку-танып бел процессын ә ә ү оештыру тора. Без т ртипле, эш с юч н, тормышта з урыннарын таба ә ө ә ү алырлык, мгыять чен т рле яклап ск н ш хес т рбиял рг тиеш. Алар җә ө ө ү ә ә ә ә ә инициатива к рс т бел че, очраган кыенлыклардан и юлларын ү ә ә ү ж ңү м ст кыйль таба алырлык, ягъни стандарт булмаган чишелешл р таба алучы; ө ә ә креатив (и ади), критик (т нкыйди) фикерг ия, м шулай ук хезм т җ ә ә һә ә базарларында конкурентлыкка с л тле, компетентлы ш хес булсын. Бу- ә ә ә укыту-т рбия процессыны асыл максаты. ә ң Б генге к нд компетентлы (способный, белемле, с л тле, у ышка иреш ү ө ә ә ә ң ә торган) ш хес формалаштыру чен, укытучы зе д шул тал пл рг ия ә ө ү ә ә ә булырга тиеш. Компетентлы укытучы нинди к некм л рг ия булырга тиеш? ү ә ә ә 1) Даими йр нерг : зг решл рг зер булырга, р эш н ти ле булсын чен ө ә ә ү ә ә ә ә һә ә җә ө тырышырга, белеме не системага салырга, башкалар фикере бел н ң ә ис пл шерг , я алыкны тиз кабул ит рг йр нерг ; ә ә ә ң ә ә ө ә ә 2) Эзл нерг : информацияне сайлап ала белерг , зе кир клесен эзл п ә ә ә ү ңә ә ә табарга; 3) Хезм тт шлек ит рг : группада, командада эшл г нд , карарлар кабул ә ә ә ә ә ә ә итк нд , конфликтларны чишк нд башкалар фикере бел н ис пл ш д ; ә ә ә ә ә ә ә ү ә 4) Эшк тотынырга: проектлар эшл рг , берд м булырга, з эше не оештыра ә ә ә ә ү ң белерг ; ә 5) айлашырга: я а информацион м коммуникатив технологиял рне Җ ң һә ә кулланырга, я алыкны тиз кабул ит рг , югалып калмаска. ң ә ә Заманча сыйфатлы белем бир – универсаль уку гам лл рен (УУГ) ү ә ә формалаштыруга юн лг н булырга тиеш. ә ә Укытуга компетентлы якын килү укытучы бел н укучыны бер к максатта эшл вен т эмин ит .Укытучы ә ң ү ә ә ә укучыга зер белем бирерг тиеш т гел:укучылар белем алырга кил , ә ә ү ә ә укытучы укучыларны белем алуларын оештырырга тиеш була, ягъни ң эшлекле белем механизмы тормышка ашырыла:укытучы да, балалар да процессны субъектлары булу зарур. ң УУГ гам лл ре я а белем м ә ә ң һә к некм л рне м ст кыйль р вешт зл штер алуы м шул процессны ү ә ә ө ә ә ә ү ә ә һә оештыра бел не т эмин ит торган гам лл р ыелмасы ү ә ә ә ә ж . Укытучы – оештыручы т рле эш формалары, я а белемн рне эзл рг эт р че ө ң ә ә ә ә ү технологиял р кулланырга тиеш. (Традицион эш т рл ре бел н, инновацион ә ө ә ә формалар еш

кулланырга: тренинг, эшлекле уен, мастер-класс, проект эшл ре, ҽ эзл н - тикшерен эшл ре .б.) ҽ ү ү ҽ һ Я а стандартлар укытучыдан м гъл мати коммуникатив технологиял р ң ҽ ү ҽ куллануны тал п ит .Компьютер технологиял рен куллану н ти сенд ҽ ҽ ҽ ҽ җҽ ҽ балалар м гъл мат ташкынында иркен аралашырга йр н , м гъл мат алу ҽ ү ҿ ҽ ҽ ҽ ү ысулларын зл штер . Белем бир д проектлар методын файдалану балага ү ҽ ҽ ү ҽ ш хси якын килеп укытуда н ти ле технологиял рд н санала. Проект т з ҽ ҽ җҽ ҽ ҽ ҿ ү эшч нлеге м ст кыйль фикерл не стер ,м гъл мат таба бел , ҽ ҿ ҽ ҽү ү ү ҽ ү ү фаразлау ,стандарт булмаган карарлар кабул ит осталыгына ия булуны к зд ү ү ҽ тота. Мультимедиа технологиял ре электрон белешм лекл р, ҽ ҽ ҽ энцеклопедиял р, к л мле м гъл мат чыганаклары бел н эшл г юл ача. ҽ ү ҽ ҽ ү ҽ ҽү ҽ Укучыларны зара ярд мл ш ен активлаштыруга юн лтелг н эш ң ү ҽ ҽ ү ҽ ҽ формасы буларак эшч нлекне т ркемн рд оештыру у ай н ти л р бир . ҽ ҿ ҽ ҽ ң ҽ җҽ ҽ ҽ Укучылар бер – берсе бел н аралашып, бер – берсене фикерен ты лап, з – ҽ ң ң ү ү ҽ ҽ ҿ ҽ ү ү ҽ зл ренд м ст кыйльлек сыйфатлары булдыралар, шулай итеп, алар з сешк иреш . ҽ Проблемалы укыту технологиясе куллану н ти сенд балаларны ҽ җҽ ҽ ң фикерл с л те камилл штерел . ҽү ҽ ҽ ҽ ҽ Татар теле д ресл ренд ҽ ҽ ҽ и ади стерешле Р химов технологиясе җ ү ҽ кулай булса, д бият д ресе чен Яхин ҽ ҽ ҽ ҿ методологиясе кулай. Тагын инновацион технологиял рне берсе- ҽ ң критик фикерл технологиясе ҽү н аерып к рс т сем ү ҽ ҽ кил . Бу технология – з фикере не яклый, иткер алу, г м д ше не ҽ ү ң җ ҽ ҽң ҽ ҽ ҽ ң ты лый бел , аргументларга нигезл неп, логик фикер й ртерг шартлар ң ү ҽ ҿ ҽ тудыра. Д ресне т рле этабында куллану чен т рле алымнары бар. Я алыгы ҽ ң ҿ ҿ ҿ ң – и ади ш хес т рбиял г шартлар тудыра. Бу турыда м гъл матны м гариф җ ҽ ҽ ҽү ҽ ҽ ү ҽ журналларыннан да таба аласыз. (―К рзин‖ ысулы, Синквейн, Кластер, Алты ҽ эшл п .б. ысуллар) ҽ ҽ һ Укучыларны зара ярд мл ш ен активлаштыруга юн лтелг н эш ң ү ҽ ҽ ү ҽ ҽ формасы буларак эшч нлекне т ркемн рд оештыру у ай н ти л р бир . ҽ ҿ ҽ ҽ ң ҽ җҽ ҽ ҽ Укучылар бер – берсе бел н аралашып, бер – берсене фикерен ты лап, з – ҽ ң ң ү ү ҽ ҽ ҿ ҽ ү ү ҽ зл ренд м ст кыйльлек сыйфатлары булдыралар, шулай итеп, алар з сешк иреш . ҽ Укытуны традицион системасында булган и яхшы алым,методларын ң ң кулланып м стер барып эшл г нд ген инновацион технологиял р яхшы һҽ ү ҽ ҽ ҽ ҽ ҽ ҽ н ти г ирешерг ярд м ит . мма рбер д ресне д информацион ҽ җҽ ҽ ҽ ҽ ҽ Ѳ һҽ ҽ ҽ технологиял р кулланып тк реп булмый, мондый д реск зерлек укытучыдан ҽ ү ҽ ҽ ҽ ҽ к п вакыт та тал п ит ү ҽ ҽ.―Укытучыны тере с зен бернинди компьютер да ң ү алыштыра алмый‖ диг н с зл рне еш ишетерг туры кил . Бу с зл р бел н ҽ ү ҽ ҽ ҽ ү ҽ ҽ килеш м. Туган тел д ресл рен укучыларны мониторга каратып кына тк реп ҽ ҽ ҽ ү ҽ булмый. Ч нки д ресне т рле этапларында урынлы, уйланылып кулланылган ҿ ҽ ң ҿ компьютер бел н эш укучыны укытучы ҽ ң һҽ ҽ м сыйныфташлары бел н аралашуы һҽ ү ҿ ҽ ҽ ү м башка к п т рле эшл р бел н релеп барырга тиеш. Б генге к нд м кт пл рд татар халкы тарихы бик аз к л мд укытыла ү ҿ ҽ ҽ ҽ ҽ ҽ ү ҽ ҽ яис б тенл й укытылмый. Шу а к р татар теле д ресл ренд , коммуникатив ҽ ҿ ҽ ң ү ҽ ҽ ҽ ҽ һҽ ҽ ү ҽ м т рбияви максатларны к зд тотып, кызыклы этнографик-тарихи темаларны яктырту укучыларга з халкыны тк не турында к пмедер к л мд ү ң ү ҽ

ү ү ҽ ҽ м гъл мат биреп, аларда татар тарихын йөр н г мотивация булдыра. ҽ ү ҿ ҽ ү ҽ Икенчед н, б генге к н укучыларында татар халкыны гореф-гад тл ре, ҽ ү ҿ ң ҽ ҽ традициял ре турында к заллау бик шартлы. Бигр к т зур ш рл рд яш че ҽ ү ҽ ҽ ҽһҽ ҽ ҽ ҽү балалар лк н буын в килл ре – би-бабаларыннан читт яши, шу а к р ҿ ҽ ҽ ҽ ҽ ҽ ң ү ҽ аларда татар халкыны гасырлар д вамында формалашкан гореф-гад тл ре ң ҽ ҽ ҽ турында х б рсез булып калуы ихтимал: ― бил регез яшь чакта кулъяулыклар ҽ ҽ Ө ҽ чикк ндер, к рг негез, сораганыгыз бармы?‖ - дип сорагач, балалар ―без би ҽ ү ҽ ҽ бел н яш мибез, ул аерым яши‖ яки ― би-бабай лг н, йортлары сатылган ҽ ҽ ҽ ү ҽ инде‖, дил р. Гомум н, социом д ни компетенцияне тел материалы бел н берг ҽ ҽ ҽ ҽ ҽ ҽ ү ҿ ҽ Ҿ ҽ реп, диалогик яки монологик с йл м итеп ченчед н, укучыларда татар халкыны д нья цивилизациясене бер леше булуын, аны з милли киен ң ҿ ң ҿ ң ү ү р веше, к заллаулары, гореф-гад тл ре, рухи м материаль байлыгы барлыгы ҽ ү ҽ ҽ һҽ турында фикер урнаша. Ө ҽ ҽ ҽ ң ү т рбияви максаты татар милли биз кл ре, татар халкыны киен ү ҽ ҽ ҽ ҽ ҽ ҽ зенч лекл ре, гореф-гад тл ре, аш-су осталыгы, кулдан эшл нг н эш кораллары турында м гъл мат бир , укучыларда з халкыны гореф- ҽ ү ү ү ң гад тл рен , этнографик зенч лекл рен ихтирам-х рм т уяту, горурлык хисе ҽ ҽ ҽ ү ҽ ҽ ҽ ҿ ҽ т рбиял булган д ресл р комплекслы т къдим ителс , укучыларыбызда з ҽ ҽү ҽ ҽ ҽ ҽ ү халкы м д нияте турында тулы к заллау булдырырга м мкин. Шул р вешле ҽ ҽ ү ҿ ҽ б генге заман 21 нче гасыр укытучысы татар телен м д биятын йөр т бел н ү һҽ ҽ ҽ ҿ ҽ ү ҽ берр тт н, укучыларда, ягъни кил ч к буын в килл ренд , з тк нен , ҽ ҽ ҽ ҽ ҽ ҽ ҽ ү ү ҽ ҽ тарихына, м д ни мирасына ихтирам-х рм т т рбияли, дим к, р бала з- зен ҽ ҽ ҿ ҽ ҽ ҽ һҽ ү ү яратырга, би-бабасын, ти- нисен х рм тл рг йөр н . ҽ ҽ ҽ ҿ ҽ ҽ ҽ ҿ ҽ ҽ М кт пт кулланыла торган и отышлы инновацион технологиял рне ҽ ҽ ҽ ң ҽ ң берсе электрон д реслекл р ҽ ҽ һҽ ҽ ҽ Ү ҽ ҽ ҽ м ярд млекл р. з д ресл ремд Хайдарова Р.З. Галиева Н.Г ит кчелегенд чыккан ―К елле татар теле‖ электрон җ ҽ ҽ үң д ресл кл рен, ҽ ҽ ҽ Ф тхуллова К.С. Юсупова А.Ш. Денм х мм това Э.Н. ҽ ҿ ҽ ҽ авторлыгында чыккан ―Татарча с йл ш без, укыйбыз, язабыз‖ ярд млекл рен ҿ ҽ ҽ ҽ ҽ кулланам. леге д реслекл р м ярд млекл рд ге материаллар укучыда тел Ө ҽ ҽ һҽ ҽ ҽ ҽ ҿ ҽ ү ҽ ң ҽ ҽ ҽ һҽ йөр н г кызыксыну тудыра. Аларны з выклы биз леше, биремн р м текстларны с нгатьч биз леше, биз лешт т сл рне урынлы куллану, ң ҽ ҽ ҽ ҽ ҽ ҿ ҽ т къдим ителг н текстларны м зекл рне балалар чен кызыклы булуы, ҽ ҽ ң һҽ ҿ ҽ ң ҿ яшь зенч лекл рен туры кил е, биремн р м сорауларны укучы башкарып ү ҽ ҽ ҽ ү ҽ һҽ ң чыга алырлык катлаулылыкта булуы, аудирование лешл ре булу бик т яхшы. ҿ ҽ ҽ Татар теле м д бияты д ресл ренд компьютер технологиял рнен һҽ ҽ ҽ ҽ ҽ ҽ ҽ куллануны т б нд ге у ай яклары бар: ң ү ҽ ҽ ң • уку процессы эчт легене индивидуальл ш , к л мле материалны тиз ҽ ң ҽ ү ү ҽ ң ү ҽ ү зл штерел е; • укучыларны танып бел активлыгы с ; ң ү ү ү • укучыларны психологик м мкинлекл рене ис пк алынуы м ң ҿ ҽ ң ҽ ҽ һҽ белемн рне объектив б ял нел е; ҽ ң ҽ ҽ ү • укытучыны эш характеры зг р . ң ү ҽ ү Шул р вешле, татар телен укытканда, заманча технологиял рг таяну ҽ ҽ ҽ укытучыны да эшен и ел йөт , укучыларны белем д р сен арттыруда да ң җ ң ҽ ҽ ң ҽ ҽҗҽ м им чара булып тора. ҿһ Х зерге шатрларда татар телен гам лг керт чен, объектив шартлар ҽ ҽ ҽ ү ҿ җ ҽ ҿ ҽ ҽ җҽ ҽ ү ү ҿ ит

рлек. Татар телен укытуны м мкин кад р н ти лер к ит – б генге к н педагогикасыны м им бурычларыннан берсе. у ай н ти л рг иреш д ң ҫһ Ҽ ң ҽ җҽ ҽ ҽ ү ҽ заманча технологиял рг таяну ярд м ит ала. ҽ ҽ ҽ ҽ Белем бир д заманча технологиял рне куллану ул - хлаклы кеше ү ҽ ҽ ҽ т рбиял , педагогик технологиял р булдыруда ф нне роле арту, йр нг нне ҽ ҽү ҽ ҽ ң ҫ ҽ ҽ тормышта куллана бел м башкалар. ү һҽ Д ресл ремд заманча технологиял рне кулланып мин т б нд ге ҽ ҽ ҽ ҽ ү ҽ ҽ н ти л рг иреш алдым дип уйлыйм:укучыларны с йл м теле яхшыра, ҽ җҽ ҽ ҽ ҽ ң ҫ ҽ с злек запасы баеый; компьютер технлогиял ре куллану уку эшч нлеген тагын ү ҽ ҽ да баетты;укучыларны и ади эшч нлеге артты. ң җ ҽ Эшемне н ти се буларак укыткан укучыларым ачык д ресл рд , т рле ң ҽ җҽ ҽ ҽ ҽ ҫ конкурсларда, конференциял рд актив катнашалар, урыннар алалар, д реск ҽ ҽ ҽ ҽ кызыксыынп, тел п й рил р. ҽ ҫ ҽ Я а технологиял р бел н танышуны м д рест куллану, и ади сешне ң ҽ ҽ һҽ ҽ ҽ җ ү т эмин ит че методик д биятны йр н , эзл н эшч нлеген д вам ит ҽ ү ҽ ҽ ҫ ҽ ү ҽ ү ҽ ҽ ү кил ч кк переспиктивам. ҽ ҽ ҽ Алда язылганнардан н ти ясап, шуны йтерг була: педагогика ф ненд ҽ җҽ ҽ ҽ ҽ ҽ укыту-т рбия процессы сыйфатын стерерг булышлык ит че технологиял р ҽ ү ҽ ү ҽ шактый. Укытучыны бурычы – я алыклар агымында югалып калмыйча, д рес ң ң ҫ юн леш алу, укытучыны р этабы чен уку материалын а латуны и ҽ ң һҽ ҫ ң ң ң у ышлы вариантын табу. Шул ук вакытта аларны бер-берсе бел н ярашырга ң ң ҽ тиешлеген д онытмау зарури. И м име шул: заманча технологиял рне ҽ ң ҫһ ҽ куллану алынган м гъл матны 85%ка якынын, традицион технологиял р – ҽ ү ң ҽ ҽ 40% белемне х терд озак сакларга ярд м ит . ҽ ҽ ҽ ҽ Я а белем бир стандартлары куйган тал пл рне у ышлы т м кт п, ң ү ҽ ҽ ң ү ҽү ҽ ҽ гаил , мгыять м д л т берд м булып, зур к ч куеп эшл г нд ген ҽ җҽ һҽ ҽү ҽ ҽ ҫ ҽ ҽ ҽ ҽ булачак. Я а стандартлар буенча чыгарылыш укучысы кызыксынучан, ң д ньяны актив танып-бел че, белем нигезл рен яхшы зл штер че, м ст кыйль ҫ ү ҽ ү ҽ ү ҫ ҽ һҽ җ ү ң ҽ һҽ җҽ м и ади, зене туган ягын, илен яратучы, гаил м мгыять кыймм тл рен кабул ит че м х рм т ит че, зе эшл г н эшк гаил м ҽ ҽ ү һҽ ҫ ҽ ү ү ҽ ҽ ҽ ҽ һҽ м кт п алдында авап бир бел че, кеше фикерен ты лый м з фикерен ҽ ҽ җ ҽ ү ң һҽ ү ҽ ҽ ү ҽ ҽ ҽү ҽ ҽ ҽ ҫ ҽ ү ҽү йт бел че, с лам т яш р веше кагыйд л рен т г л т че булырга тиеш. Укытучы к р з че т гел. Ул баланы кил ч кт кем булуын, ү ҽ ҽ ү ң ҽ ҽ ҽ җҽ ҽ ҽ мгыятьт нинди урын тотуын бел алмый. Шулай да укытучы перспектив эшл рг тиеш. Ул т рбиял че ш хес заманча мгыятьк ҽ ҽ ҽ ҽү ҽ җҽ ҽ у ышлы формалашкан булсын м чын кеше булып калсын.

Ҽдҽбият

1. Загашеев И.О., Заир-Бек С.И., Муштавинская И.В. Учим детей мыслить критически. – СПб, 2003

2. Селевко Г. К. Современные образовательные технологии. М., ―Народное образование‖, 1998.

3. Педагогическая технология творческого развития : метод. пособие по развивающему обучению / А.З. Рахимов ; Башк. гос. педуниверситет. - Уфа : Творчество, 2003 . - 142 с.

ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ МӘГЪЛҮМАТИ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

Шиһабеддинова Г.Х.
ДАҺБУ ―Г. Тукай ис. Арча педагогия көллияте‖
shigabuddinova@mail.ru

Аннотация. В статье рассматриваются современные педагогические технологии, широко используемые в области языкового образования, в том числе при обучении татарскому языку. Среди них наиболее привлекательными считаются информационно-коммуникационные, дистанционные, игровые технологии и проектная технология. Использование их способствует развитию коммуникативной компетенции учеников, которая понимается как способность порождать высказывание на изучаемом языке.
Ключевые слова: языковое образование, татарский язык; современные технологии, коммуникативная компетенция.

Җәмгыятьтә барган үзгәрешләр чоры укыту-тәрбия эшенең дә барлык өлкәләренә яңача якын килү, аны яңача аңлауны таләп итә. Бу үзгәрешләр мәгариф өлкәсендә эшләүчеләр алдына яңа мәсьәләләр куя. Укытучылар бу яңарышларны тормышка ашыруда төп рольне башкаралар. Укыту-тәрбия системасын яңарту – яңа идеяләр, ысуллар, чаралар эзләү дигән сүз. Мәктәпләрнең бүгенге бурычы – хәзерге көн таләпләренә, тормыш, җәмгыять ихтыяҗларына җавап бирүче белемле, тирән фикер йөртә торган, социаль актив, карарларны мөстәкыйль кабул итә торган иҗади шәхес тәрбияләү [3, 5].

Соңгы елларда күп кенә яңа технологияләр тәкъдим ителде һәм гамәлгә кертелде. Аларның күбесе дәресләрдә уңышлы кулланыла. Укытучы һәм укучылар эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен алдан уйлап, башкарырга тиешле эшләрне системага салып кую укыту-тәрбия процессында уңышка ирешергә ярдәм итә.

Татар телен яңа заманча технологияләр аша өйрәтү – ул уку процессын яңача оештыру, ахыргы нәтиҗәләрне күзалларга омтылу, укучыларның актив эшчәнлегенә этәргеч бирү.

Соңгы елларда белем бирү системасында заманча метод-алымнардан уку процессын оештыру һәм идарә итүнең нәтиҗәлелегенә нигезләнгән педагогик технологияләр (терәк схемалар кулланып, алга китеп укыту, белем бирүнең компьютер, үстерелешле укыту, проектлар методы, концентрик белем бирү технологияләре) һәм укучылар эшчәнлеген активлаштыру һәм интенсивлаштыруга юнәлтелгән педагогик (уен, проблемалы укыту, аралашуга өйрәтү технологияләре) уңышлы кулланыла.

Татар теленә өйрәткәндә, заманча технологияләрне файдалануның мөһим бурычлары булып түбәндәгеләр санала:

- укучыда өйрәнелә торган фәнгә карата кызыксыну уяту;
- укучының танып белү активлыгын арттыру;

- тел өйрәнү өчен уңайлы шартлар булдыру, аралашу вакытында үзара ярдәмләшү мохите тудыру;

- укучының иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачу, алган белемнәрен тирәнәйтү, инициативасын тагын да үстерү [4, 33].

Әлеге технологияләрнең берничәсенә тукталып үтик.

Дәресне заман таләпләренә туры килгән компьютерлар белән тәэмин итү – мәгълүмати технологияләрне гамәлгә куюда беренче шарт. Аларны укыту һәм тәрбия эшендә гамәлгә ашыру, укытучыдан фәнни-методик яктан әзерлек белән бергәттән, укытуны компьютер ярдәмендә оештыра белүне дә таләп итә. Бу – яңа технологияне нәтиҗәле куллануның иң мөһим педагогик шарты.

Компьютер – соңгы елларда уку процессына актив кертелгән һәм иң мөһим чараларның берсе. Аны куллану яңа мәгълүмати технологияләрдән файдалануны күзаллый.

Компьютер технологияләре төрле чаралар белән гамәлгә ашырыла: мөстәкыйль компьютер, автоматлаштырылган эш урыны, локаль исәпләү челтәре, компьютерлы мәгълүмат челтәрләре. Уку йортларында аның белән бәйле төшенчәләр актив һәм уңышлы кулланыла башлады: мәгълүмат базасы, укучының эш урыны, мультимедия системасы. Компьютер технологиясе – компьютер мөмкинлекләреннән файдаланып, өйрәнүчегә мәгълүматны әзерләү һәм тапшыру процессы ул. Ф.Харисов, татар телен өйрәткәндә, компьютерны түбәндәге очракларда кулланырга тәкъдим итә:

- тел күренешләренә өйрәткәндә;
- диалогны, аралашуны тәэмин иткәндә (компьютер челтәре аша);
- сөйләм осталыгын һәм күнекмәләрен формалаштырганда;
- белем һәм күнекмәләр булдыруның билгеле бер дәрәҗәсен тикшергәндә;
- кирәкле мәгълүматны укыту максатыннан чыгып эзләгәндә;
- уку материалын тәкъдим иткәндә һәм аңлатканда, төрле ситуацияләрне модельләштергәндә [5, 219].

Компьютер программаларын кулланып укыту ысуллары сөйләмгә өйрәтә торган диалогларны һәм төрле процессларны модельләштерү, уку материалын үзләштерүне контрольдә тотудан гыйбарәт. Моннан тыш, компьютер мөһим мәсьәләләрне хәл итәргә булыша. Мәсәлән: текстларны төзү һәм эшкәртү, укытучыны иҗади булмаган эштән бушату, өйрәнелә торган тел белән бәйләнешне арттыру. Шулай ук татар теленә өйрәтүнең төп методларын (күрсәтү, аңлату, төзәтү, белемнәрне бәяләү, күнегү) гамәлгә ашырырга ярдәм итә.

Тиешле белем бирү һәм алган күнекмәләрне кирәкле дәрәҗәдә үстерү өчен, заманча мәгълүмати технологияләрне дәрестә системалы һәм урынлы итеп файдалану зур әһәмияткә ия. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә бу технологияләрне кулануның өстенлеге бәхәссез. Барыннан да элек, алар шәхескә юнәлтелгән, ныклы һәм вариатив. Компьютер күрсәтмәлелекне, контрольлекне тәэмин итеп һәм күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрүгә ярдәм итә, этәргеч бирә.

Компьютер куллану шулай ук укучыны дөрес язарга, дөрес укырга өйрәтә, сүзлек запасын баета. Компьютерның өстенлеге шунда: мониторда барлык биремнәр матур, эстетик яктан камил эшләнә. Компьютер ярдәмендә бик күп эшләр эшләп була: мультимедиа презентацияләре, төрле тестлар, схемалар. Мәсәлән, презентацион программаларны төзегәндә, укытучы аның эченә бик күп материал: төрле схемалар, рәсемнәр, фотосурәтләрне кертә ала. Мондый программа белән танышканда, укучы үзен кино караучы итеп хис итә. Электрон презентацияләр даими кулланылганда гына, уңай нәтиҗәләргә китерә. Презентация слайдлары яңа материалны аңлатканда да, белемнәрне актуальләштерү этабында да, белемнәрне гомумиләштерү, системалаштыру этапларында да уңышлы кулланылырга мөмкин. Материал фәннилек, аңлаешлылык, күрсәтмәлелек принципларына җавап бирерлек итеп сайланырга тиеш. Яңа теманы аңлатканда, презентация бирелешенең әһәмияте зур. Слайдларда рәсемнәр, схемалар, даталар, терминнарга аңлатмалар, кыскача тезислар язылырга мөмкин. Яңа тема аңлату дәресе тулаем слайд карап утыруга гына кайтып калырга тиеш түгел. Дәрес барышында башка эш төрләре дә актив кулланыла: дәреслек белән эш, тактага язу, сүзлекләр белән эшләү һ.б. Шулай итеп, презентация материалын күрсәтү башка эш төрләре белән үрелеп бара. Электрон презентацияләр төзү укучыларга өй эше итеп тә бирелергә мөмкин. Мондый эшләр башкару укучыларга үз фикерләрен төгәл, җыйнак итеп әйтеп бирергә мөмкинлек бирә.

Телгә өйрәтүдә компьютер технологияләрен куллануның өстенлек яклары итеп түбәндәгеләрне күрсәтергә була:

- укытуда индивидуализация барлыкка килә;
- укучыларның компьютер белән кызыксыну укыту процессын мотивлаштыра;
- укучылар компьютер белән диалогны бик теләп башкаралар;
- хаталар булганда, компьютер тискәре эмоцияләрне белдерми;
- объектив билге куела [1, 143].

Компьютерның мөһим бурычларыннан берсе булып күнегүләр системасын тормышка ашыруны тәэмин итү тора. Ул исә үз чиратында, уку процессын камилләштерергә, сөйләм материалын үзләштерүне җиңеләйтергә тиеш. Эш барышында укучы үзенең җавапларының дөреслеген дә тикшереп бара ала.

Дәрестә уеннар оештыру – укытуның актив формалары һәм методларыннан файдалану ул.

Уенны оештыру өчен, элек төп бурычны билгеләргә, укучыларны уенга әзерләргә, аларны кирәкле теоретик белемнәр, төрле мәгълүматлар белән тәэмин итәргә кирәк. Уен шартлары һәм үзара аралашу кагыйдәләре белән таныштырырга; максатны һәм чишелергә тиешле бурычларны аңлатырга, уен барышында шул бурычларны үтәүгә ирешергә, чишелешнең дөреслеген тикшереп, нәтиҗәләргә бәя бирергә кирәк була.

Уенны нәтиҗәле үткәрү өчен, укучыларны кызыксындырырлык проблемалы сораулар куя белүнең дә әһәмияте зур.

Уку процессын интенсивлаштыру максатын истә тотып, уеннар төшенчәләрне үзләштерү, теманы өйрәнү, яңа материалны аңлату һәм ныгыту, сөйләм эшчәнлегенең тыңлап аңлау, уку төрләренә өйрәтү вакытында технология буларак файдаланыла ала.

Татар теленә өйрәткәндә, рольле уеннар аеруча актив кулланыла [6, 11]. Уеннарны парлап та, төркемләп тә үткәрергә мөмкин. Мондый уеннарны үткәрү өчен пьеса формасында уенның моделе төзелә. Укучыларга рольләрнең сүзләре бүлеп бирелә. Уен вакытында катнашучылар бер-берсе белән аралашалар, аларның табигый рәвештә нәрсәдер әйтү, нәрсә турында булса да сорау, әңгәмәдәшенә җавап бирү теләге туа.

Бу уеннар берничә этаптан тора: әзерләнү этабы (сценарий төзү, уен өчен кирәкле материалларны әзерләү, үткәрү планын төзү, максат-бурычларны билгеләү, уен кагыйдәләрен ачыклау, рольләрне бүлешү, төркемнәргә бүлену, консультацияләр үткәрү һ.б.); уенны үткәрү этабы (кирәкле чыганаклар белән эшләү, төркемнәрнең чыгышы, дискуссияләр үткәрү, экспертларның эшләре һ.б.); йомгаклау этабы (уенга анализ ясау; бәяләү; нәтиҗә ясау, киңәшләр бирү һ.б.). Рольле уеннар төрле тип дәресләрдә дә уңышлы кулланылалар.

XIX йөзнең беренче яртысында чит ил педагоглары И.Г. Песталоцци, А. Дистервег, рус галим-педагоглары К.Д. Ушинский, Л.С. Выготский тарафыннан үстерешле укыту технологиясенә нигез салына. Аның нигезен укучыларның танып белү мөмкинлеген активлаштыру һәм үстерү тәшкил итә.

Үстерешле белем бирү теориясе Л.В. Занков, Д.Б. Эльконин, В.В. Давыдов һ.б. педагогларның хезмәтләрендә алга таба эшкәртелгән. Хәзерге вакытта үстерешле укыту буенча берничә технология эшләнгән. Л.В. Занков технологиясе шәхесне төрле яклап үстерүне күздә тота, Д.Б. Эльконин – В.В.Давыдов технологиясе акыл эшчәнлеге үсешен алга куя, иҗади үсеш технологиясенең төп шарты – психологик уңай халәт тудыру. Проблемалы-үстерелешле белем бирү методларын эшләүгә М.И. Мәхмүтов зур өлеш керткән. Ул үз хезмәтләрендә укучыларның интеллектуаль мөмкинлекләре үсешендә бу методның нәтиҗәле булуын раслаган. Ә.З. Рәхимов иҗади үсеш технологиясенә нигез салган. Иҗади үсеш технологиясе, барыннан да элек, иҗади шәхес тәрбияләүгә юнәлтелгән. Ә.З. Рәхимов төп кагыйдәләр итеп укытучы һәм укучының дәрестә субъект буларак эшләвен, укытучының балалар эшчәнлеге белән идарә итүче дирижѐр вазифасы башкаруын күрсәтә.

Дәресне иҗади үсеш технологиясе нигезендә үткәрүнең иң мөһим шарты – уку эшчәнлеген төркемнәрдә алып бару.

Профессор Ә.З. Рәхимов болай ди: ―ИҮТ өч китта тора. Шуларның беренчесе – төшенчәнең эчтәлеген һәм аңа билгеләмә бирү буенча эш итү ысулын гомумиләштерү, икенчесе – укучылар эшчәнлеген төркемнәрдә оештыру, өченчесе – модельләштерү‖ [2, 132].

Шушы мөһим компонентларның берсе булган модельләштерүгә тукталыйк. Модель төзү – иҗади эш. Аның аша укучылар төшенчәнең үзенчәлекләрен, төп билгеләрен һәм эчке бәйләнешләрен ачалар. Типографиядә эшләнгән әзер күрсәтмә чаралар укучыларның фикерләү сәләтен үстерми, ә

модель укытучы һәм укучыларның бердәм уку эшчәнлеге нәтиҗәсендә туа. Укучылар төрле символлар, билгеләр, график модельләр белән эш итәргә өйрәнәләр.

Модельләштерү бигрәк тә теоретик материалны кыска бер фикер итеп күз алдына китерү өчен кулай.

Мәсәлән, ―Исем‖ темасын өйрәнгәндә, модель төзү һәм төшенчәгә билгеләмә бирү этабын күзәтик:

Исем

↓

Мөстәкыйль сүз төркеме

↓

Предмет яки зат

↓

Кем? Нәрсә?

↓

Ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык, хәл.

Бирем: модельгә таянып, исемнең билгеләмәсен бирергә.

Модельләштерү дәрестә төшенчә өстендә эш белән нык бәйләнгән. Төшенчә формалаштыру – дәреснең мөһим этабы. Чөнки төшенчә - логик фикер йөртүнең төп формасы булу белән бергә укучыларда фәнни белемнәр булдыруның төп чарасы да.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар теле дәресләрендә заманча технологияләрне куллануның өстенлеге бәхәссез. Барыннан да элек, технологияләр – шәхескә юнәлтелгән, ныклы һәм вариатив булуы белән аерылып тора. Компьютер, күрсәтмәлелекне һәм контрольлекне тәэмин итеп, күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, этәргеч бирә.

Әдәбият

1. Апатова Н.В. Информационные технологии в школьном образовании. – М.: Изд-во РАО, 1994. – 143 с.
2. Рахимов А.З. Психология семьи: учеб. пособие. – 2-е изд., доп. – Уфа: Башк. гос. пед. ун-т. 1999. – 132 с.
3. Федераль белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм / төз.: Р.Б. Камаева, А.Х. Мөхәммәтҗанова. – Казан: ТРМүи, 2015. – 110 б.
4. Харисов Ф.Ф. Татар телен өйрәтүдә заманча технологияләр / Ф.Харисов, Ч.Харисова // Мәгариф. – Казан, 2002. – № 8. – Б.33-36.
5. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – 367 б.
6. Харисов Ф.Ф. Татар теле: яңача укыту юнәлешләре. – Казан: Вестфалика, 2015. – 52 б.

XIX ГАСЫР ТАТАР ТЕЛЕ НЗӘЙРӘТКЕЧЛӘРЕ

Юсупова Ә.Ш.
Казан федераль университеты
alyusupova@yandex.ru

Аннотация.Постоянное и периодическое издание самоучителей в XIX веке говорит о том, что была настоятельная необходимость обучения русских татарскому языку, что объясняется целями и задачами, как просвещения, так и восточной политики царского самодержавия и христианизацией. В самоучителях ставилась практические цели: обучить понимать, говорить, читать и писать на татарском языке. Эти цели в различных самоучителях осуществлялись по–разному. В большинстве самоучителей основное внимание уделяется пониманию и говорению. Обучение произношению проводилось при помощи транскрипции в основном на кириллице, которая, естественно, не в состоянии была передать правильное звучание тюрко–татарских слов и фраз. Структура и композиция самоучителей во многом совпадают. Почти во всех самоучителях лексика вводится по тематическому принципу. Это наблюдается в самоучителях, Ш.Саинова, М.Салихова, И.Кондратова. Основы коммуникативного принципа, который является главным среди лингвистических принципов в современной методике, были заложены уже в самоучителях XIX века. Во многих самоучителях отсутствуют теоретические и научные сведения по фонетике, морфологии, синтаксису татарского языка. Авторы ограничиваются лишь представлением алфавитов двух языков: татарского (на арабской графике) и русского. Это, несомненно, обедняет содержание самоучителей. Только в самоучителе И.Кондратова даются краткие сведения по грамматике татарского языка. В остальных трудах правила грамматики применяются только для составления речевых образцов и изучение его не является самоцелью, носит вспомогательный характер.
Ключевые слова: татарский язык, XIX век, самоучитель, методы

XIX гасырда татар теленә өйрәтү өчен дәреслекләр һәм укыту ярдәмлекләренә булган зур ихтыяҗ яңадан-яңа хезмәтләр язылуга китергән.

1880 елда Казанда ―Татар теленнән яңа һәм тулы үзөйрәткеч яки русларга татар телендә һәм татарларга рус телендә сөйләшергә һәм укырга үзлегеннән өйрәнү өчен кулланма‖ исемле хезмәт басылып чыккан, аның авторы – Ш.Саинов. Тюркологларның хезмәтләрендә бу исем телгә алынмаган. Шуңа күрә бу автор турында биографик мәгълүматлар билгесез. Шунысы гына мәгълүм ки, Ш.Саинов укытучы булган. Хезмәтнең титул битендә автор болай дип язган: ―Бу үзөйрәткеч яңа кулланмалар нигезендә укытучы Ш.Саинов тарафыннан төзелде‖. Ш.Саинов татар укытучылар мәктәбенең инспекторы булган диген караш яши [2,202]. Үзөйрәткеч 130 биттән тора, ул Мәскәү шәһәрендә Россия китапханәсендә саклана [7,210-215].

Үзәйрәткеч традицион рәвештә төзелгән. Беренче кисәктә татар теленең алфавиты бирелгән. Автор 32 татар хәрефенең язылышын һәм укылышын тәкъдим иткән. Алга таба юл өсте һәм юл асты ярдәмче тамгалары тасвирланган. Бу – әлеге дәвердә татар теленнән дөнья күргән үзәйрәткечләрнең барысы өчен дә хас үзенчәлек.

Башка үзәйрәткечләрдән аерылмалы буларак, Ш.Саинов үзәйрәткечендә сүзләрне дөрес уку өчен күнегүләр китерелгән. Башта автор сүзләрнең тәрҗемәләрен биргән, соңыннан, истә калдыру һәм ныгыту максатыннан, бу сүзләр гыйбарәләр эчендә тәкъдим ителгән. Беренче төркем 79 сүздән тора. Сүзләр төрле өлкәләргә карый. Тематик принцип сакланмаган. Мәсәлән, تآ – ат, توا – ут, نوا – ун, نامروا – урман, ىوا – өй, رق – кыр, وات – тау, راق – кар, تيا – ит [3,8–11] һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, сүзләрнең транскрипциясе күрсәтелмәгән.

Сүзләрдән соң гыйбарәләр урын алган. Мәсәлән, ىن وب бу ни? زغك آق –ак кәгазь,پشكن زپراق – пешкән карбыз, چقصاب رميت – тимер баскыч, روضە ەزەرت – зур тәрәзә, شاب اتوا – баш авырта, تيا نكشپ– ит пешкән, ىاب لو – ул бай, چاكشا – ишек ач [3,10–12]. Гыйбарәләр арасында сүзтезмәләр һәм гади җөмләләр бар.

Сүзлекнең зур өлешен татарча-русча сүзлек тәшкил итә. Сүзләр тематик төркемнәргә бүленгән. Барлыгы 29 төркем бирелгән. «Части человеческого тела» (—Кеше тәне әгъзалары‖), «Учебные принадлежности» (—Уку әйберләре‖), «Слова, обозначающие действия» (—Хәрәкәтне белдерә торган сүзләр‖), «Пять чувств» (—Биш хис‖), «Названия животных» (—Хайван исемнәре‖), «Названия птиц» (—Кош атамалары‖), «Насекомые и гады» (—Бөҗәкләр һәм әкәм-төкәмнәр‖), «Минералы» (—Минераллар‖), «Деревья, растения» (—Агачлар, үсемлекләр‖), «Упряжь» (—Җигем‖), «Родство» (—Туганлык‖), «Природа» (—Табигать‖), «Дом и двор» (—Йорт һәм ишегалды‖), «Одежда» (—Кием‖), «Пища и напитки» (—Ашамлык һәм эчемлек‖), «Профессия и ремесла» (—Һөнәр һәм кәсеп‖), «Цветы» (—Чәчәкләр‖), «Орудия» (—Кораллар‖), «Человек» (—Кеше‖), «Имена» (—Исемнәр‖), «Свойства» (—Үзлекләр‖), «Глаголы» (—Фигыльләр‖), «Вес и мера» (—Үлчәм һәм чама‖). Шунысын билгеләргә кирәк: әлеге тематик төркемнәр шул чор татар теленнән үзәйрәткечләрнең барысында да чагылыш тапкан, ләкин бу хезмәттә алар тулыландырылган һәм үз эчендә берничә төркемгә бүленгән. Мәсәлән, «Столовый прибор» (—Табын дирбиясе‖), «Чайный прибор» (—Чәй савыт-сабасы‖) төркемнәре аерым бирелгән. «Имена стран и народов» (—Ил һәм халык атамалары‖) дигән үзенчәлекле төркем бар. Тематик төркемнәрнең исемнәре бары тик рус телендә генә бирелгән.

Традицон рәвештә бу үзәйрәткечтә дә «Разговоры» («Суйляшуляръ») диалоглары бирелгән. Аларның рус теленә тәрҗемәләре күрсәтелмәгән. Мөгаен, автор бу эшне укучыларның үзләренә калдырган. Диалоглар сорау-җавап рәвешендә төзелгәннәр һәм ике кешенең сөйләшүе буларак бирелгән.

Ш.Саинов, укучыларны татар халык авыз иҗаты белҽн таныштыру максатыннан, ҽхлакый характердагы мҽкальлҽр тҽкъдим иткҽн. Мҽсҽлҽн, Гыйлемлекъ байлыктанъ яхшыракъ. Күп бел, аз сҿйлҽ. Эшне башлаганда ахрынъ уйла. Бер иске дусъ яңаның икесеннҽн артыгракъ. Тимерне кызуында сукъ. Бурычны түлҽсҽң ямьле. Бер колъ ике хужага хезмҽт итми [с.95]. Еди үлчҽ бер кис [с.96]. Тугры сүз күзне тишҽ [с.97]. Яхшыдан качма, яманны кылма [с.97]. Һҽр орлыкның үз буразнасы [с.99]. Балта юл ҿчен иптҽш [с.99].

Ш.Саинов үзҿйрҽткече русларга татар телен ҿйрҽтү ҿчен тҿзелгҽн үзҿйрҽткечлҽр арасында матур үрнҽк булып тора.

1885 елда М.Ш.Салиховның —Татар теленнҽн яңа үзҿйрҽткеч‖е басылып чыккан. Хезмҽт Казан император университетының басмаханҽсендҽ дҿнья күргҽн, 53 биттҽн тора. 1893 елда басылган икенче басма тулысынча беренчесе белҽн туры килҽ.

Билгеле булганча, М.Ш.Салихов мҽдрҽсҽ мҿгаллиме булган [1,254]. Шунысы да билгеле: М.Ш.Салихов татар фольклоры белгече булган һҽм 1880 елда беренче татар табышмаклары һҽм мҽкальлҽре җыентыгын бастырган.

М.Салиховның үзҿйрҽткече, алда карап киткҽн башка хезмҽтлҽрдҽн аерылмалы буларак, җайлырак рҽвештҽ тҿзелгҽн; кереш ҿлештҽ шулай ук татар һҽм рус теллҽренең алфавитлары урнаштырылган. М.Салихов татар алфавитында 33 хҽрефне билгелҽгҽн. Аларның язылышы, уку кагыйдҽлҽре аңлатылган. М.Салихов түбҽндҽгечҽ язган: —Татар язуын уңнан сулга таба укырга кирҽк. Сүзлҽрне укыганда бу хҽрефлҽр кыскартылып ҽйтелҽлҽр‖ [4,3].

Үзҿйрҽткечнең кереш ҿлешендҽ автор татар авазларын рус авазлары белҽн чагыштырган: —ا элифъ рус авазлары **э**, **и**, **у** кебек ҽйтелҽ; мҽсҽлҽн, ب دا – эдебъ – образованность, فاصنا – инсафъ – скромность, ديما умидъ – надежда, ҽгҽр юл ҿстендҽ (˜) мҽддҽ тамгасы булса һҽм сүзнең уртасында һҽм ахырында рус телендҽге **а** авазы кебек ҽйтелҽ, мҽсҽлҽн, آط ат, شاتا таш; ب тулысынча рус телендҽге **б** авазына тҽңгҽл: راب – баръ – есть; **п** پавазы кебек ҽйтелҽ: ﻩاشداپ – падша – царь; تавазы рус телендҽге **т** шикелле: ﻩزرت– тярязя – окно‖ [4,5].

Русча-татарча сүзлек рҽвешендҽ тҿзелгҽн үзҿйрҽткечтҽ сүзлҽр 47 тематик тҿркемгҽ бүленгҽн. Сүзлҽр кириллица һҽм гарҽп шрифтында язылган. Тематик тҿркемнҽргҽ киң кулланылышта булган сүзлҽр кертелгҽн. Аларның кайберлҽре хҽзерге вакытта фонетик үзгҽреш кичергҽн. Аерым бер сүзлҽр диалектларда гына сакланып калган. Татар сүзлҽренең Пугачев күтҽрелеше вакытында татар телендҽге документларда теркҽлгҽн борынгы вариантлары да очрый [8,162]. Түбҽндҽге тематик тҿркемнҽр күрсҽтелгҽн: —Рухи сүзлҽр‖, —Җир шары‖, —Кеше һҽм кеше тҽне ҽгъзалары‖, —Кием‖, —Авырулар‖, —Ашамлыклар һҽм эчемлеклҽр‖, —Язу ҽйберлҽре‖, —Феннҽр‖, —Кҽсеплҽр‖, —Хайваннар дҿньясы‖, —Үсемлеклҽр‖, —Җимешлҽр‖ һ.б.

Г.Вәһапов (1867 елдан соңгы басмалар), М.Бекчурин һәм Ш.Саинов үзөйрәткечләреннән аермалы буларак, М.Салихов үзөйрәткечендә диалоглар, гыйбарәләр, халык авыз иҗаты үрнәкләре бирелмәгән. М.Салихов хезмәтендәге тематик төркемнәрнең лексик составы Г.Вәһапов (1864, 1867) үзөйрәткечләренең беренче басмалары белән охшаш.

1887 елда Казан университеты типографиясендә билгесез авторның ―Татар теленнән яңа тулы үзөйрәткеч яки русларга татар телендә һәм татарларга рус телендә сөйләшергә һәм укырга өйрәнү өчен кулланма‖ исемле 51 биттән торган хезмәте басылып чыккан. Авторның исеме тышлыкта да, титул битендә дә күрсәтелмәгән. Китап белгече, татар кулъязмаларының зур остасы, Н.И.Лобачевский исемендәге китапханәнең сирәк китаплар бүлегенең элекке мөдире – А.Фәтхиев билгеләвенчә, бу үзөйрәткечне төзүче кеше Г.Вәһапов булырга мөмкин. Ул хезмәтнең тышлыгында Г.Вәһапов авторлыгын күрсәтә торган тамга билгеләгән, әмма Г.Вәһапов үзөйрәткечләре арасында 1887 елгы басма очрамый. Хезмәт сүзлек составы, күләме белән дә аерыла. Моннан тыш, үзөйрәткеч Ш.Саинов хезмәте белән зур охшашлык күрсәтә. Күбесенчә гыйбарәләр, тематик төркемнәр, лексик берәмлекләр туры килә.

Башка үзөйрәткечләрдәге кебек үк, кулланманың кереш өлешендә ике телнең алфавиты чагыштырма рәвештә тасвирланган. Татар әлифбасы бирелгән [6,2]. Ярдәмче яки юл өсте һәм юл асты тамгалары [6.3], рус әлифбасы [6,4–5].

Үзөйрәткечнең төп өлешен 22 тематик төркемгә бүленгән татарча-русча сүзлек тәшкил итә. Сүзлекнең лексик составы Г.Вәһапов үзөйрәткечләрендә бирелгән сүзләр белән күп очракта туры килә, ләкин теге яки бу лексик берәмлекнең бирелешендә кайбер аермалар да бар (фонетик үзгәрешләр, сүзләрнең диалект вариантлары). Тематик төркемнәр түбәндәгечә урнаштырылган: مويك кием – одежда, چاغا агачъ – дерево, قايا ىمويك аякъ кіеми – обувь, واشا ашау – ѣда, رلكمچا ичемлекларъ – напитки, ونيك кіену –наряд تغامج джямагать – семейство, رلناص санларъ – числа, رلسوت тусляръ – цвѣта, تقو вакытъ – время, واچلوا үльчау – вѣсы.

Кайбер тематик төркемнәр билгеләнмәгән, ягъни исемнәре күрсәтелмәгән. Алар тормышның төрле өлкәләрен чагылдыралар (дин, дөнья, төзелеш, мебель, уку әйберләре, хайваннар, җимешләр, металлар, ат дирбиясе, гумно, фигыльләр).

Үзөйрәткечнең соңгы өлешендә 84 татар халык мәкале һәм әйтеме бирелгән. Алар рус теленә тәрҗемә ителгән яки рус телендәге эквивалентлары тәкъдим ителгән.

Бу үзөйрәткечне тәфсилләп өйрәнү нигезендә без түбәндәге нәтиҗәгә килдек: әлеге хезмәт Г.Вәһапов һәм Ш.Саинов үзөйрәткечләренең синтезы булып тора. Үзенең төзелеше, сүзлек составы белән үзөйрәткеч Г.Вәһапов китабына якын тора, гыйбарәләр, халык авыз иҗаты үрнәкләре күп очракта Ш.Саинов үзөйрәткечендә бирелгән мисаллар белән туры килә. Әмма без үзөйрәткечнең теге яки бу авторныкы булуын дәлилли алмыйбыз.

1893 елда Казан император университетында И.Кондратовның —Татар теленнән яңа гамәли үзәйрәткеч‖ исемле хезмәте басылып чыккан. Кызганычка каршы, автор турында бер генә нәрсә әйтергә мөмкин: ул казан тюркологы булган [1,192]. Башка мәгълүматлар сакланмаган. Үзәйрәткеч 90 биттән тора; 6 тапкыр басылган; Н. Лобачевский исемендәге китапханәдә 1893, 1908, 1911, 1914 елгы басмалар сакланып калган. Бу хезмәтләр барысы да үзгәрешсез басылганнар, шуның өчен без беренче басманы гына тикшерәбез.

Автор А. Троянский (1824, 1833, 1860), Г. Мәхмүдов (1857) хезмәтләре, М. Салихов (1885) үзәйрәткече белән яхшы таныш булган. Үзенең үзәйрәткечен ул шушы китаплар нигезендә язган. Китапның титул битендә И.Кондратов үзе үк болай дип билгеләгән: —Үзәйрәткеч А.Троянский, Г.Мәхмүдов һәм М.Салиховка таянып төзелде‖ [5,1].

Китап татар һәм рус алфавитларын күрсәтү һәм аңлату белән башланган. Ике телнең алфавитлары белән таныштыргач, И.Кондратов татар грамматикасының нигезләрен биргән. Ул болай яза: —Татар грамматикасында (нәхү) баш хәрефләр һәм тыныш билгеләре юк. Шулай ук язу вакытында хәрефләрнең астында һәм өстендә сузык авазлар кулланылмый.

Татар телендә сүзләрнең, фикернең бүленеше аларның тәртибенә карап билгеләнә. Татар телендә хәрефләр сузык, ике сузыклы, өч сузыклы була. Сузык авазлар дип әйтелеш вакытында бары бер генә аваз ишетелгәннәрне атыйлар; алар өчәү: ا و ى. Ике сузыклы авазлар ике сузыктан торалар һәм әйтелеш вакытында бер аваз булып ишетеләләр; алар 7: وا – о, وا – у, ىا – эй, ىآ – ай, ايـ – я, ويـ – ю, ىيـ – йи. Өч сузыклы авазлар өч сузыктан торалар, бер иҗекне тәшкил иткән катнаш аваз чыгаралар; алар 4: ىوا – ой, ىايـ – яй, ىويـ – юй, ىيـ – ей. Тартык авазлар сузыклардан башка әйтелмиләр. Әгәр сүзнең уртасында һәм ахырында бер сузык аваз булса, сузыклары булмаган хәрефләр күп очракта аңардан көч алалар һәм шуның ярдәмендә төзеләләр. Сузык хәрефләре булмаган сүзнең әйтелешен билгели торган сузык тамгалар көчсезрәк, тизрәк, йомшаграк әйтеләләр.Татарларда мужской һәм женский род дигән төшенчә юк‖ [5,14].

—Күнегү өчен сүзләр‖ бүлегендә автор үзенең укучыларын кайбер сүз төркемнәре белән таныштырган. Беренче чиратта, И.Кондратов 33 алмашлыкны күрсәткән. Алар арасында зур урынны бүгенге көндә дә киң кулланылышта йөргән алмашлыклар алып тора: я – نيم минъ, ты – نيس син, кто – مك кем, что – ىن ни. [Кондратов, 1893:15]. Аннан соң —Теркәгечләр, рәвешләр, бәйлекләр‖ дип аталган бүлек бирелгән, анда ярдәмче сүз төркемнәре, модальлек төшенчәсен белдергән сүзләр тикшерелгән [5,25].

Үзәйрәткечнең зур өлешен русча-татарча сүзлек алып тора, сүзлектә 47 тематик төркем бирелгән. Төркем исемнәре, аларның лексик составы М.Салихов үзәйрәткечендәге кебек. Шулай да аермалар бар, һәм алар тематик төркемнәрнең урнаштырылуына бәйле. Сүзлек 49 биттән тора. Алга

таба ―Күнегү ҿчен гыйбарҽлҽр‖, ―Сҿйлҽшүлҽр‖ исемле бүлеклҽр урын алган. Бу бүлеклҽрдҽ гади, җыйнак җҿмлҽ үрнҽклҽре бирелгҽн. Мҽсҽлҽн:

نم ىشك Мин кеше
نيس ذيا وك Син изге
نم لايق نم Мин кыламын
امليق نس نسى Син кылмыйсың
وم زبلايق زب Без кылабызмы?
مديا روليق نم Мин кылыр идем
وم زكنديا روليق زس Сез кылыр идегезме?
زس زساناشا Сез ышанасыз
[5, 80].

Соңгы ―Сҿйлҽшүлҽр‖ бүлегендҽ диалог үрнҽклҽре бирелгҽн, аларда сүз грамматика, тҽрҗемҽ сҽнгате, сҽламҽтлек, язу турында бара.

И.Кондратовның татар телен ҿйрҽнү ҿчен тҿзелгҽн үзҿйрҽткече традицион тҿзелеш калыбын саклаган. Хезмҽтне ҿлешлҽп тикшерү нигезендҽ шундый нҽтиҗҽ ясарга мҿмкин: грамматик мҽгълүматны автор А.Троянский һҽм Г.Мҽхмүдов китапларыннан алган, хезмҽтнең лексик составы М.Салихов үзҿйрҽткече белҽн туры килҽ, диалоглар, югарыда ҽйтелгҽнчҽ, А.Троянский грамматикасыннан алынган.

Нҽтиҗҽ ясап ҽйткҽндҽ, XIX гасырда дҿнья күргҽн татар теле үзҿйрҽткечлҽре гамҽли максатларны күздҽ тотып тҿзелгҽннҽр. Бу хезмҽтлҽрдҽ үз заманының иң үтемле тел ҿйрҽтү методлары кулланылган. Ҿлеге хезмҽтлҽр XIX гасырда татар телен ҿйрҽнүгҽ булган зур ихтыяҗны тормышка ашыруда зур роль уйнаганнар һҽм алар үзлҽренең мнтодик кыйммҽтлҽрен бүген дҽ югалтмый.

Ҽдҽбият

1. Кононов А.Н. Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов (дооктябрьский период) . М.: Наука, 1974. – 340 с.
2. Михайлова С.М. Казанский университет в духовной культуре народов Востока России. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1991. – 359 с.
3. Саинов Ш. Новый и полный самоучитель татарского языка или руководство выучиться без посторонней помощи говорить и читать русским по-татарски и татарам по-русски. Казань,1880.130с.
4. Салихов М. Новый самоучитель татарского языка или руководство выучиться говорить и читать русским по-татарски и татарам по-русски, без посторонней помощи. Казань: типография императорского университета, 1885. - 53 с.
5. Кондратов И. Новый практический самоучитель татарского языка. Полное руководство, как без посторонней помощи выучиться говорить и читать русским по-татарски, а татарам по-русски.
6. Новый и полный самоучитель татарского языка или руководстве выучиться говорить и читать русским по-татарски и татарам по-русски* Казань: типография императорского университета, 1887. - 52-е.

7. Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре Казан: ТаРИХ, 2001. – 432 б.
8. Хисамова Ф.М. XVIII йөздәге татарча эш кәгазе язмаларынын тел үзенчәлекләре Казан: Казан ун-ты нәшр., 1981. – 162 б.

ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ДИСТАНЦИОН УКЫТУ ТЕХНОЛОГИЯСЕН КУЛЛАНУ

Юсупов А.Ф., Юсупова Н.М.
Казан федераль университеты
faikovich@mail.ru

Аннотация. Статья посвящена изучению современных информационных технологий в образовательном процессе, в частности использованию технологии дистанционного обучения на уроках татарского языка и литературы. Как известно, концепция модернизации российского образования ставит новые цели и задачи перед общим образованием на современном этапе. В современной системе образования стремительно набирает скорость процесс внедрения информационно-коммуникационных технологий, которые должны быть направлены на развитие познавательной самостоятельности и творческих способностей учащихся.
Ключевые слова: родной язык, татарская литература, информационные технологии, дистанционное обучение.

XXI гасыр башында илдә барган иҗтимагый яңарыш мәгариф өлкәсенә, шул исәптән татар теле һәм әдәбиятын укыту методикасына да үзгәрешләр алып килде. Заман таләбе, яшьләрнең кызыксыну өлкәләре үзгәрү уку процессына да зур йогынты ясады. Белем бирү традицион форма кысаларыннан чыгып, укучы өчен актуаль һәм кызыклы булырга, аны җәмгыяткә яраклаштырырга тиеш дигән фикер алга куелды. Бу исә укытучыларга – белем бирү процессы белән идарә итүчеләр буларак – яңа мәгълүмати технологияләр белән хәбәрдар булуны, аларны дәресләрдә нәтиҗәле куллана белүне көн тәртибенә куйды.

Онлайн белем бирүнең тарихы, мәгълүмати технологияләр тарихына караганда күпкә кыскарак. Онлайн укыту бүген мәгълүмати технологияләрнең үзенә күрә иң югары дәрәҗәсе дияргә мөмкин, аның барлыкка килүе технологик трансформация белән генә түгел, ә иҗтимагый трансформация, җәмгыятьнең традицион белем бирү модельләреннән китәргә әзерлеге белән бәйләнгән. Бүген классик белем бирү форматлары торган саен азрак ихтыяҗ тудыра, шул ук вакытта, төрле онлайн-ресурсларны кулланучыларның саны даими үсештә.

Тулы масштаблы онлайн укыту 2001 нче елда, Массачусет технологик институты OpenCourseWare проектын ачып җибәреп, үзенең бер төркем уку-укыту материалларына һәм белем бирү программаларына ачык керүне игълан иткәч башлана. Әгәр әлеге моментка кадәр онлайн укыту системалы характерга ия булмаса, бу моменттан ул комплекслы тәмамланган продукт буларак тәкъдим ителә. Бүгенге көндә унбер меңгә якын ачык белем бирү программалары бар, дип исәпләнелә, аларның егерме миллионга якын тыңлаучылары бар [5: 21].

Шулай итеп, онлайн укыту – безнең көннәрдә ачык белем бирүнең киң таралыш алган формасы. Онлайн укыту – өйрәнү өчен өстәмә материаллары, тестлары һәм арадаш аттестация эшенең башка биремнәре булган кыска видеолекцияләр сериясеннән гыйбарәт. Ахырда теге яисә бу курсны үтү һәм үзләштерүне раслаган сертификат алу мөмкинлеге бар. Теләсә кайсы эш формасы кебек үк, бу төр укытуның да уңай һәм кимчелекле яклары бар. Онлайн укытуның өстенлекле ягы лекцияләрне тыңлау мөмкинлеге булуга бәйле, ләкин бу очракта укытучы белән аралашу кими [7: 20]. Онлайн белем алу, кайда һәм кайчан укырга уңайлы булуга бәйле төстә, белем алу процессын мөстәкыйль оештыру мөмкинлеген бирә. Әмма шушы ук факт кулланучылардан үздисциплина һәм даими төстә укуга мотивация булдыруны да таләп итә. Мондый укытуның төп өстенлеге, кешенең үз белем траекториясен шәхси кызыксынулары һәм ихтыяҗларына бәйле рәвештә мөстәкыйль билгели алуына бәйле. Әмма, галимнәр искәртүенчә, мәктәптәге предметларны онлайн укыту белән алыштыру реаль түгел, чөнки, алар нинди генә плюс якларга ия булмасыннар, белем бирү алдында торган бурычларның күпчелеген мәктәп стеналарыннан тыш хәл итеп булмый. Ләкин мондый система мәктәптәге предметларны өйрәнүдә һәм дәресне тулыландыруда файдаланыла ала, теманы, предметны тирәнрәк өйрәнү мөмкинлеге бирүче яхшы ресурс булырга мөмкин.

Онлайн укыту, башлыча, теоретик белемнәрне гамәлдә куллануга һәм метапредмет якын килүгә юнәлдерелгән. Онлайн укыту укытучының укучыларга индивидуаль якын килүен гамәлгә ашыруда өстәмә механизм була ала. Биредә укытучының төп максаты булып онлайн укыту потенциалын традицион дәресләр белән интегральләштереп дөрес һәм нәтиҗәле куллану торачак.

Белем бирү оешмаларындагы предметлар кысаларында онлайн укыту технологиясе белән эшләүнең берничә варианты бар:

– онлайн укыту материалын өй эше сыйфатында өйрәнү;

– үзләштерелгән белемнәрне контрольгә алу формасы буларак онлайн укыту тестларын һәм арадаш аттестация эше биремнәрен башкару;

– теманы тирәнрәк үзләштерү өчен онлайн укытуны өстәмә материал сыйфатында куллану;

– онлайн укыту мөмкинлекләрен укучыларның мөстәкыйль иҗади һәм проект эшчәнлегендә куллану;

– материалны тел предметы (яисә башка предмет та булырга мөмкин) буенча программаны үзләштерүдә һәр укучының «йомшак» якларын һәм ныгытырга кирәк булган белемнәрен исәпкә алып сайлау.

Электрон белем бирү фәндә ике төрле мәгънәдә аңлашыла: 1) мәгълүмати-телекоммуникацион технологияләр ярдәмендә уку; 2) яңа мультимедиа технологияләр һәм Интернетны куллану хисабына уку-укыту сыйфатын арттыру [3: 313].

Татар телендә электрон белем бирү ресурслары, гомумән, белем бирү системасындагы кебек үк, үсеш юлында берничә этап кичерә.:

1) беренче этап (1990 нчы еллар). Электрон белем бирүнең төп ресурсларын электрон дәреслекләр тәшкил итә;

2) икенче этап (2000 – 2004 нче еллар). Дистанцион уку системасы формалаша;

3) өченче этап (2004 – 2009 нчы еллар). Болытлы сервислар барлыкка килә;

4) дүртенче этап (2008 – 2011 нче еллар). Электрон укуда ачык курслар барлыкка килә;

5) бишенче этап. Онлайн-курслар оешып китә [4: 8].

Уку-укыту китабының перспектив юнәлешләре турында сөйләгәндә, белгечләр киләчәктә әйдәп баручы булып мәгълүмати-коммуникацион технологияләр мөмкинлекләреннән файдаланып төзелгән электрон (мультимедияле) дәреслекләр торачак дигән фикерне үткәрәләр. Электрон дәреслек дигәндә, «аерым гына файдаланырга мөмкин булган, басма аналоглары булмаган, өстәвенә уку материалы кысаларын киңәйтә, мәктәп курсы белән генә чикләнмичә, өстәмә белем алу мөмкинлеге бирә торган аерым бер продуктны» атыйлар [1: 10]. Т.С. Круст, төрле предметларга караган электрон дәреслекләрнең телен, стилен, жанр үзенчәлекләрен өйрәнеп, мондый нәтиҗәгә килә: «Электрон дәреслек – фәнни стильгә караган жанрлар системасында «дәреслек» жанрының бер вариантын, ә компьютер тирәлегендәге мәгълүмати жанрлардан мөстәкыйль жанрны тәшкил итә. Ул билгеле бер адресатка юнәлдерелә, белем бирү максаты белән төзелгән каты структуралы гипертекст буларак төзелә; аңа мультимедиялелек, интерактивлык, катлаулы төзелешле булу, мәгълүматның фәнни стильдә тапшырылуы хас; метател аңында электрон дәреслекләрнең релевант билгеләре булып гипертекстуальлек, мультимедиялелек, мәгълүматның дәреслек битләрендә фрейм рәвешендә бирелеше тора» [6: 24].

Программалаштырылган электрон дәреслек укытучы башкара торган кайбер вазыйфаларны да үти башлый: «мәгълүмат чыганагы булып тора; уку-укыту процессын оештыра; материалның үзләштерелү дәрәҗәсен контрольдә тота; предметны өйрәнүнең темпын көйли; аңлатмалар бирә; хаталарны кисәтә» [8: 303]. Электрон дәреслектән тыш, укытучы дәрестә эшне электрон кушымтага нигезләнеп тә алып барырга мөмкин. Бу очракта укытучы никадәр күбрәк чыганакка нигезләнеп эш итә, эшчәнлекне никадәр төрләндерә ала, шулкадәр яхшырак, нәтиҗәләрәк санала.

Бүгенге көндә һәрбер дәреслекнең электрон варианты бар, әмма ул басма вариантны тулысынча кабатламый, ә бәлки өстәмә материал буларак файдаланыла. Мисал өчен, рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында татар телен өйрәнүче укучыларга атап төзелгән дәреслекләрнең электрон формаларында дүрт төрдәге биремнәр тәкъдим ителгән: аудиоязма, диктант, тест һәм физкультминутлар өчен видеороликлар. Моннан кала электрон дәреслек, электрон кушымталарда диктор укуындагы текстлар тәкъдим ителә. Өлеге төр биремнәр, беренче чиратта, укучыларга авазларны дөрес әйтергә өйрәтсә, икенче чиратта, аларны әсәрне сәнгатьле итеп укырга өйрәтә.

Дистанцион уку системасына килгәндә, «дистанцион курслар кулланучыларны табигый сөйләм эшчәнлегенә җәлеп итәләр һәм бүгенге көн реалияләренә туры киләләр. Алар матур итеп бизәлгәннәр, бу исә кулланучыларда татар телен өйрәнүгә өстәмә мотивация тудыра» [2: 279].

Дистанцион уку системасын камилләштерү юлында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан җитди эшләр алып барыла. Мисал өчен, «Ана теле» онлайн-мәктәбе сыйфатлы сервис аркылы татар теленә өйрәнү мөмкинлеге бар. Шулай ук, «Бала.рф» виртуаль китапханәсе дә «үзебезнең илдәге һәм чит илдәге татар балаларын дистанцион укытуда эффектив ресурс» буларак бәяләнә ала.

Тагын бер уңышлы эшләп килүче татар телле интернет-ресурс – «Татармультфильм». Әлеге берләшмәнең продуктлары сыйфатлы, җанлы, тәэсирле булулары белән аерылып торалар. Берләшмә халык әкиятләрен, атаклы әдипләрнең иҗатларын мультфильм яки анимацияле рәт буларак тәкъдим итә. Шуны билгеләп үтәргә кирәк: мультфильмнарны карау алдыннан укучыларга берничә төрле эш тәкъдим итәлә: яңа лексика белән таныштыру, кайбер сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау – сүзлек эше, видеосюжетның исемен аңлату һ.б.

Дәреслектә тәрҗемәләр эше өчен биремнәр аз күләмдә генә бирелә, укучының әсәрне аңлавында контекст, укытучы ярдәме зур булачак дип күзалланырга мөмкин. Шул рәвешле әзерлек эше алып барылганнан соң, укытучы турыдан-туры видеоматериалны күрсәтүгә керешә. Сыйфатлы итеп ясалган видеоматериал, кызыклы сюжет, ачык төстәге бизәлеш, әсәрнең мультфильм жанрына яраклаштырылып бирелүе гадәттә балаларга ошый, уңай мотивация тудыра. Мультфильм каралганнан соң, текст материалын аңлау дәрәҗәсе күнегүләр белән эш вакытында тикшерелә.

Билгеле булганча, укылган текст буенча сорауларга җавап бирү кызык булмаска мөмкин, сораулар укучыда авырсыну да тудыра ала. Әмма мультфильм караганнан соң аның темасы, идеясе, геройлары башлангыч сыйныф укучысы күңелендә урын ала, димәк, бирем дә җиңеллек белән башкарылыр дип уйларга җирлек бар. Берләшмәнең проекты булган «Бала.рф.» виртуаль китапханәсенең кыйммәте аеруча зур булып аңлашыла, биредә җанлы, кызыклы ресурслар тест биремнәре һәм әңгәмә өчен сораулар белән тулыландыра. Күп кенә әсәрләр рус балаларына татар теленә – дәүләт теленә өйрәнү әсбапларындагы текстлар белән аваздаш.

Чираттагы татар телле интернет-ресурс – «Татар теле онлайн» интерактив интернет-дәреслеге. Әлеге интерактив дәреслек түбәндәге максатларга ирешүне күз уңында тота: 1) киң җәмәгатьчелекне алдынгы Интернет-технологияләрне кулланып татар телен мөстәкыйль өйрәнүгә җәлеп итү; 2) татар телен, мәдәниятын, тарихын һәм сәнгатен өйрәнүгә кызыксыну уяту; 3) белем бирүче Интернет-ресурсларны киңәйтү. Бу дәреслектә аудиоматериалларны тыңлау һәм татар теленең фонетикасы, лексикасы һәм грамматикасы буенча биремнәрне үтәү; текстны укып, дөрес җавапларны яки бер генә дөрес җавапны табу; текстның төшеп калган урыннарына язып бетерү; бирелгән хәрефләрдән

сүзләр һәм сүзләрдән җөмләләр төзү; телдән һәм язма сөйләмгә кагылышлы биремнәрне үтәү һ.б.лар урын алган.

Болытлы сервисларны куллану буенча да татар теле һәм әдәбияты укытучылары нәтиҗәле эшчәнлек алып баралар. Гугл-диск болытлы сервис укучыга үз эшчәнлегендә кулланырга мөмкин булган мәгълүматны кертергә, сакларга, кирәкле вакытта укучылары яки коллегалары белән бүлешергә мөмкинлек бирә. Әлеге сервис ярдәмендә графикалы, текстлы, аудио һәм видеофайлларны, электрон таблицаларны, презентация, графика, диаграммаларны карарга һәм үзгәртергә була. Белгечләр ассызыклаганча, әлеге сервис саклау вазифасын гына башкарып калмый, ә файллар белән коллектив рәвештә эшләү мөмкинлеген дә бирә. Гугл-диск, гугл-формалар ярдәмендә укытучылар, аларның үз сүзләре белән әйткәндә, укучылар арасында сораштыру оештырганда, проект һәм реферат темалары буенча эшләгәндә һәм укучыларга тәкъдим иткәндә, интерактив биремнәр эшләгәндә, онлайн-тестлар эшләгәндә нәтиҗәле эш алып баралар [9: 51-52].

Гомумән алганда, татар теле һәм әдәбиятына өйрәтү заманча шартларда, заманча ысуллар һәм сыйфатлы ресурслар ярдәмендә тормышка ашырыла. Ул ресурслар укытучының вакытын тиешенчә сарыф итү мөмкинлеген бирә, дәреснең җанлылыгын тәэмин итә.

Әдәбият

1. Бәшәрова А., Шәмсетдинова Р. Татарча электрон кушымталар һәм дәреслекләр // Мәгариф. – 2016. – №1. – Б. 10-12.

2. Замалетдинов Р.Р., Фатхуллова К.С., Юсупова А.Ш. Из опыта использования мультимедийных технологий в обучении татарскому языку // Филология и культура. – 2013. – №3(33). – С. 277-281.

3. Исследовательская лингводидактика по русскому языку: теория, практика, инновации: монография. – М.: РУДН, 2016. – 598 с.

4. Краснова Г.А. Можаева Г.В. Электронное образование в эпоху цифровых трансформаций. – Томск: Изд. Дом Томск. гос. ун-та, 2019. – 200 с.

5. Кузнецов Н.В. Онлайн-образование: ключевые тренды и препятствия // E-Management. – Т. 2. – №1. – 2019. – С. 19-25.

6. Куст Т.С. Жанровая природа электронного учебника: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Томск, 2011. – 25 с.

7. Основы открытого образования: в 2 томах. Т. 1. / Отв. ред. В.И. Солдаткин. – М.: НИИЦ РАО, 2002. – 676 с.

8. Радчиков А.С., Радчикова Н.П. Использование электронных учебников для организации самостоятельной работы студентов / Женщина. Общество. Образование. Материалы 12-ой международной научно-практической конференции (18-19 декабря 2009 г.). – Минск, 2010. – С. 304-308.

9. Яхин И.Использование Гугл-форм в педагогической практике // Мәгариф. – 2016. – №1. – Б. 51 – 52.

СОДЕРЖАНИЕ

ЭЧТӘЛЕК

Айдарова С.Х., Гарипова-Хасаншина В.М. Уроки татарского языка на краткосрочных курсах 3

Алшейхо Газала Специфика ономастики и топонимики гидронимов турецкого и татарского языков 7

Болгарова Р.М., Исламова Э.А. Особенности функционирования тюркизмов в сравнениях русского языка 16

Вершинина Т.В. Связь фразеологии и языковой картины мира 21

Гайнуллина Г.Р. Ә. Еники публицистикасында башлангыч мәктәптә туган телне өйрәтү мәсьәләләренә карашлар 23

Гайнутдинова А.С. Ортактюрк тили в современности 25

Гайсина Р.С. Башлангыч сыйныф укучыларында этномәдәни компетенция формалаштыру юллары 29

Галиева Л. А. Руские фразеологизмы как средство формирования коммуникативной компетенции учащихся 7-8 классов 33

Галиева Р.Т. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә уңай мотивация тудыру – белем сыйфатын арттыру чараларының берсе 38

Галимҗанова Р.Ф. Кейс-технология һәм аны татар телен укытуда куллану мөмкинлекләре 43

Галиуллина Г.Р. Татар теле белемендә синонимнарны өйрәнү тарихына күзәтү 47

Гареева Р.Р., Гареева М.Р. Некоторые особенности разговорной речи студентов в полилингвальном образовательном пространстве 50

Гареева Р.Р., Гиззатуллина А.Ф. Иновационные педагогические технологии на уроках татарского языка 54

Гарифуллина Г. А. Логопедическая мнемотехника как средство активизации речевой деятельности детей 58

Гарифуллина Л.И. Обучение родного (татарского) языка в начальной школе 60

Гатауллина А. С. Халык һәм автор җырлары 63

Гилазетдинова Г.Х., Абдрахманова Ю.Д. Специфика путешествия как литературного жанра в России конца XIX века 68

Гилязиева А.Н. Работа с одарѐнными детьми в начальной школе 73

Гаязова Д. И. Проект технологиясен татар теле дәресәрендә куллану ысуллары 77

Гомәрова Г.А. Туган телгә өйрәткәндә заманча һәм инновацион технологияләрне куллану 81

Гыйләҗева Л.Г. Татар телен чит тел буларак өйрәтү дәресләрендә лексиканы һәм грамматиканы активлаштыру 84

Денмухаметова Э.Н. Языковая личность в полилингвальной среде и мониторинг знаний выпускников по татарскому языку 88

Замалетдинова Г.Ф. Концепт җан / душа в татарском языковом сознании 93

Замалетдинов Р.Р. О новой системе оценки уровня владения татарским языком 97
Зөфәрова Г. Хэзерге татар һәм төрек теллəрендə мөрəжəгать итү алымнары 102
Ибнеева А.М., Марданова З.Р. Развитие коммуникативных компетенций учащихся на уроках литературы в начальной школе 105
Измайлова Г. А., Замалетдинова Г. Р. Молодежный сленг в современном английском языке 109
Иргалина З. Г. Мобильные инновационные технологии в обучении иностранному языку 112
Исламова Л.Л. Татар һəм казах теллəрендə «баш» компонетлы фразеологизмнар 116
Исмаилова М. Этнокультурологическая характеристика кулинарной культуры Азербайджана 120
Исхакова Р. Ш . Азнакай районында хəзерге татар теле лексикасын өйрəтү 127
Karimova I. M.Caucasus area of toponyms of Turkish origin 130
Каюмова И.Ф. , Мударисова Р.Р. Современные цифровые средства обучения языкам 138
Кəлимуллина Л.Ю. Татар теле дəреслəрендə заманча һəм иннавацион технологиялəр куллану 141
Кириллова З.Н. Германия һəм Венгриядə татар телен укыту 145
Лукаш Л.В. Применение инновационных технологий на уроках русского языка и литературы в современной школе 149
Мансурова З.Җ. Татар телен өйрəтүдə сыйныфтан тыш уку дəреслəренең роле 152
Мирзагитов Р.Х. Подготовка би- и полилингвалтьных педагогических кадров в казанском федеральном университете 155
Мигранова Л.Ш. Изучение фразеологических единиц на уроках родного языка (русского) 159
Мөгътəсимова З.А. «Кара» компонентлы татар мəкальлəренə лингвомəдəни анализ 164
Мөхəммəтшина А.Ф. Кытай һəм татар теленең фонетикасы: чагыштырма аспектта 167
Мухаметьянова Э. Р. Совершенствование образовательной среды на уроках татарского языка и литературы 171
Насипов И. С., Рамазанова А. Р. Г. Ибраһимовның «Казак кызы» романындагы тел үзенчəлеклəрен урта мəктəптə өйрəнү 174
Нəбиева Я.К. Схемалылык эш технологиясе куллану буенча тикшерену нəтиҗəлəре 176
Нəбиуллина Г.Ə. Татар сөйлəм этикетына өйрəтү алымнары 178
Нəүмəтова Р.Р. Татар теленə өйрəтүдə əхлакый кыйммəтлəрне формалаштыру чарасы буларак мультипликацион фильмнар 180

Некрасова Т.В., Моисеенко Л.Н. Нарративный подход в методике преподавания иностранного языка в условиях глобализации профессионально - ориентированного образовательного процесса 185
Нигамаева Г.Г. Развитие речи младших школьников в поликультурной среде 190
Нигметзянова А.Р., Садыкова А.М. Внедрение компьютерных технологий в процессе обучения 195
Нурисламова З.Г. Туган тел һәм әдәбиятын укыту мәсьәләләрен чишүдә универсаль уку гамәлләрен үзләштерүгә юнәлтелгән биремнәрнең әһәмияте 197
Нурмөхәммәтова Р.С. XXI гасыр русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләре 200
Нуэрмаймайти Нуэрсяти. Поздравления в речи уйгур 205
Öner Mustafa. «Ege-türkoloji»de çağdaş türk yazi dilleri öğretimi ve araştirmasi 209
Сәгъдиева Р.К., Хөснетдинов Д.Х. Туган (татар) тел дәреслекләрендә электрон дәреслекләрне файдалану 214
Сабирҗанова Р. Р. Сүз сәнгатендә кешелек кыйммәтләренең бирелеше 218
Саде Бейза. Характерные особенности использования компонентов-зоонимов в пословицах турецкого и татарского языков 220
Салахова А.Р. Лексикографическое описание мифологического персонажа ―дию‖ 223
Саматова И.Р. Татар телендә исем фигыль һәм аны укыту үзенчәлекләре 226
Саматова М.А. Ясалма сүзләр системасында синоним, антоним, омонимнар 229
Samedova K. I. Non-Terminological words in the Northern dialects of the Azerbaijani language 234
Саттарова М.Р. Татар һәм рус телләрен чагыштырма өйрәнү: актив һәм пассив төзелмәләр кулланылышы үзенчәлекләре 240
Сафина Э. И. Туган тел дәресләрендә татар сүзлекләре 244
Сәлахова Р. Р. Татар теле дәресләрендә сөйләм телен үстерү һәм камилләштерү чарасы буларак кроссвордлар 249
Селендили Л.С. Первые шаги в обучении крымскотатарскому языку 255
Сибгаева Ф.Р. Татар теле дәресләрендә интеграль алымның роле 261
Файзуллина Г.Ч. Метрические записи XIX – начала XX вв. о тобольских бухарцах как историко-лингвистический источник 265
Фаттахова Р. Ф., Шәмсетдинова Р.Р. Татар теле дәресләрендә укучыларның тел байлыгын үстерү 269
Фәтхуллова К.С., Мөгътәсимова Г.Р. Телләрне заманча укытыйк 274
Фәхриева Л.Х. «Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам…» (Г. Тукай әдәби мирасында «Пушкиннән мокътәбәс» ирекле шигырьләренең тель-стиль үзенчәлекләре) 277

Ферафонтова А.И. Синонимическая парадигма в филологических исследованиях 281
Хѐева Ф. Җ. Татар теле һѐм татар ѐдѐбияты дѐреслѐрендѐ куллану ҿчен, learningapps.org сервисы ярдѐмендѐ интерактив биремнѐр тҿзү 284
Хаева-Хаметзянова В.Х., Фатхуллова К.С. Развитие коммуникативной одаренности учащихся гимназии 289
Халиуллина А.Г., Башарова Г. Сопоставительный анализ переводов романа Марка Твена «Приключения Тома Сойера» на русский и татарские языки 294
Халиуллина Н.У., Басырова А.Р. М. Кашгарлының ―Диване лҿгат ѐт-тҿрк‖ сүзлегендѐге лексик параллельлѐрнең семантик үзенчѐлеклѐре 297
Халиуллина Э.У., Сираева А.А. Функционирование концепта ҿй «дом» в памятниках древнетюркской письменности 302
Харисов Ф.Ф. Татар теле дѐресѐлрендѐ компетенциялѐр формалаштыру мѐсьѐлѐсе 306
Хѐйретдинова Л.Н. Татар теле дѐреслѐрендѐ проект эшчѐнлеген оештыру 310
Хѐйруллин И.Р. Дѐреслѐрдѐ мультимедиа технологиялѐрен куллану 314
Һадиева Г.К., Кузьмина Х.Х. Гомуми белем бирү оешмалары ҿчен татар телендѐ тҿзелгѐн дѐреслеклѐрдѐ топонимик материалның кулланылышы 316
Шаймердинова Н.Г. Взаимодействие казахского языка с кыпчакскими и огузскими языками в Казахстане 321
Хҿснетдинов Д.Х., Сагдиева Р.К. Сѐламѐтлек саклау технологиясе нигезендѐ язучы телен ҿйрѐнү 329
Шаймухаметова Р.Р. Универсаль уку гамѐллѐрен формалаштыру позициясеннѐн, заманча чит тел дѐреслѐре проектлаштыру 332
Шѐмсетдинова Р.Р., Фаттахова Р.Ф. Татар теле һѐм ѐдѐбияты дѐреслѐрендѐ укучыларның функциональ грамоталылыгын формалаштыру 335
Шѐрифуллина Р.И. Милли мѐгарифнең белем сыйфатын күтѐрүдѐ тҿп бурычлар 339
Шиһабеддинова Г.Х. Татар теле дѐреслѐрендѐ мѐгълүмати технологиялѐр куллану 343
Юсупова Ѳ.Ш. XIX гасыр татар теле үзҿйрѐткечлѐре 348
Юсупов А.Ф., Юсупова Н.М. Татар теле һѐм ѐдѐбияты дѐреслѐрендѐ дистанцион укыту технологиясен куллану 355

Научное издание

СОВЕРШЕНСТВОВАНИЕ МЕТОДИКИ ОБУЧЕНИЯ ЯЗЫКАМ

ПЛОЩАДКА ОБМЕНА ПРОГРЕССИВНОЙ ПРАКТИКОЙ

ТЕЛЛӘРГӘ ӨЙРӘТҮ МЕТОДИКАСЫН КАМИЛЛӘШТЕРҮ

АЛДЫНГЫ ТӘҖРИБӘ БЕЛӘН УРТАКЛАШУ МӘЙДАНЧЫГЫ

МАТЕРИАЛЫ МЕЖДУНАРОДНОГО НАУЧНО-МЕТОДИЧЕСКОГО

ОНЛАЙН-СЕМИНАРА

(18 февраля 2021 г.)

Подписано в печать 17.03.2021.
Бумага офсетная. Печать ризографическая.
Формат 60x84 1/16. Гарнитура «Times New Roman». Усл. печ. л. 35,5
Усл. изд. л. 42,1. Тираж экз. Заказ электронный формат

Отпечатано с готового оригинал-макета
в типографии Издательства Казанского университета

420008, г. Казань, ул. Профессора Нужина, 1/37
тел. (843) 233-73-59, 233-73-28